# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2025 3 (47)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен***
***һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы***
***кысаларында 2014 елдан нәшер ителә.***
***Елына кәгазь һәм электрон форматта 4 сан чыгарыла.***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр*
*һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча*
*федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы*
*таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ МӨХӘРРИР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
НАДЫРШИНА Л.Р., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы сәркатип)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ДӘҮЛӘТШИНА Л.Х. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
АБДУЛЛИНА Н.Т., ЧУГУНОВ А.С.

Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mail: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Гыйлемшин Ф.Ф.* Рөстәм Галиуллин әсәрләрендә эмотив лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 7
*Мотыйгуллина Ә.Р.* Спорт төшенчәләрен классификацияләү мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Зиннәтуллина Г.Ф.* Әдәби текстта сөйләм теле лексикасы *(Гаяз Исхакый әсәрләре мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . 25
*Кадирова Э.Х.* Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә бер урыннан икенче урынга күчерү фигыльләре. . . . . . . . . . . 30

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Рәмиев З.З.* Тукай фатихасын алган шагыйрь *(Сәгыйть Сүнчәләйнең тормыш һәм иҗат юлы турында)*. . . . . 36
*Шаронов А.М.* Габдулла Тукай шигырьләре эрзя теленә тәрҗемәдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

### ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛЛЫКНЫ КАРШЫЛАП

*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Әмирхан публицистикасында иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормыш (1906–1912). . . . . . . . . 51
Фатих Әмирханның фикъһ хакында уйланулары *(Муса Бигиев хезмәтенә бәяләмә)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Хәбетдинова М.М.* Татар текстологиясе һәм Нәкый Исәнбәт. . . . 78

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ 80 ЕЛ

*Дәүләтшин Г.М.* Фронт һәм фән юлын узган галимнәр . . . . . . . 96
*Галиева Л.Ш.* Бөек Ватан сугышы чорында Казандагы әдәби тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Төхфәтуллина Ә.Г.* Мәктәпкәчә белем бирү программалары: үткәне һәм бүгенгесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
*Фәтхуллова К.С.* Яңа шартларда туган телдән дәрестән тыш эшчәнлек оештыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126

### СӘНГАТЬ

*Махинин А.Ю.* Декоратив-гамәли сәнгать әсәрен булдыруда визуальләштерүнең роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
*Кулмамбетов Ж.О.* Казахстан һәм Кыргызстан театрларының яшь режиссёрлары яңа мәгънә эзли . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
*Бердникова Т.М., Шкляева Л.М.* Апас районы рәссамнар иҗатында *(пленэр мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Габдрахман Сәгъди.* Икенче баскыч совет мәктәпләрендә әдәбият һәм аны укыту методлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Галиуллин Т.Н.* Тарихта һәм фәндә үз урыны бар *(галим, җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсәнов истәлегенә)* . . . . 160
*Алишина Х.Ч.* Фуат Әшраф улы Ганиев – төрки тел белемендә фәнни мәктәпкә нигез салучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Бәширова И.Б.* Китап күзәтү: Когнитив лингвистиканың проблемалы кырлары. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
*Алиева Ә.Х.* Фатих Әмирхан – сүз сәнгате остасы *(алты томлы академик басманың 2 нче һәм 3 нче томнары дөнья күрү уңае белән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Гилемшин Ф.Ф.* Особенности использования эмотивной лексики в произведениях Рустама Галиуллина. . . . . . . . . . . .7

*Мотигуллина А.Р.* Вопросы классификации спортивных терминов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .15

*Зиннатуллина Г.Ф.* Разговорная лексика в художественном тексте *(на материале произведений Гаяза Исхаки)* . . . . . . . . .25

*Кадирова Э.Х.* Глаголы движения, выражающие каузацию перемещения объектов в письменных памятниках периода Казанского ханства . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .30


## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Рамеев З.З.* Соратник и друг Тукая *(о жизненном пути и творчестве Сагита Сунчелея)* . . . . . . . .36

*Шаронов А.М.* Переводы стихотворений Габдуллы Тукая на эрзянский язык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .44


## К 140-ЛЕТИЮ ФАТИХА АМИРХАНА


*Загидуллина Д.Ф.* Общественно-политическая и культурная жизнь в публицистике Фатиха Амирхана (1906–1912) . . . . . . .51

Размышления Фатиха Амирхана об исламском праве *(рецензия на книгу Мусы Бигиева)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . .69


## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Хабутдинова М.М.* Татарская текстология и Наки Исанбет. . . . . 78


## 80 ЛЕТ ВЕЛИКОЙ ПОБЕДЕ


*Давлетшин Г.М.* Ученые-фронтовики ИЯЛИ . . . . . . . . . . . . 96

*Галиева Л.Ш.* Литературная жизнь Казани в годы Великой Отечественной войны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108


## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ


*Тухфатуллина А.Г.* История развития образовательных программ дошкольных учреждений . . . . . . . . . . . . . . . . 117

*Фатхуллова К.С.* Организации внеурочной деятельности по татарскому языку в новых условиях . . . . . . . . . . . . . . . . 126


## ИСКУССТВО


*Махинин А.Ю.* Роль визуализации в создании произведения декоративно-прикладного искусства . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

*Кулмамбетов Ж.О.* Молодая театральная режиссура Казахстана и Кыргызстана в поисках нового смысла . . . . . . . . 137

*Бердникова Т.М., Шкляева Л.М.* Апастовский район в творчестве художников *(на примере пленэра)* . . . . . . . . . . . 145

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Габдрахман Сагди.* Литература и методы ее преподавания в советских школах второй ступени . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

## ПЕРСОНАЛИИ

*Галиуллин Т.Н.* Ученый, оставивший след в истории и науке *(памяти Мансура Хасанова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

*Алишина Х.Ч.* Фуат Ашрафович Ганиев – основоположник научной школы в тюркском языкознании . . . . . . . . . . . . . . 165

## НОВЫЕ КНИГИ

*Баширова И.Б.* Обзор книги: Проблемные поля когнитивной лингвистики . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

*Алеева А.Х.* Фатих Амирхан – мастер художественного слова *(о 2-м и 3-м томах шеститомного академического издания)* . . . 179

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***Ф.Ф. Гыйлемшин***

# РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИН ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЭМОТИВ ЛЕКСИКАНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Данная статья посвящена анализу эмотивной лексики, использованной в произведениях известного писателя Рустама Галиуллина. В исследованных текстах эмоциональность передается при помощи глаголов и эмоциональных слов. В них глаголы, отражающие такие эмоции, как радость, горе, страх, гнев, раскрывают внутренний мир героев, привлекают читателя и показывают историко-культурный контекст произведений. Семантическое разнообразие эмоциональной лексики, богатство синтаксических форм и контекстуальное употребление делают их глубокими и впечатляющими. В произведениях, посвященных таким героям, как Таджетдин Ялчыгул и Гиззатулла Рахматуллин, эмоциональные глаголы образуют смысловое и эстетическое ядро текста. Глаголы, выражающие радость, грусть, страх и гнев, раскрывают внутренний мир персонажей, вовлекают читателя и указывают на исторический и культурный контекст. Семантическое разнообразие эмоциональной лексики, богатство синтаксических форм и контекстное использование обуславливают смысловую глубину и выразительность литературных текстов.

**Ключевые слова:** эмотивная лексика, положительные эмоции, чувство, произведение, персонаж, эмоционально-экспрессивные слова, фразеологизмы, эстетические особенности.

This article is devoted to the analysis of emotive vocabulary used in the works of the famous modern Tatar writer Rustam Galiullin. In the studied texts, emotionality is conveyed with the help of verbs and emotional words. In them, verbs reflecting such emotions as joy, grief, fear, anger, reveal the inner world of the characters, emotionally attract the reader and show the historical and cultural context of the works. The semantic diversity of emotional vocabulary, the richness of syntactic forms and contextual use make them deep and impressive. In the works dedicated to such heroes as Tadzhetdin Yalchygul and Gizzatulla Rakhmatullin, emotional verbs form the semantic and aesthetic core of the text. Verbs expressing such emotions as joy, sadness, fear and anger reveal the inner world of the characters, emotionally involve the reader and indicate the historical and cultural context. The semantic diversity of emotional vocabulary, the richness of syntactic forms and contextual use make the works deep and impressive.

**Keywords:** emotive vocabulary, positive emotions, feeling, work, character, emotionally expressive words, phraseological units, aesthetic features.

Әдәби текст тел чаралары ярдәмендә дөньяның сәнгатьле картинасын чагылдыру, кеше кичерешләрен һәм рухи дөньяны ачу өчен хезмәт итә. Эмоциональ лексика әсәрләрдә геройларның эчке дөньясын күрсәтүдә, укучыны эмоциональ яктан җәлеп итүдә һәм әсәрнең тәэсир көчен арттыруда мөһим роль уйный. Бу мәкаләдә

танылган язучы Рөстәм Галиуллинның 2017 елда Казанда нәшер ителгән «Васыять» китабына кергән «Васыять», «Әдрән», «Босойокко», «Җиһан», «Көзге», «Дәвам» әсәрләрендә эмоциональ лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре өйрәнелә. Әлеге әсәрләр тарихи вакыйгаларны, кеше психологиясенең тирән катламнарын һәм татар халкының рухи дөньясын чагылдыра.

Тикшеренүнең максаты – эмоциональ лексиканың текстларда кулланылышын, аның семантик һәм стилистик үзенчәлекләрен анализлау, шулай ук әсәрләрдәге эмоциональлекнең укучыга тәэсирен ачыклау.

Тикшеренү текстология, лингвистика һәм әдәбият белеме кысаларында формалашкан теоретик концепцияләргә нигезләнә. Ш. Балли [2], Н. Арутюнова [1], И. Носенко [5] кебек галимнәрнең хезмәтләре эмоциональлекнең тел чаралары аша чагылышын өйрәнүдә мөһим урын алып тора. Методологик яктан структур-семантик анализ, контекстуаль интерпретация һәм компаратив ысуллар кулланыла. Бу ысуллар текстагы эмоциональлекнең төрле аспектларын – геройларның эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын һәм реакцияләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, эмоциональ фигыльләрнең кулланылышын тикшергәндә, компаратив анализ ярдәмендә, семантик яктан бердәй булган очракларда да, эмоциональлекнең төрле дәрәҗәләре ачыклана. Бу ысул текстның эмоциональ тәэсирен һәм укучыда тудырыла торган резонансны тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Р. Галиуллин әсәрләрендә эмоциональ лексика геройларның эчке дөньясын ачуда һәм тарихи-мәдәни контекстны күрсәтүдә зур роль уйный. Уңай эмоцияләрне белдерә торган лексика аеруча игътибарга лаек. *Шатлык* төшенчәсе әсәрләрдә киң таралган һәм *шатлану*, *сөенү*, *куану* лексемалары ярдәмендә чагыла. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *шатлану* сүзенә «Шатлык хисе кичерү, куану, сөенү, канәгатьлек хисе тою» дигән төшенчә бирелә [7: 679]. Бу сүзләр контекстка бәйле рәвештә төрле эмоциональ тирәнлекне күрсәтәләр:

1. Тышкы шатлык: *Аларны* ***шатланып*** *кабул иттеләр* [4: 64]. Бу җөмләдә шатлык тышкы күрсәткеч буларак, ягъни персонажларның күренеп торган хисләре аша чагыла.

2. Эчке тирән шатлык: *Ир бала туса, алар моны кешеләргә* ***шатланып*** *хәбәр иткән* [4: 174]; *Динә Мөстәкыймовна алтын тапкандай* ***шатланды*** [4: 270]. Бу мисалларда шатлык геройларның тирән кичерешләрен ача.

3. Канәгатьлек белән бәйле шатлык: *Остаз инде ул шәкертенең үзеннән уздыруын күреп* ***куана*** [4: 93]; *Ялчыгол хәзрәт... улының әле һаман да гыйлемгә сусавын күреп* ***куанды*** [4: 129]. Бу очракларда *куану* фигыле горурлык һәм канәгатьлек хисен белдерә.

Шатлык хисен белдерүче тагын бер мөһим лексема – *көлү*. Сүзлектә бу лексема «Шатлык, канәгатьләнү, күңеллелек белдерү» дип аңлатыла [7: 320]. Автор көлүне төрле конструкцияләр белән баета, бу эмоциональлекнең дәрәҗәсен күрсәтә:

1. Нәзакәтле, тыйнак көлү: *Кыз **тыйнак** кына көлде* [4: 171]; *Хәзер исә **чырык-чырык** көлә* [4: 274].

2. Көчле, чиксез шатлык: *Азат абый **кычкырып** көлде* [4: 291]; *Табиб, башын артка ташлап, чын күңеленнән **рәхәтләнеп** көлде* [4: 347].

3. Тәрбия дәрәҗәсе: *Габделкәримнең сүзләреннән ирләр тагын **шаркылдап көлде*** [4: 54].

Тискәре эмоцияләрне белдергәндә, *кайгыру*, *курку*, *ачу* кебек лексемалар актив кулланыла. *Кайгыру* сүзлектә «Кайгы хисе кичерү, хәсрәтләнү, борчылу» дип аңлатыла [7: 222].

Мәсәлән, еш кына бу сүзләр:

1. Пассив, көчсезлек белән бәйле кайгыны белдерә: *Габдерәхим бик **кайгырган**, әмма нишләсен* [4: 208].

2. Протест рухын чагылдыра: *Әби патша, губернатор өчен **кайгырмый** алар* [4: 30].

3. Конкрет курку объектын күрсәтә: *Бар **курыкканы** шул иде* [4: 52].

Автор әсәрләрдә курку хисен белдерү өчен еш кына *шүрләргә* фигылен дә куллана. Бу фигыль куркуның йомшаграк формасын белдерә: *Мәрьям абыстайның үз белдегенчә хәзрәтне вәгазьләп утырган иренең касыгына төртеп кисәтәсе килә, әмма **шүрли*** [4: 183]; *Ул үзе корт чагудан **шүрли*** [4: 362].

Кайгырту, борчылу хисләрен белдергәндә, *хафа* лексемасы, *хафалану* фигыле һәм *хафага кал-* конструкциясенең актив кулланылышы теркәлгән: *Миңлебикә Таҗеддин хәзрәтнең **хафасы** шул гына икәнен ишеткәч, сөенеп куйды* [4: 189]; *Инде утызга якынлашкан Җәмилә чын-чынлап **хафага** калды* [4: 328]; *Ул алда булачак хәлләр өчен артык **хафаланмады*** [4: 71].

Текстларда борчылу, курку хисләре шулай ук гарәп алынмаларыннан булган – *хәвеф* сүзе һәм *хәвефләнү* фигыле ярдәмендә дә белдерелә: *Әти – старшина, ул **хәвефне** алдан ук чамалый* [4: 150]; *Әллә сөенеп, әллә **хәвефләнеп**, ул тагын да суза төште* [4: 234]; *Тагын да **хәвефлесе** – шул наданнар әллә ниткән мисаллар уйлап чыгарып, халыкны дер калтыратып, ахырзаман белән куркытып тора* [4: 167].

«Васыять» китабында шулай ук *ачулану* төшенчәсен белдергән сүзләр дә киң урын алган. Сүзлектә бу төшенчә түбәндәгечә аңлатыла: «Ачулану – 1. кемгә яки нәрсәгә ачу килү, ачу тойгысында булу, бик нык үпкәләү. 2. Әрләү, орышу» [7: 57].

Әсәрләрдә әлеге фигыль йомшак ачуны белдерү өчен кулланыла: ***Ачуланма**, хәзрәт, изге догада бул, хәер-фатихаңны бир* [4: 148]; *Әй, мине **ачуланмагыз** инде* [4: 216]; *Миңа **ачуланма**, син әйбәт малай, үз итәм мин сине, – диде ул һәм кулын сузды* [4: 238].

Рөстәм Галиуллин еш кына, ачулану төшенчәсен белдергәндә, *сүгү* фигыленә дә киң урын бирә. Бу сүз көчле, агрессив ачуны чагылдыра: *Кычкырсын, **сүксен** иде ул – анысы берни түгел, әмма шулай тешен кысып, иренен тешләп кенә еламасын* [4: 241]; *Әгәр*

*тотып **сукса**, кычкырса, болай ук авыр булмас иде, бу сүзләре исә аңымны томалады* [4: 251]; *Аның кадәр үк **сукмә** инде аларны, Әтәч дус* [4: 359].

Әсәрләрдә тискәре хисне белдергән *елау* лексемасы да еш очрый: ***Еларга** ярамый иде* [4: 246]; *Үзем **елыйм**, үзем куркам, әмма авылга да кайтмыйча булмый* [4: 25]; *Аның әнисе Мәрьям турындагы юлларны **елый-елый** укый торган иде* [4: 18]; *Тәрәзә турысына чүгәләдем дә әллә нәрсәсенә Искәндәргә кушылып **елыйсым** килә башлады* [4: 240].

Елау хисе шулай ук үзенең күптөрлелеге белән аерылып тора һәм төрле конструкцияләр ярдәмендә белдерелә. Бу конструкцияләр дә геройларның эмоция дәрәҗәсен чагылдыру максатында кулланылалар. Мәсәлән, әсәрләрдә *иңрәп елау, акырып елау*, *өзгәләнеп елау*, *зар-зар елау*, *тыйлыгып елау, тәгәрәп елау* кебек конструкцияләр кайгының тирәнлеген һәм интенсивлыгын күрсәтә: *Вәли кинәт аны кочаклап алды да **иңрәп еларга** кереште* [4: 181]; *Әлеге сүзне ишеткәч, Аллаһияр **зар-зар еларга** керешә* [4: 201]; ***Акырып еларга** керештем* [4: 237]; *Бер үк вакытта шашынып-шашынып йодрык селкисе һәм **тыйлыгып-тыйлыгып елыйсы** килә* [4: 91]; *Сабирҗан кызы Өммегөлсем **өзгәләнеп елый*** [4: 148]; *...шул каенлык янында булсам, сикереп төшәм дә **тәгәрәп елыйм*** [4: 248].

Эмоциональ лексика әсәрләрдә тарихи вакыйгаларны һәм геройларның шәхси кичерешләрен берләштерүче күпер вазифасын да башкара. Елау, көлү кебек хисләрне тасвирлаган җөмләләр персонажларның хис-кичерешләрен моменталь рәвештә ачып бирә, шул ук вакытта укучыны әсәрнең эмоциональ атмосферасына чумдыра.

Еш кына әсәрнең телен төрләндереп җибәрү максатында, елау төшенчәсен белдергәндә, *күз яше* кушма сүзе ярдәмендә ясалган төрле конструкцияләр дә кулланыла: *Ул арада Вәли тагын **күз яшен түгә** башлады* [4: 182]; *Таҗеддин инде **күз яшен тыя** алмады* [4: 123]; *Ирнең **күз яше тәгәри** – ул аны сөртергә җыенмый да иде* [4: 332].

Бу төр фразеологизмнарның иске татар язма истәлекләрендә дә урын алуы авторларның телне тирән тоемлап, аның эчке мөмкинлекләреннән киң файдаланулары хакында сөйли: *Бу мискин, Мәүла Колый, **яшьләр түксен,*** / *Иман әйтеп, тәгать кылып, гомер кичсен* [1: 25].

*Куркырга*, *борчылырга*, *көләргә*, *еларга* кебек фигыльләр текстта еш кулланылып, геройларның дулкынлану, курку, шатлык яки кайгы хисләрен ачык күрсәтә. Бу фигыльләрнең актив кулланылышы укучыда эмоциональ резонанс тудыра һәм әсәрнең динамиклыгын арттыра.

Еш кына тикшерелә торган әсәр текстларында, кызгану хисен белдергәндә, *кызганырга* фигыленең актив кулланылуы күзәтелә: *Петров фамилияле укытучы Нугайбәкне... бу юлы да **кызганмады*** [4: 28]; *Олылап каршы алдың, ачык чыраеңны **кызганмадың*** [4: 146]; *Анда исә ул үз-үзенә мактауны да, тәнкыйтьне дә **кызганмады*** [4: 354].

*Көнләшү*, ягъни «Берәр кешенең уңышын яки уңай сыйфатын күреп, шул уңышка, уңай сыйфатына кызыгып карау; көнчелек барлыкка китерү» [7: 321] төшенчәсен белдергән лексемалар текстларда зур урын алган: *Нугайбәк шундук аңлады: күптән инде аның абруеннан **көнләшеп**, яшертен генә теш кайрап йөргән берничә сәләтсез малайның эше бу* [4: 27]; *Кара бу Миңлебикәне! – дип **көнләште** көн дә Аллаһы Тәгаләдән юньле кияү сораган кызлар* [4: 178]; *Сәбәбе һаман да шул бер: алар аның гыйлеменнән, халык арасындагы абруеннан **көнләште*** [4: 200].

Әсәрләрдә геройларның тартыну, кыймау, уңайсызлану тойгыларын белдергән очракта *оялу* лексемасы киң кулланыла: *Ир, **оялып**, нидер әйтмәкче булды, әмма ихтыяры җитмәде* [4: 21]; *Китсәнә, Әдрән, Казан галимнәре алдында **оялмыйча** тагын! Булмаганны, юк-юк!* [4: 260]; *...тавышымның үземә хас булмаганча сыекланып чыгуыннан **оялып**, карашымны өстәлдәге кәгазьләргә батырдым* [4: 339].

«Васыять» китабында *кыенсыну* лексемасы да шул ук хисне белдергәндә актив кулланыла. Бу сүз әлеге хисне *оялу* лексемасына караганда, йомшаграк формада белдерә: *...сиңа иде, – диде Таҗеддин, **кыенсынып** кына* [4: 150]; *Шул арада Габдерәхим хәзрәт **кыенсынып** басып торган Таҗеддин хәзрәтне кочаклап алды* [4: 133]; *Кирәк булганда мөрәҗәгать итегез, **кыенсынмагыз*** [4: 342].

Текстларда эмоциональ лексика психологик портрет ясауда зур роль башкара. Эмоциональлек белән сугарылган фигыльләр аша каһарманнарның эчке дөньясы, аларның реакцияләре һәм хисләре ачыла. Канәгать булу – кешенең иң яхшы сыйфатларыннан берсе. Автор әлеге халәтне укучыга *канәгать калу*, *канәгать булу* конструкцияләре ярдәмендә җиткерә: *Бу җаваптан Габдерәхим хәзрәт бик **канәгать** калды кебек* [4: 225]; *Инде барыннан да **канәгать** булдым дип уйлыйсың* [4: 169]; *Якут агае **канәгать** көлемсерәде* [4: 303].

Әмма сирәк кенә булса да текстларда канәгать булмау очраклары да тасвирлана: *Ул күзен кәгазь буйлап йөгертте – укыган кадәресе күңелендә **канәгатьләнү** хисе тудырмады булса кирәк* [4: 155]; *Казанцев **канәгатьсезлек** белән йөзен җыерды* [4: 153]; *Бу эш миңа һич тә **канәгатьлек** бирми* [4: 239].

Кичерү, ягъни «...кемнең дә булса берәүнең, бер тарафның хатасы, явызлыгы, рәнҗетүе, начар эше, һ. б. өчен җәза, үч ниятеннән баш тарту; гафу итү» [7: 260] хисен чагылдырган *кичерергә* фигыле, *гафу кыл-*, *гафу ит-*, *гафу үтен-* кебек конструкцияләр әсәрләрдә киң урын алган. Аларның кулланылышында семантик яктан яки эмоциональлекне белдерүдә аермалар күзәтелми: *Нугайбәк, адәм баласы хатадан хали түгел. **Кичерә** белергә кирәк* [4: 63]; ***Кичерерлек** дип табасыз икән – җибәрегез; Җәза тиешле икән – бирегез* [4: 54]; *Бәндәчелек белән ачык кылган, яшерен кылган, белеп кылган, белми кылган барча гөнаһларыбызны да **гафу кылсана*** [4: 108]; *Шушы бәндәңә*

*рәхмәтләреңне иңдер, гөнаһларын* ***гафу ит****!* [1: 113]; ***Гафу итегез,*** *Җәмилә Җәлиловна* [4: 231].

Автор, кайгы-хәсрәт кичерүче кешене тынычландыру, күңелен күтәрергә тырышу, елаудан туктатуны белдерү максатында, әсәрләрендә еш кына *юату* сүзен куллана: *Әмма ни әйтергә, үзен ничек* ***юатырга*** *белмәүдән гаҗиз иде* [4: 200]; *Искәндәр үзен артыннан калмыйча* ***юатып*** *йөри* [4: 286]; *Үзебез өчен яшәп калыйк әле, – дип* ***юатты*** [4: 328].

Язучы еш кына үкенү хисен укучы колагына *үкенеч* сүзе һәм *үкенергә* фигыле ярдәмендә җиткерә: *Элеккеге гамәлләре өчен* ***үкенәдер*** [4: 62]; *Үзе дә* ***үкенәдер*** [4: 63]; *Бер генә...* ***үкенечем*** *кала...* [4: 344]; *Бернәрсәгә дә* ***үкенмим*** [4: 356].

Шул ук мәгънәгә якын булган хисне белдерүче *тәүбә* сүзе һәм *тәүбә ит-, тәүбәгә кил-* конструкцияләре дә әсәрләрдә еш күзәтелә: *Бәлки, чыннан да, мин уйлаганча,* ***тәүбә иткәндер*** [4: 63]; *Ялгышуым да бар, аннары, бәлки, адәм баласы* ***тәүбәгә килгәндер****?* [4: 62]; ***Тәүбә, тәүбә****, диген, Хәсәнҗан!* [4: 25] Аларның кулланылышында семантик яктан яки эмоциональлекне белдерүдә аермалар күзәтелми.

«Персонажның яисә лирик геройның кылган эшләренә үкенү, тәүбәгә килүе белән бәйле хис-кичерешләре дә суфи шагыйрьләр иҗатында еш яктыртыла: *Бозык эшне куйасы, изге эшне йулласы, / Бозык эшдин тәүбә кыйлдым, Хак йулында буласы»* [3: 26].

Геройларның сагыну хисен кичерүләрен, ягъни «...элек белгән кешене, күрелгән берәр әйберне, яки үткән хәлне, уңай ягы белән искә төшереп, аны юксыну хисе кичерү» [7: 457] тойгысын тасвирлаганда, язучы еш кына *сагынырга* фигыленә мөрәҗәгать итә: *Саҗидәне уйламаган,* ***сагынмаган*** *көне юк* [4: 103]; *Мөхәммәдшакир оныгымны бик* ***сагындым*** [4: 230]; *Гыйззәтулла гаиләсен* ***сагынган*** *иде* [4: 219]; *Әти, әти, мин сине* ***сагындым****!* [4: 344].

Тикшерелә торган әсәрләрдә персонажларның эмоциональ һәм психик халәтен белдерүче сүзләрнең еш кулланылуы турыдан-туры психологизм кебек сәнгати алымның активлыгын күрсәтә.

Тискәре эмоцияләр шулай ук *эт, шайтан, җен* кебек экспрессивлык белән сугарылган сүзләр ярдәмендә дә белдерелгән очраклар бар: ***Эт*** *икәнсең, малай, ну да!* [4: 297]; *Кит, кеше көлдермә, карт* ***шайтан****!* [4: 351]; *Их, әйләндереп каплыйсы* ***җен*** *хатыны!* [4: 373]; ***Җен*** *карчыгы тәки эштән алдырган икән!* [4: 300]; *Мин ул кашын песи ялаган* ***җен*** *хатынын тирмәсе-ние белән алаһадан чыгарып ташлыйм! – дип, әрле-бирле йөренеп алды* [4: 310].

Тискәре эмоция еш кына *хәйләкәр* яки *карт төлке* сүзтезмәсе белән дә белдерелергә мөмкин. Бу сүзтезмәләр хәйләкәр кешеләргә, аларның начар эшләрен фаш итүгә мөнәсәбәтле кулланыла*: Тик* ***хәйләкәр төлке*** *Кыдрач сүзендә тормый* [4: 62]; ***Карт төлке*** *Мертвецов утлы табага басканмыни...* [4: 65]; *Шунда башың бетсен,* ***карт төлке****!* [4: 67]; *Ул бу* ***хәйләкәр төлкенең****... Вәлитне тотып бирергә вәгъдә бирүләрен уена да кертеп карамаган иде* [4: 86].

Сарык һәм ат кебек хайваннарны белдерүче сүзләр катнашкан түбәндәге җөмләләр дә тискәре эмоция белән сугарылган. *Сарык* сүзе бу очракта «юаш, надан кеше» [5: 464] мәгънәсен үз эченә алган: *Нугайбәк аңлады: әйе, алар өчен халык –* ***сарык****, болар бары тик үз иминлеген генә кайгырта* [4: 31]; *Димәк, фетнә халыкны тәмам* ***сарыкка*** *тиңли башлаган хөкүмәт кешеләренең күңеленә курку оеткысын шактый ук салган булып чыга* [4: 100]; *Патшасы халыкны сөйми, аңа ышанычы юк,* ***сарыкка*** *караган кебек карый* [4: 220]; *Ат хәтле, ат кебек* дигән чагыштыру зур, таза гәүдәле кеше [7: 53] мәгънәсен белдерү өчен кулланылган: *Әллә* ***ат хәтле*** *малайның имчәгеңне тотып ятуын телисеңме?* [4: 24].

Текстларда «әшәке, җирәнү хисе тудыра торган кеше» [5: 216] мәгънәсен белдергән *кабахәт,* «җәбер-золым күрсәтүче; явызлык эшләүче; явыз көч» [5:33] мәгънәсендәге *албасты,* «бик усал, явыз кешегә карата әйтелә» [5:25] торган *аждаһа* сүзләре дә тискәре эмоция белдерү өчен кулланыла: ***Кабахәт****! Мин аны шушы кулларым белән!* [4: 63]; *Теге* ***кабахәт*** *аны халыкка өләшүдән тыйды* [4: 30]; *Өсләренә төрле ертык-сәләмә киеп, кулларына сәнәк, чалгы, казык тоткан бу ирләр Осип күзенә урман* ***албастылары*** *булып күренә башлады* [4: 53]; *Хәзер дөресен әйт: сине абыйның* ***аждаһасы*** *рәнҗетәме? – дип сорап куйды* [4: 310].

Эмоциональлек әсәрләрдә еш кына хуплауны белдерүче *валлаһи, билләһи,* канәгатьләнү хисен белдерүче *менәтерәк,* сукрануны белдерүче *каһәр суккан,* шатлык билгесен белдерүче *рәхмәт төшкере* кебек ымлыклар белән бирелгән очраклар да күзәтелә: *Нәкъ син инде,* ***валлаһи****!* [4: 254]; *Әгәр кемдер мине читтән карап торса, хәйран калыр иде,* ***билләһи*** [4: 237]; ***Рәхмәт төшкере,*** *әтисенең дусты сүзчән, иң мөһиме, тарихтан хәбәрдар кеше иде* [4: 115]; *Менә Казан артында Аты юлы бар, анда сикергәләп кенә барасың инде* ***менәтерәк*** [4: 5]; *Ә беркөнне... шул* ***каһәр суккан көнне****... Җиһанның башында яман шеш тапканнар* [4: 330].

Эмоциональлек һәм экспрессивлыкны белдерүдә стилистик *-чык/-чек, -кай/-кәй, -кәш* кебек кушымчаларның да роле зур. Алар, нигездә, уңай эмоцияләр тудыру максатыннан ярату, иркәләү хисләрен белдерү өчен кулланылалар [6: 240]: *Әбиләрем шулкадәрле зиннәтле күлмәкләрне күреп аһ итте. –* ***Әнекәчкәем*** *лә генә*! [4: 291]; *Ашыкма әле,* ***җанкисәккәем*** [4: 335]; *Әй остазым,* ***кызчыгым*** *бер дә умартадай гөжләми, татлыдан татлы бал сыман* [4: 93]; *Менә яучы җибәртим генә, атаң шунда ук риза булыр,* ***кошчыгым*** [4: 179]; ***Кызчык*** *җавап көтә иде. – Мин дә... сезне сагындым, кызым* [4: 345]; *Аннан өйдә* ***энекәш*** *кала барыбер* [4: 247]; *Мин аңа: «Сиңа* ***энекәш*** *алып кайтабыз», – дигәндә, мәчеттә азан әйтә башладылар* [4: 334]; *Әй* ***балакаем****! ...Мин дөньядан үткәч, каберемне ялгыз калдырма* [4: 8].

Рөстәм Галиуллинның «Васыять» китабына кергән әсәрләрдә эмоциональ лексика татар әдәбиятының бай мөмкинлекләрен

күрсәтүче үрнәк булып тора. *Шатлану*, *көлү*, *кайгыру*, *курку*, *ачу*, *елау* кебек лексемалар һәм аларның төрле синтактик формалары геройларның эчке дөньясын, кичерешләрен һәм реакцияләрен ачык күрсәтә. Экспрессив сүзләр (*эт*, *шайтан*, *җен*) һәм фразеологик чаралар (*күз яше түгү*) текстка халыкчан төсмер өсти, ә *-чык*/*-чек, -кай*/*-кәй* кебек кушымчалар уңай эмоцияләрне ярату һәм иркәләү хисе белән сугара. Эмоциональ лексика тарихи вакыйгаларны һәм геройларның шәхси кичерешләрен берләштерүче күпер вазифасын башкара, укучыны әсәрнең эмоциональ атмосферасына чумдыра. Шулай итеп, Рөстәм Галиуллин әсәрләре татар халкының рухи байлыгын, каһарманнарның тирән кичерешләрен чагылдыруда эмоциональ лексиканың зур әһәмиятен ассызыклап күрсәтә. Бу тикшеренү әсәрләрнең семантик һәм эстетик үзенчәлекләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә, шулай ук татар әдәбиятының эмоциональ тел байлыгын күрсәтә.

**Әдәбият**

1. *Арутюнова И.Д.* Предложение и его смысл. М.: Наука, 1976. 383 с.

2. *Балли Ш.* Французская стилистика. М.: Изд-во иностр. лит., 1961. 394 с.

3. *Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр искетатар язма истәлекләрендә тотрыклы сүзтезмәләр // Фәнни Татарстан. 2024. № 3. Б. 22–30.

4. *Галиуллин Р.Г.* Васыять. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 367 б.

5. *Носенко Э.Л.* Особенности речи в состоянии эмоциональной напряженности. Днепропетровск: Изд-во Днепропетров. ун-та, 1975. 132 с.

6. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

***Гыйлемшин Флер Фоат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гилемшин Флер Фоатович,***
*доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ, ведущий научный сотрудник Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук»*
*Fler.Gilemshin@yandex.ru*

УДК 811.512.145

***Ә.Р. Мотыйгуллина***

# СПОРТ ТӨШЕНЧӘЛӘРЕН КЛАССИФИКАЦИЯЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Данная статья посвящена изучению спортивной терминологии на татарском языке в историческом ракурсе. Классификация спортивных терминов является важным аспектом для спортивной лексики, который позволяет систематизировать и упорядочить специализированную терминологию различных видов спорта. Структурированная система классификации терминов способствует более эффективному изучению и использованию спортивного языка. В данной работе рассматриваются основные подходы к классификации спортивных терминов, включая их структурные, функциональные и этимологические характеристики. Основываясь на исследования ученых, делается попытка систематизации спортивных понятий. Особое место уделяется изучению заимствованной лексики в спортивной сфере. Кроме этого, изучая разные классификации спортивной лексики и терминообразования теоретиков-филологов, предлагается систематизировать спортивные термины, разделяя их на игровые, циклические и ациклические виды спорта. Терминообразование в спортивной отрасли является средством обогащения национальной лексики. Целью данной работы является изучение спортивных терминов в историко-этимологическом аспекте, их систематизация и создание комплексной модели классификации, которая поможет исследователям, тренерам и спортсменам лучше понимать и использовать в практической деятельности. Новизна темы заключается в выработке критериев и структуры единой системы классификации спортивных терминов с учетом лингвистических, этимологических и семантических факторов. Также в выявлении новых проблем, возникающих при классификации терминов, обусловленных интенсивным заимствованием из других языков, развитием информационных технологий и изменениями в спортивной практике. Практическая ценность классификации заключается в возможности её применения для обучения, перевода и систематизации информационных ресурсов, связанных со спортом.

**Ключевые слова**: этимология, спортивные термины, словообразование, языковые явления, классификация, игровые виды спорта, циклические виды спорта, ациклические виды спорта.

This article is devoted to the study of sports terminology in the Tatar language from a historical perspective. Classification of sports terms is an important aspect for sports vocabulary, which allows to systematize and organize specialized terminology of various sports. A structured system of classification of terms contributes to more effective study and use of sports language. This paper examines the main approaches to the classification of sports terms, including their structural, functional and etymological characteristics. Based on the research of scientists, an attempt is made to systematize sports concepts. Special attention is paid to the study of borrowed vocabulary in the sports field. In addition, studying different classifications of sports vocabulary and term formation of theoretical philologists, it is proposed to systematize sports terms, dividing them into game, cyclic and acyclic sports. Term formation in the sports in-

dustry is a means of enriching the national vocabulary. The aim of this work is to study sports terms in the historical and etymological aspect, their systematization and creation of a comprehensive classification model that will help researchers, coaches and athletes to better understand and use in practice. The novelty of the topic lies in the development of criteria and structure of a unified system for classifying sports terms taking into account linguistic, etymological and semantic factors. Also in identifying new problems that arise in classifying terms due to intensive borrowing from other languages, the development of information technology and changes in sports practice. The practical value of the classification lies in the possibility of its application for teaching, translation and systematization of information resources related to sports.

**Keywords:** etymology, sports terms, word formation, linguistic phenomena, classification, game sports, cyclic sports, acyclic sports.

Бүгенге көндә безнең тормышыбызны иңләп алган өлкәләрнең берсе булган спорт белән бәйле төшенчәләрнең барлыкка килүенә, таралышына, кулланылыш даирәсенә күзәтү ясау тарихи, мәдәни аспектка бәйләп өйрәнүләрне таләп итә. Әлеге мәкаләдә спорт төшенчәләрен өйрәнү максаты куела. Бурычлар – терминнарны тарихи аспектта барлау, спорт төшенчәләрен төркемләү мәсьәләсенә, бу юнәлештәге эзләнүләргә күзәтү ясау, спорт һәм мәдәниятнең уртак нигезләрен эзләүдән гыйбарәт.

Татар телендәге спорт терминнары системасын камилләштерергә омтылыш, спорт белән бәйле атамаларның кулланылыш даирәсе киңәю, төрле милләтләрнең үзара аралашу чарасына әверелүе аларны система буларак өйрәнү мәкаләнең актуальлеген дәлилли.

Спорт белән бәйле төшенчәләрне төрлечә төркемләүләр күзәтелсә дә, күп кенә тикшеренүче галимнәр аларны спорт терминнары системасы кысаларында карарга тәкъдим итәләр. Шуңа күрә аларны аерым өлкә, ягъни физик культура һәм спорт атамаларын махсус өйрәнүче өлкә буларак аерып чыгару сорала. Әлбәттә, спорт атамалары тел-сөйләм үзенчәлекләренә ия, лексик-семантик яктан да үзгәреп тора.

Спорт терминнарының классификациясе «Спорт терминнары сүзлеге»ндә бирелә: 1) су спорты төрләре (йөзү, суга сикерү, синхрон йөзү, су полосы, су асты спорты); 2) хәрби спорт төрләре (парашют спорты, ориентирлашу, чик сакчылары өчен ориентирлашу, диңгезчеләр өчен йөзү һәм ишкәк ишү); 3) Олимпия уены төрләре а) һөнәри (альпинизм, ат чабышы); ә) тизлек һәм көч салуга корылган спорт төрләре, циклга корылмаган спорт төрләре (сикерү, ядрә ату, авыр атлетика, гер спорты) һәм циклга корылган спорт төрләренә (кыска аралыкка йөгерү, каршылыклар белән йөгерү, тимераякта йөгерү, велосипед спорты) керә; б) тизлекне саклауга корылган спорт төрләре (нәфис гимнастика, акробатика, суга сикерү, синхрон йөзү, фигуралы шуу); в) циклга корылган спорт төрләре: йөрү, йөгерү, йөзү, чаңгы спорты, тимераякта йөрү, велосипед спорты һәм ишкәк ишү [15: 44–45]. Сүзлек авторлары спорт төшенчәләренең тулы бер системасын

булдыруны максат итеп куйганнар. Әлеге сүзлек башка төрле махсус спорт сүзлекләреннән спорт төшенчәләре белән бәйле атамаларның этимологиясен өйрәнү юнәлеше белән аерылып тора. Кайбер мисалларга тукталып узыйк.

1. Теннис [тэ]ннис, а, м. [англ. tennis < франц. tenez держите, поймайте] 1. Олимпия уен төре: кортта уйнала торган, тәбәнәк сетка аша ракетка белән кечкенә тупны сугып чыгаруга корылган. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен дә адаптацияләнгән уен. *Теннис мәктәбе. Өстәл теннисы* [15: 303–304].

2. Футбэг, а, м. [англ. footbag < foot нога + bag мешок] Спорт төре: уенның максаты каты гранулалар тутырылган кечкенә тупка аяк белән тибеп, җиргә төшермичә алып бару. *Футбэг буенча дөнья чемпионаты* [15: 334].

Сүзлектә спорт төшенчәләренең килеп чыгышы гына түгел, ә этимологик эзләнүләр өчен классификация дә аерым параграфларга бүлеп бирелә (татарчага тәрҗемәләр. – *Ә.М.*). Мәсәлән,

§ 27. «Этимология чикләрендә сүзнең семантикасы үсү һәм таралуын ачыклауга багышланган тарихи һәм географик белешмәләр дә бирелергә мөмкин. Спартакиада [Спартак исеменнән (лат. Spartaks: б. э. к. 110–71) Рим колларының юлбашчысы булган [15: 28].

§ 28. Этимологик белешмә этимонның катлаулы төзелеше турында белешмә бирә: бу очракта сүзнең компонентлары + график тамга белән санап барыла.

Слалом ...[норв. Slalom< Sla склон (авышлык) + lam тропинка (сукмак)] [15: 28].

3. Ушу ... [кит. wŭshŭ < wŭ военный (хәрби) +shú искусство, метод (сәнгать, ысул)] [15: 29].

§ 29. Әгәр берәр сүз катлаулы сүз составына керә икән, ул турыдагы мәкалә киңрәк бирелгән өлештәге вокабуланы карау юлы күрсәтелә.

4. Автогол ...[ греч. < autos сам + гол] [15: 28].

§ 30. Әгәр сүзнең нигезе кушма сүз составына керми икән, кыскартылган өлеше этимология зонасында түгәрәк җәяләр эчендә бирелә:

5. Бич-волей... [англ. Beach< wolley пляж + (ball) волейбол] [15: 28].

§ 31. Башка телләрдән алынган аббревиатуралар булса, этимологик белешмәдә этимон һәм аның таркатылган аңлатмасы бирелә.

6. УЕФА… [англ. UEFA < сокр. Union European Football Associations Союз Европейских футбольных ассоциаций] [15: 29].

§ 32. Әгәр сүз рус телендәге кыскартылма булса, бу телдә сөйләшүчеләр өчен аббревиатура булып аңлашылса, этимология чикләрендә квадрат җәяләр белән бирелә.

7. Самбо.. [сокр. Самооборона без оружия (коралсыз үз-үзен саклау)] [15: 29].

§ 33. Сүзлектә латин хәрефләре белән язылган сүзләр очраганда (чыганак сүз орфографиясендәге сыман), шулай ук алынма сүзнең семантикасын һәм килеп чыгышын ачыклаган этимологик белешмә бирелә.

8. FMX... [англ. FMX < сокр. Freetyle Motocross < frestyle фристайл +motocross мотокросс] [15: 29].

Ә татар телендә исә спорт атамаларының килеп чыгышына багышланган фундаменталь махсус эзләнүләр аерым мәкаләләр рәвешен ала. Аерым төшенчәләрнең сүзьясалышын өйрәнүгә тикшеренүче Л.К. Ишкинина игътибар итә. Ул *-даш*/*-дәш* аффиксларының, исем сүз төркеменә кушылып килеп, бердәмлекне, уртаклыкны белдерүен билгели. Мисалга *көндәш команда* төшенчәсен китерә. Автор спорт төшенчәләренең сүзьясалыш үзенчәлекләрен тикшерә. Моннан тыш Л.К. Ишкинина хоккей уен төрендә *алка, капка, рефери, калкан, һөҗүм* тамыр сүзләре һәм *перчатка-тозак, казый-хронометрист, судья-информатор, тайм-аут* парлы сүзләре мисалларында татар телендә сүзьясалышының төрле ысулларын ачыклый [8: 90].

Татар телендә сүзләрнең этимологиясен өйрәнүнең [5: 11–37] теоретик нигезе турындагы мәгълүматны спорт төшенчәләренең тарихи-этимологик асылын эзләүдә файдаланып була. Моннан тыш әлеге мәгълүмати чыганакта спорт белән бәйле фикерне «Күперчекләр ысулы» теориясен аңлаткандагы мисалда очратабыз. «Кирәкле мәгълүмат – күперчек бүтән төрки телләрдә юк, ул удмурт телендә табыла: маташ (мата-шыны) «көрәшкәндә аяк чалу (чалышу), шундый (көрәштә тыелган) ысул белән җиңмәкче булу» – «бер-береңне матау» [5: 17]. Димәк, милли спорт төре булган көрәшнең тыелган алымы әлеге теорияне ачуда мисалга китерелә.

Әлеге хезмәт кысаларында этимологик эзләнүләрне тарихилык принцибына бәйләп карау күзәтелә. Аның бер таләбе – «1) ретроспективлык (үтелгән юлга карау)». Моны галим эздәнлек принцибы дип атый [5: 17–19]. Бу принцип нигезендә күп кенә спорт төшенчәләренең этимологиясен өйрәнү мөмкинлеге туа. Эздәнлек принцибы спорт терминнарының килеп чыгышын ачу нигезе белән тәңгәл килә. Мисалга Россиядә беренчеләрдән булып таралган спорт төре булган фехтованиене алыйк.

Иң элек фехтование Испаниядә барлыкка килә. Аның нигезендә шпага һәм рапира белән идарә итү осталыгы ята. Ул күп кенә илләрдә дуэльләр таралуга да сәбәп була. Соңыннан Италия, Франция, Германиядә шпага белән идарә итү буенча беренче милли мәктәпләр оеша башлый. XVII гасырдан башлап, Франция дөнья фехтованиесенең үзәгенә әверелә. Әгәр Италия мәктәбендәге фехтование коралын кисү, яру, турау (рубящее оружие) өчен файдалансалар, Франциядә төртүгә, чәнчүгә (колющее оружие) нигезләнгән методика эшләнә. Аның яңа теоретик базасы барлыкка килә. Шуңа күрә фрунцуз теле фехтованиенең рәсми теле булып исәпләнә башлый. Ул чиксез попу-

лярлык казана. Шуның нәтиҗәсендә ул 1896 елдан Олимпия уеннары программасына кертелә.

Россиядә «шпага сәнгате» белән кызыксыну XVII гасырдан башлана. Аны Пётр I үз даирәсендәге кешеләргә, хәрби һәм башка уку йортларына «Рапира фәне» дип кертергә тәкъдим итә. XIX гасыр башында «Сөңге (штык) белән фехтование сәнгатенең кагыйдәләре» эшләнә. Ул Россиядә барлык хәрби әзерлеккә корылган уку йортлары, кадет корпуслары программасына мәҗбүри фән буларак кертелә. 1855 елда Петербургта гвардия корпусының фехтование-гимнастика залы ачыла. 1860 елда исә фехтование буенча беренче рәсми Россия чемпионаты уза һәм башка күптөрле ярышлар оештырыла. Совет власте елларында фехтование популярлыгын югалтмый. Физкультура уку йортларында фехтование буенча махсус тренерлар белем алып чыга. 1935 елда Ленинградта (хәзерге Санкт-Петербург) фехтованиедән беренче балалар спорт мәктәбе ачыла.

Фехтование түбәндәге төрләргә бүленә: хәрби фехтование; спорт фехтованиесе; тарихи фехтование; паралимпия фехтованиесе; сәхнә фехтованиесе; бугут көрәше (күмәк көрәш) [16].

Галим татар теленең этимологиясен өйрәнүнең күп якларына туктала. Телдәге бик күп сүзләрнең, гыйбарәләрнең аңлатмалары арасында кайбер спорт атамаларын да очрата алабыз. Мәсәлән, «Иш-ү «грести, вить; бежать иноходью (вообще попеременно работать то справа, то слева)», «работать лопатой, разрушать» < чув. иш- «җимерү; йөзү» < гом. төрки эш-, äш- < *алч-> болг. *ал- > чув. ал- «казу; сөрү». Бу сүзнең исем корреляты иш (к.). ЭСТЯ I: 315–317; Федотов I: 32, 175. Иш- продуктив нигез: ишел-ү, ишелдер-ү, ишерр-ү, ишкәк ишмә» [5: 319]. Шулай итеп, *ишү* белән бәйләп спорт төшенчәсе булган *ишкәк ишү* атамасының этимологик нигезләре дә ачыла.

Әлбәттә, спорт белән бәйле төшенчәләр бик аз бирелсә дә, этимология теориясендә алынма сүзләр турындагы материал урнаштырылган. Шуңа нигезләнеп, спорт атамаларының бик күбесе алынма сүзләр булуын истә тотып, аларны өйрәнү юлларын ачыклый алабыз.

Спорт терминнары арасында рус һәм татар телләренә чит иләрдән кергән алынмалар күп. Аларның үзенчәлекләрен билгеләп, Р.Г. Әхмәтьянов «Алынма төшенчәсе үзе дә катлаулы. Безнең сүзлекләрдә, гадәттә, турыдан-туры алынма чыганагы, ягъни татар теленә турыдан-туры кайсы телдән кергәнлеге күрсәтелә. Ул телдә әлеге сүз үзе икенче бер телдән, икенче телдәге сүз өченче телдә һ. б. алынма булырга мөмкин», – дип белдерә [5: 30]. Мәсәлән, дөньяда киң таралган футболны алыйк. «Футболга охшаган беренче уен якынча 5000 ел элек Борынгы Кытайда барлыкка килгән. Ул дзюню («дзу» – тибү, «ню» – туп) дип аталган. Ул вакытта һәр команда составына иллешәр уенчы кергән, капкалар саны да алтау булган. Туп авырлыгы 5 кг тәшкил иткән. Җиңүчеләрне чәчәкләр, кыйммәтле савыт-саба белән бүләкләгәннәр. Борынгы Спартада футболга охшаш уен – эпискирос, Борынгы Римда харпастум дип аталган. XIV гасырда

Италиядә кальчо уены барлыкка килә. Тора-бара ул Англиягә үтеп кергән» [11: 6]. Шулай итеп, без инглиз теленнән килеп кергән дип уйлый торган футбол шактый юллар үткән. Аның килеп чыгышыннан бигрәк, соңгы исәптә термин инглиз теленнән кергән дип карала. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дә шул фикерне дәлилләп, аның спорт уены булуына басым ясый: «Футбол. Уен вакытында һәр команда каршы яктагы капкага аяк белән тибеп (яки баш белән бәреп) мөмкин хәтле күбрәк туп кертүдән гыйбарәт командалы спорт уены» [13: 356].

Спорт терминнарының чит телләрдән керүен Н.А. Аякулов та дәлилли. Үсеш дәверендә спорт өлкәсендәге терминнар чит телләрдән алынган төшенчәләр белән тулылана. Фән өлкәләренең кушылып китүе һәм гомуми тикшерену предметы һәм ысуллары булу сәбәпле, күп кенә алынмалар телгә үзгәрешсез килеп керәләр, ягъни үзләренең төп вазифаларын һәм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә. Бу нисбәттән спорт теле күп кенә лингвистларның игътибар үзәгендә тора» [4: 13]. Автор, үз фикерен раслап, 100 ләп терминны мисалга китерә. Димәк, спорт белән бәйле терминологиянең алынма сүзләр булуын ассызыклаучы дәлилләр китерә.

Спорт төшенчәләренең этимологиясен системалаштыру, аларны бер тирәгә җыю гомуми атамалар булган *спорт* һәм *физик культура*дан башлана. Моның ачык мисалы белән тикшеренүче В.В. Кругловның спорт сүзен өйрәнүгә багышланган махсус мәкаләсендә очрашабыз. Аның фикеренчә, спортның башлангычы – Борынгы Мисырдагы б. э. к. 3 меңьеллыкта тарихчы Геродот хезмәтләрендә. Гомерның «Илиада», «Одиссея» поэмаларында грекларның ат чабышы, бокс, йөгерү, уктан ату буенча ярышларда катнашулары искәртелә [9: 45]. Соңыннан бу уеннар гасырлар дәвамында киңәеп һәм үсеп, күп функцияле иҗтимагый-мәдәни феномен буларак формалашканнар. Аларның иң популярлары Олимпия уен төрләренә кертелгән. Ә бәйгеләрдә җиңүчеләргә исә бу титул гомерлеккә бирелгән, хәтта аларга һәйкәлләр дә куя торган булганнар [9: 45–46].

Татарларда исә спорт уеннарының башлангычы Урта гасырлар белән бәйләп карала һәм спортның башлангычы дип милли уен төрләре атала. Ул татар халкының иң зур бәйрәме булган Сабантуйга барып тоташа. Башка вакытларда да хәрәкәт итү, уеннар оештыру, йөгерү, сикерү, чыдамлык сыйфатлары тәрбияләү даими рәвештә кешелек тормышының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән. Педагогика тарихын өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләрендә дә татар, башкорт һәм башка халыкларда спортның башлангычы турындагы мәгълүматлар күп очрый.

Тарихи чыганакларда спортның беренче билгеләренә кагылышлы мәгълүматлар Урта гасырларга бәйле рәвештә сакланып калган. XIII гасырда болгар-кыпчак төрки егете Лачын Хисам ниндидер сәбәпләр аркасында коллыкка төшә. Аннары Мисыр байларының берсе аны базарда сатып җибәрә. Егет җыйнак гәүдәле, ышанычлы,

зирәк күренә. Тиз арада укырга-язарга өйрәнә. Риязәт-тән тәрбиясе һәм сәясәт, ягъни ил белән идарә итү, оештыру гыйлемнәрен тиз үзләштерә. Ирешкән уңышларын, оештыру эшләре белән кызыксынуын искә алып, егетне Мисыр солтанының сарай хезмәтенә алалар. Шул чаклардан бу кеше риязәт-физкультура, спорт, сугыш һөнәрләре буенча зур тәҗрибә туплый. Ул гарәп телендә әлеге хезмәтнең фәнни-гамәли нигезе булган «Төхфәтел-моҗаһидин фи-л-гамәли-л-мәядин» («Мәйдан эшләре буенча ярышчы-көрәшчеләргә бүләк») дип аталган китап та яза. Аны төрки-кыпчак-болгар теленә дә тәрҗемә итеп, кулланылышка кертеп җибәрәләр [6: 13].

Бу исә болгар-кыпчак төркиләренең элек-электән спорт, физкультура-тән тәрбиясе белән кызыксынуларын күрсәтә. Алар бу эшләргә хосусый яки очраклы бер күренеш итеп кенә түгел, ә җәмгыятьнең кирәкле эше дип караганнар. Балаларны, бигрәк тә ир балаларны, кече яшьтән, тиз йөгерергә, суда йөзәргә, югарыдан сикерә белергә, ат өстендә төрле хәрәкәтләр ясарга, баулар-колгалар буйлап югары үрмәләргә, ук-җәядән төз атарга, җиңел гәүдә белән авыр гәүдәне күтәрә, көрәшеп җиңә белергә күнектерә торган булганнар. Бу турыда XIV йөз шагыйре Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» китабында риязәт-физкультура фәннәренә өйрәтүче махсус остазларга хөкүмәт тарафыннан хезмәт хакы түләнүе искәртелә. Китапка «Көрәшче пәһлеван» дигән хикәят тә кертелгән. Анда бер пәһлеванның өч йөз алтмыш төрле көрәш ысулын белүе һәм үз шәкертләренә өйрәтүе бәян ителә. Пәһлеван бер шәкерте белән аеруча дуслашып китеп, аңа 359 төрле көрәш ысулын өйрәтә. Соңыннан шәкерт үзенең остазы белән көч сынашырга теләк белдерә. Ул остазның җиңүе белән тәмамлана [12: 91–92].

Төрле халыклар арасында киң таралган спорт төшенчәләрен җыю, туплау, системалаштыру ихтыяҗы да туган. Шуңа күрә спорт атамаларының этимологиясен өйрәнүгә, спорт лексикасын барлауга караган фәнни-теоретик хезмәтләрдә соңгы исәптә классификация ясарга омтылыш бар. Спорт лексикасын гамәли юнәлештә өйрәнүче Д.Ю. Антонова исә терминологияне өчкә бүлеп өйрәнү юлын тәкъдим итә: 1. Гомумспорт лексикасы: рекордсмен (югары нәтиҗәләргә ирешкән спортчы), нәтиҗә (спортчының һөнәри осталыгы), олимпиада, адаптация (организмның хәрәкәтләр ясауга яраклашуы). 2. Берничә спорт төренә хас терминнар: аут, бассейн, ыргыту, капкачы, капка, шугалак, фланг. 3. Аерым бер спорт төренә генә хас төшенчәләр: әйтик, бокста – боксер, нокаут, ринг, андеркарт; футболда – бутс, мундиаль һ. б. иң күп төшенчәләр җиңел атлетика, футбол, фигуралы шуудa очрый [2: 91–92].

Спорт төшенчәләрен төркемләүне Е.И. Гуреева да үзенең хезмәтендә системалы өйрәнә. Ул спорт төшенчәләрен классификацияләп, 4 төркемгә аера: 1) гомумфәнни һәм башка өлкәләрдән алынган өлкәара төшенчәләр (психологик әзерлек, физик әзерлек (медицина), пассә, релеве (сәнгать), парус, рессора (транспорт) һ. б.; 2) гомумспорт

төшенчәләре (барлык спорт төрләренә караган: хөкемдар, финал, турнир, җиңү); 3) спортара төшенчәләр (спорт төрләре арасындагы): гол, капкачы, йөгерү, кәшәкә һ. б.; 4) махсус бер спорт төренә генә караган төшенчәләр (футболда инсайт, баскетболда блок-шот, фехтованиедә рапира, шпага, төртү һ. б.) [7: 9]. Шул ук хезмәт кысаларында спорт төшенчәләрен тематик һәм аларның сүзьясалыш үзенчәлекләрен төркемләү системасы да тәкъдим ителә. 15 төргә бүленгән классификациядә спорт төрләре һәм төркемчәләре, спорт төшенчәләре, спортчыларның аталышы, хәтта хөкемдарлар куллана торган терминнар билгеле бер эзлеклелеккә салына [7: 20]. Ул спорт төшенчәләре барлыкка килүнең унҗиде моделен бүлеп чыгара, аларның семантик үзенчәлекләрен ачыклый.

Моннан тыш рус телендә спорт лексикасын өйрәнүгә караган хезмәтләрдә күптөрле фикерләр яшәп килә. Аларны классификацияләү мәсьәләсе, терминнарның таралу, спорт лексикасында һөнәри чикләнгәнлек юнәлешләре аеруча кызыксындыра. Спорт лексикасы һөнәри яктан чикләнгән. Аларны хаклы рәвештә спорт атамалары терминнары дип санарга мөмкин. Г.М. Асаналиева фикеренчә, спорт номинацияләре дефинициязләргә корылган төшенчәгә төгәл тәңгәл килгән булырга тиеш [3: 108]. Шул рәвешле, спорт лексикасында һөнәри термин һәм төшенчәләр үсеше әлеге юнәлешнең уңышлы таралып китүенә сәбәп була. Аларның спортны үстерүнең нигезе һәм гомумхалык лексикасы дәрәҗәсендә өйрәнелергә хаклы булуын Н.П. Тимофеева да ассызыклый. «Спорт терминнарын өйрәнүнең әһәмияте физик культура һәм спорт иҗтимагый институтларының уңышы белән бәйле. Шуның белән беррәттән терминнар тел лексик системасының бер өлешен тәшкил итә, шуңа күрә терминнарны гомумхалык сүзләре кебек тикшереп була» [14: 49].

Спорт терминнарын төркемләүнең бер юнәлешен тәкъдим иткән Ш.Б. Алиева башка тикшеренүчеләрдән аерылып тора. «Хәзерге чорда спорт лексемаларын өч төркемгә бүләләр: спорт терминологиясе, спорт лексикасы, профессионализмнар. Спорт лексикасында махсус терминнарны, арготизмнарны, термин булмаган сүзләрне бүлеп чыгаралар. Аерым бер спорт төре кысаларында терминология аерым процесслар, тәэмин итү, күләме, аерым билгеләр һәм үзенчәлекләренә бәйле рәвештә аерым структурага бүленергә мөмкин. Хәзерге лингвокреатив активлык чорында безнең илдә һәм чит илләрдә яңа терминнар барлыкка килә, иске терминнарның семантик яктан таркалуы (дрейф), чит лексик берәмлекләрнең адаптацияләнүе күзәтелә [1: 122].

Спорт терминнарын төркемләүгә багышланган күп кенә чыганакларда кышкы, җәйге спорт төрләренә бүленеш бар. Әмма хәзерге заман югары уку йорты галимнәре физик культура һәм спорт белән бәйле дисциплиналарны укыту барышында студентларны түбәндәге төркемнәргә тарата: спортның уен төрләре (футбол, регби, волейбол, баскетбол, хоккей һ. б.), циклга нигезләнгән спорт төрләре (йөрү, йө-

герү, йөзү, чаңгы спорты, тимераякта йөрү, велосипед спорты һәм ишкәк ишү) һәм циклга бәйле булмаган спорт төрләре (сикерү, ядрә ату, авыр атлетика, гер спорты). Шулай булгач, спорт төшенчәләрен төркемләүнең нигезенә дә шушы юнәлеш ятарга тиеш.

Шул рәвешле, татар телендә спорт төшенчәләрен тарихи-этимологик яктан өйрәнү атамаларның килеп чыгышын ачыкларга, таралу даирәсен күзәтергә мөмкинлек бирә. Спорт төшенчәләре аша телгә килеп кергән һәр лексик берәмлек халыкның милли телен баета. Тел сөйләмне үстерү чарасына әверелә. Спорт лексикасын билгеле бер системага салу эше тел белгечләренең генә түгел, ә барлык спорт һәм физик культура дисциплиналарын укыткан һәм фәнни эш белән шөгыльләнгән киң катлау галимнәрнең бердәм хезмәт нәтиҗәсе буларак күзаллана.

**Әдәбият**


1. *Алиева Ш.Б.* Терминологический статус спортивной лексики // Central asian research journal for interdisciplinary studies (carjis). Vol. 1. Issue 3. 2021. Tashkent: Uzbekistan. С. 121–128.

2. *Антонова Д.Ю.* Лексика спортивного дискурса. Интернет-сылтама: https://www.piram2000.ru/images/cms/data/leksika_sportivnogo_diskursa.docx *мөрәҗәгать итү көне 19.11.2024*

3. *Асаналиева Г.М.* Спортивная лексика современного русского языка // Вестник КГАФКиС (Бишкек). 2017. № 4. С. 107–111.

4. *Аякулов Н.А.* Заимствованные спортивные термины и их употребление в публицистике // Вестник Челябинского государственного университета. 2020. № 3 (437). Филологические науки. Вып. 120. С. 12–20.

5. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015.

6. Без көрәшле халык / төз. һәм авт. Илдус Илдарханов. Казан: Гасыр, 2003. 400 б.

7. *Гуреева Е.И.* Спортивная терминология в лингвокогнитивном аспекте: автореф дис. ... канд. филол. наук. Челябинск, 2007. 25 с.

8. *Ишкинина Л.К.* Основные способы образования спортивной терминологии в татарском языке (на примере терминов хоккея). Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2014. № 3 (33): в 2-х ч. Ч. I. С. 88–91.

9. *Круглов В.В.* Социокультурный феномен спорта, этимология понятия «Спорт» в различных исторических условиях // Современная наука: актуальные проблемы теории и практики. Серия «Гуманитарные науки». 2016. № 2. С. 44–49.

10. Лексикология татарского языка: в трёх томах / редкол.: М.З. Закиев, А.К. Булатова, К.М. Миннуллин, О.Р. Хисамов; науч. ред. Г.Р. Галиуллина. Казань: ИЯЛИ, 2022. Т. I. 352 с.

11. Спорт энциклопедиясе: Малайларга. Кызларга / [авт.-төз.: Э.Т. Киямова, Г.Ф. Хәйдәрова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 140 б.

12. Татар әдәбиятыннан хрестоматия: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен / төз.: Х.Й. Миңнеголов, Ш.А. Садретдинов. Казан: Мәгариф, 1995. 383 б.

13. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр. 1981. 832 б.

14. *Тимофеева Н.П.* Когнитивный аспект семантики отраслевых терминов // Проблемы современной лингвистики в контексте антропоцентризма. Саратов, 2016. С. 47–84.

15. Толковый словарь спортивных терминов / сост.: Ф.П. Суслов, С.М. Вайцеховский. М.: Физкультура и спорт, 1993. 352 с.

16. Фехтовальный клуб. URL: https://fencingmoscowepee.ru/istoriya-fekhtovaniya-3https://fencingmoscowepee.ru/istoriya-fekhtovaniya-3

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты*
*16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы*
*Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ*
*по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Мотыйгуллина Әлфия Рухулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Идел буе дәүләт физик тәрбия,*
*спорт һәм туризм университетының*
*чит телләр һәм тел белеме кафедрасы доценты*

***Мотигуллина Альфия Рухулловна,***
*кандидат филологических наук, доцент кафедры иностранных языков и языкознания Поволжского государственного университета физической культуры, спорта и туризма*

*alfiya311065@mail.ru*

УДК 811.512.145

***Г.Ф. Зиннәтуллина***

# ӘДӘБИ ТЕКСТТА СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫ
## (Гаяз Исхакый әсәрләре мисалында)

В данной статье рассматривается разговорная лексика и стилистические функции данной лексики в произведениях татарского писателя, публициста и общественного деятеля конца XIX – начала XX века Гаяза Исхаки, анализируется стилистическое использование разговорной лексики как средства раскрытия характеров персонажей, индивидуальной речи героев произведений. Актуальность статьи заключается в том, что разговорная лексика и диалектизмы занимают особое место в словарном составе языка, и понимание их характера, правильное определение соотношения с литературными словами имеют значение для культуры речи, то есть для правильной речи. Цель исследования – раскрыть стилистические функции использования разговорной лексики в художественных произведениях, способствующие обучению подрастающего поколения нормам татарского литературного языка. Они имеют определенную стилистическую цель в литературном произведении, только тогда их использование считается уместным и правильным. В своих произведениях Гаяз Исхаки использует разговорную лексику, диалектизмы, реже вульгаризмы, для раскрытия характеров персонажей, передачи их индивидуальной речи. Материалы статьи можно использовать при обучении родному (татарскому) языку, также на занятиях литературы.

**Ключевые слова:** разговорная лексика, диалектизмы, эмоционально-экспрессивность, вульгаризмы, стилистическая функция.

This article examines the use of colloquial vocabulary and their stylistic functions in the works of the Tatar writer, publicist and public figure of the late 19th – early 20th centuries, Gayaz Iskhaki, analyzes the stylistic use of colloquial vocabulary as a means of revealing the characters, the individual speech of the heroes of the works. The relevance of the article lies in the fact that colloquial vocabulary and dialectisms occupy a special place in the vocabulary of the language and understanding their nature, correctly determining the relationship with literary words are important for the culture of speech, that is, for correct speech. The goal is to reveal the stylistic functions of using colloquial vocabulary in fiction and thereby educate the younger generation in the norms of the Tatar literary language. They have a certain stylistic purpose in a literary work, only then their use is considered appropriate and correct. In his works, Gayaz Iskhaki uses colloquial vocabulary, dialectisms, less often vulgarisms, to reveal the characters, convey their individual speech. The materials of the article can be used in teaching native (Tatar) language, as well as in literature classes.

**Keywords:** colloquial vocabulary, dialectisms, emotional expressiveness, vulgarisms, stylistic function.

Әдәби әсәрнең сүзлек составында гади сөйләм сүзләре һәм диалектизмнар билгеле бер урын тота. Лексик-семантик категория буларак, алар арасында уртаклык бар: икесе дә әдәби яктан нормалашмаган, һәм икесе дә телгә яңа сүзләр, әйтелмәләр бирә торган бай чыганак булып саналалар. Стилистик яктан, язучы хикәяләвендә һәм

персонажлар телендә башкарган функцияләре ягыннан әлеге сөйләм чаралары бер-берсеннән аерыла.

Гади сөйләм сүзләре гомумхалык теленең гомумәдәби телгә керми торган, әдәби нормалашмаган махсус лексик катламын тәшкил итәләр. Сөйләм теле лексикасыннан аермалы буларак, гади сөйләм сүзләре әдәби телнең язма формасын гына түгел, сөйләмә формасын да түбәнәйтелгән стильгә якынайта. Алар диалектизмнар кебек территория белән чикләнмәгәннәр һәм шул телдә сөйләшүче барлык кешеләр өчен таныш, аңлаешлы була. Гади сөйләм сүзләренең нигезендә халыкның җанлы сөйләү теле ята. Алар – чын мәгънәсендә халыкның үз эчендә туган сүзләр һәм тормыш-көнкүрешкә бәйле булган әһәмиятле моментларны чагылдыралар, үткен, җанлы, ачык аңлаешлы, чынбарлыкны нәкъ булганча, бизәкләмичә күрсәтәләр. Китап теле лексикасы абстракт фикерләү һәм логик гомумиләштерү нигезендә туса, гади сөйләм сүзләре турыдан-туры җанлы сиземләү, предмет һәм күренешләрне образлы яклары белән зиһенгә алу җирлегендә барлыкка киләләр. Шуңа күрә алар көчле, ачык образлылыкка ия булалар һәм кеше күңеленә үтемлерәк тәэсир итәләр [12: 103–109; 11: 69–71; 1: 129–158].

Диалекталь сүзләрнең матур әдәбиятка, аның аша әдәби телгә үтеп керүендә язучыларның индивидуаль-иҗади тел үзенчәлекләре зур роль уйный. Җирле сөйләш элементларын куллану мисалларын Гаяз Исхакый иҗатында да күрәбез. Аның әсәрләре телендәге бу үзенчәлек беренче хикәяләреннән үк килеп, аннан соңгы зур күләмле проза әсәрләрендә дә дәвам иттерелә. Әдипнең көнбатыш диалект вәкиле булуын да истән чыгармаска кирәк [4: 82]. Аның әсәрләрендә кулланылган диалектизмнар Чистай сөйләшенә карый һәм билгеле бер күләмдә әлеге сөйләшнең лексик, семантик, фонетик, морфологик үзенчәлекләрен чагылдыра. Әдип иҗатында лексик диалектизмнар фонетик һәм грамматик диалектизмнарга караганда чагыштырмача күбрәк очрыйлар. Лексик-семантик диалектизмнар Гаяз Исхакый әсәрләрендә автор сөйләмендә дә, персонажлар телендә дә иркен кулланылалар. Мәсәлән, «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендәге Хәлим сөйләшендә: ***Бак**, шул төрле кояшның яктылыгы гүя минем өчен холыйк ителмеш кышкы кояш баешыннан искән җилләр Хәлимгә «сәгадәт, тәгаллем – сәгадәт» дигән сүзләрне сөйлиләр* [8: 36]; *...* ***этине дә игә китерделәр*** [8: 43]. Әдәби телдә бу сүзләрнең синонимнары бар: *багу – карау* мәгънәсендә, *игә китерү – җайлау, җайга китерү, җайга салу* мәгънәсен белдерә. Гомумән әйткәндә, Г. Исхакыйның диалектизмнарны персонажлар теленә кертүе сөйләмнең җанлылыгын арттыра, сөйләүчегә үз фикерен образлырак, үткенрәк итеп әйтергә мөмкинлек бирә. Диалекталь сүзләрне автор сөйләмендә дә еш очратабыз: *... борылып-борылып төшә торган тауларда тәгәрәп,* ***мәтәкләнеп*** *китүләр бик тиз мине туйдырды* [8: 352]. *Мәтәкләнү* сүзе әдәби телдәге *мәтәлчек ату, мәтәлү* [кара ТТДС: 475] мәгънәсен бирә. Әдип җирле сөйләш сүзләреннән үз әсәрләренең телен яңа сүзләргә, синонимнарга баетырдай лексик чаралар кертергә тырыша һәм аларны иҗади файдалануның матур үрнәген күрсәтә. Ул аларның мәгънә үзенчәлекләрен аңлап, сөйләмгә нинди мәгънә төсмер-

ләре алып керүен ачык сиземләп эш итә. Шул ук вакытта диалекталь сүзләр әсәрдәге милли колоритны да күрсәтеп торалар.

Гомумхалык теле формалашу процессында күп кенә җирле сөйләм сүзләре киң кулланыла башлый. Аларның бер өлеше әдәби китап теленә үтеп керә, язучы әсәрләре телендә генә кулланыла, ә икенче өлеше бары халыкның көндәлек сөйләм телендә генә очрый. Тарихи яктан диалектизмнар гади сөйләм сүзләренә әйләнә баралар, шуның аша аларның кайберләре әдәби лексика составына да үтеп керәләр [2: 227]. Мәсәлән, диалекталь сүз булган *уптимиләйһи* сүзе аннан гади сөйләм сүзенә әйләнә, ә алга таба әдәби сурәтләү чарасына әверелә.

Әдәби телнең үсеше белән бәйле рәвештә халыкның көндәлек сөйләмендә кулланыла торган күп кенә сүзләр әдәби тел составына керәләр. Әлеге процесс бүгенге көндә дә дәвам итә. Гади сөйләм сүзләренең әдәби тел составында кулланылуын раслый торган мисалларны Гаяз Исхакый әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Бай углы» хикәясендә: *Ул бар да булыр, яшь вакытта азрак* ***мутланмаенча*** *да булмый. Дәүләтеңез бар, шаярса да аңар гына йетәрлек булыр әле* [8: 125]. Элек гади сөйләм лексикасына караган *мутлану* сүзе хәзерге көндә әдәби телгә кереп, *кылану, шаяру* мәгънәсен белдерә һәм әдәби әсәрдә образлылыкны арттыра. Гаяз Исхакый әсәрләрендә кулланылган гади сөйләм сүзләре үзләренең составлары ягыннан бертөрле генә түгел. Аларны, тел белемендә күрсәтелгәнчә, өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Лексик һәм саф гади сөйләм сүзләре әдәби кулланыштагы сүзләргә синоним буларак кулланылалар. Мәсәлән, *бытырдау* (күп сөйләү, лыгырдау), *шыпырдау* (кычкыру), *ганка* (ачулану сүзе), *уптимиләйһи* (берьюлы), *чәпелдәү/чапылдау* (ашаганда авыз белән тавыш чыгару) [7: 20; 34], *марҗа* (рус хатын-кызы), *жулик* (тәртипсез), *тырт-пырт* (юкка ачулану; үпкәләп китеп, башкалар белән сөйләшмичә, киреләнеп йөрү), *дүндерү* (кундыру, сугып алу) [8: 119, 147], *сәленү* (хәлсезләнү), *чыңылдау* (яңгыравык, нечкә тавыш чыгару) [8: 92], *шәбәю* (яхшыру), *шымлау* (куркудан дәшмәү, тыну) [8: 348] һ. б.

2. Семантик гади сөйләм элементлары. Кайбер гомумкулланылышта йөргән сүзләр стилистик түбәнәйтелгән күчмә мәгънә алалар. Мәсәлән, *этләнү* (тилмерү), *өшкерү* (ачулану, сүгү), *саплау, әләгешү* (сугышу, талашу), *кызарту* (оялту), *пешерү* (кыйнау), *дуңгыз* (ачуланганда куллана), *тукмау* (кыйнау), *төткәрү* (җиткерү), *гыйлем казанына бату* (баш-аягы белән укуга бирелү) [7: 26] һ. б.

3. Фонетик гади сөйләм элементлары – фонетик бозып яки үзгәртеп кулланылган алынма сүзләр. Алар Г. Исхакый әсәрләрендә шактый күп очрый: *начальства, нутренни врак, его благарудия, высакаблагарудия, әфисәр, стансә, маладис* [8: 331, 342, 344, 345, 346, 348], *кампания, мятни* [7: 26], *расхут* [8: 67, 134], *шкул, парахут, кают, кантур, ыстанса* [8: 79, 81, 104, 105, 110], *канфит, мороз, папирус, прастуй* [8: 118, 119, 145] һ. б.

Гади сөйләм лексикасы составындагы сүзләр эмоциональ-экспрессив табигатьләре белән бер-берләреннән аерылалар. Аларның бер өлешендә кискен тупаслык экспрессиясе ярылып ята. Болар –

вульгаризмнар [13: 132]. Мәсәлән, тиргәү өчен кулланылган сүзләр: *ганка, жулик, дуңгыз, каһәр суккан* һ. б. Әлеге сүзләр бик тупас яңгырыйлар һәм алар әдәби тел рамкаларына сыймыйлар: ***Каһәр суккан*** *Бәдәр харап итте мине, Бәдәр* [8: 48]; ***Дуңгызлар****, двор өенә качып торганнар* [7: 26]; *Әллә ничә җирдән кунаклар адресына:* ***«Ганка!»*** *дигән сүз йибәрелде* [7: 23]; һ. б.

Гади сөйләм сүзләренең икенче бер төре артык тупас түгел, әдәби кулланылыш чигендә торалар. Мисал өчен, ***Бытырдама,*** *малай, күрмисеңмени, Галиәкбәр хәлфәгә кунаклар килде!* [7: 20]; *...баеракларыны* ***сабак өйрәтеп*** *этләнде* [7: 34]; *...дүртесенең дә* ***авызлары чәпелдәргә тотынды*** [7: 34]; *Зуррак шәкертләр җыелып, ат яллап артларыннан куып йетеп кайтарырга кирәклегене, кайсылары барып йетеп, бик* ***пешереп****, юлда ташлап калдырырга тиешлегене сөйләде* [7: 26]; һ. б. Тел үсеше процессында күп кенә гади сөйләм сүзләре әдәби тел составына үтеп керәләр. Шуның белән алар әдәби телнең сүзлек хәзинәсен тулыландыручы чыганак булып торалар [2: 228; 10: 122–123; 9: 230–232]. Гади сөйләм сүзләре әдәби әсәрләр телендә гаять әһәмиятле стилистик функция башкаралар. Гаяз Исхакыйның «Мулла бабай» романыннан бер мисал: *Килгән шәкертләр бер-берсенә карашып, без нәхүдән сөйләшмибез, сөйләшәсеңез килсә, шәкертләремезне йебәрермез, диделәр. Килгәннәрнең болай кылынулары мәдрәсәнең исеменә тию булганга, Дәүкади Гата, шыпырдама, дип тә кычкырды* [7, 23]. *Шыпырдау* сүзе *кычкыру* сүзе белән бергә контексттагы башка лексик чаралардан кырыслык, тупаслык буяулары белән аерылып тора һәм бөтен сөйләмгә шундый эмоциональ-экспрессив төсмер бирә. Бу сүзгә йөкләтелгән төп стилистик функция – сөйләүченең башкаларга карата ачуы килгәнен күрсәтү, тискәре мөнәсәбәтен белдерү. Мондый сүзләрдә сөйләү теленә хас гадилек тә, үткенлек тә, сурәтлелек тә ачык чагыла. Шуңа күрә сөйләм тормышчан, җанлы, тәэсирле яңгырый.

Гаяз Исхакый гади сөйләм лексикасының телне синоним сүзләргә баетуын яхшы сиземли. Мәсәлән, *тилмерү, кыйнау* кебек битараф сүзләргә синоним буларак кулланылган *этләнү, пешерү, тукмау* фигыльләренең контекст эчендә нинди максатчан семантик-стилистик функция башкаруларына игътибар итик: *...баеракларыны сабак өйрәтеп этләнде* [7: 34]; *...кайсылары барып йетеп, бик пешереп, юлда ташлап калдырырга тиешлегене сөйләде* [7: 26]; *...бөтен мәдрәсә тегеләрне тукмый башлады* [7: 26].

Еш кына гади сөйләм сүзләре язучының персонажга булган мөнәсәбәтен һәм шуның аркылы җәмгыятьнең нинди икәнен күрсәтү өчен кулланылалар. Мәсәлән, «Солдат» хикәясендә: *Ул да (Садыйк) шундый үзенең яхшы солдатлыгын күрсәтергә җай килүен,* ***нутренни вракны*** *һәң генә иттерергә туры килүен эченнән көтә дә иде* [8: 346].

Автор сөйләмендә солдат Садыйкка карата белдерелгән мөнәсәбәт *нутренни врак* сүзтезмәсе аша чагылыш таба. Әлеге мисал ярдәмендә Гаяз Исхакый Садыйкның ни дәрәҗәдә «яхшы солдат» булуын, җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне, аның шәхескә тискәре йогынты ясавын күрсәтергә тырыша.

Гади сөйләм сүзләре әдәби әсәрдә стилистик максатка ия, шул вакытта гына аларны куллану дөрес санала. Киресенчә булганда һәм куллануда чама сакланмаганда, алар әдәби телне чуарлауга, сөйләм культурасызлыгына китерәләр. Гаяз Исхакый үзенең әсәрләрендә гади сөйләм сүзләрен персонажларның характерын ачу, аларның индивидуаль сөйләмен бирү өчен куллана. Әдип әсәрләренең телендә кулланылган җирле сөйләш һәм гади сөйләм сүзләрен өйрәнү аша без авторга хас булган чама хисен, аның тел сиземләү сәләтен, аларны урынлы һәм максатчан куллануын күрдек.

**Әдәбият**

1. *Абдуллин И.А.* Г. Камал драмаларының теле. Казан, 1968. Б. 129–158.

2. *Ефимов А.И.* Стилистика художественной речи. М.: Изд-во Москов. гос. ун-та, 1961. 517 с.

3. *Зиннатуллина Г.Ф.* Сравнительно-историческое исследование словарного состава художественных произведений Гаяза Исхаки // Филологические науки. Вопросы теории и практики. № 12. Ч. 2. 2015. С. 78–80.

4. *Зиннәтуллина Г.Ф.* Гаяз Исхакый әсәрләрендә фразеологик берәмлекләрнең семантикасы // В.А. Богородицкий и современная лингвистика: Труды и материалы Междунар. науч. конф.: в 2 т. Казань, 2024. Т. 2. С. 80–84.

5. *Зиннатуллина Г.Ф.* Индивидуальный стиль писателя Гаяза Исхаки // Казанская наука. 2025. № 2. С. 271–274.

6. *Исхакый Г.* Тәгаллемдә сәгадәт // Мирас. 1992. № 12.

7. *Исхакый Г.* Мулла бабай // Мирас. 1995. № 4, 5–6, 10.

8. *Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 400 б.

9. *Князькова Г.П.* Русское просторечие второй половины XVIII века. Л.: Наука, 1974. 253 с.

10. *Курбатов Х.Р.* Сүз һәм стиль // Совет әдәбияты. 1961. Б. 122–123.

11. *Сабиров К.С.* Классификация лексической фразеологии (на материале татарского языка) // Ученые записки. Вып. XXVIII. Чебоксары: Чувашкнигоиздат, 1965. С. 69–71.

12. *Хаков В.Х.* Татар теле стилистикасына кереш. Казан, 1963. Б. 103–109.

13. *Шанский Н.М.* Лексикология современного русского языка. М., 1964. 316 с.

14. *Юсупов Р.А.* Диалект һәм гади сөйләм сүзләре // Безнең гәҗит. 2022. 6 июль (№ 26).

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Зиннәтуллина Гөлзара Фазылрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының гамәли һәм эксперименталь лингвистика кафедрасы доценты*

***Зиннатуллина Гульзара Фазулрахмановна,***
*кандидат филологических наук, доцент кафедры прикладной и экспериментальной лингвистики Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета*
*Zara-75@yandex.ru*

УДК 811.512

***Э.Х. Кадирова***

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫ ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ БЕР УРЫННАН ИКЕНЧЕ УРЫНГА КҮЧЕРҮ ФИГЫЛЬЛӘРЕ

Татарская глагольная система, как и в других языках, представляет значительный интерес с точки зрения исследования лексической семантики. В статье анализируется группа глаголов движения, а именно лексические единицы, выражающие каузацию перемещения объектов, которые встречаются в письменных памятниках эпохи Казанского ханства: в произведениях Мухаммедьяра, Кулшарифа, Умми Камала, в памятниках «Сираджел-кулуб» Аднаш Хафиза и «Зафернамэ-и Вилайет-и Казан».

Хотя глаголы движения в сравнительно-историческом аспекте исследованы достаточно подробно, именно эта подгруппа до сих пор остается недостаточно изученной, что и определяет актуальность работы. Рассматриваемые слова обозначают ситуации, в которых субъект должен заставлять объект к изменению местоположения: заставлять его переместиться из одного места в другое, принимая в результате новое положение в пространстве. Автор останавливается на анализе глаголов сөрү ‘гнать’, куу ‘гнать’, сөйрәү ‘волочить’. Особое внимание уделяется сравнительно-историческому анализу семантики данных лексем.

**Ключевые слова:** глагол, семантика, письменные памятники, татарский язык, старотатарский язык.

The Tatar verb system, as in other languages, is of considerable interest from the point of view of the study of lexical semantics. The article analyzes a group of verbs of motion, namely lexical units expressing the causation of the movement of objects, which are found in written monuments of the Kazan Khanate era, namely in the works of Muhammadyar, Kulsharif, Ummi Kamal, in the monuments “Sirajel kulub” of Adnash Hafiz and “Zafername-i Vilayet-i Kazan”. Although verbs of motion have been studied in sufficient detail in the comparative-historical aspect, it is this subgroup that remains insufficiently studied, which determines the relevance of the work. The words under consideration denote situations in which the subject must force the object to change its location: force it to move from one place to another, as a result taking a new position in space. The author dwells on the analysis of the verbs сөрү ‘to drive’, куу ‘to drive’, сөйрәү ‘to drag’. Particular attention is paid to the comparative analysis of the semantics of these lexemes.

**Keywords:** verb, semantics, written monuments, Tatar language, Old Tatar language.

Фигыльләр мәгънәләренең гомуми һәм киң булуы белән башка сүз төркемнәреннән аерылып тора. Шунлыктан аларны лексик мәгънәләре буенча төркемләү – катлаулы эш.

Әлеге мәкаләдә хәрәкәт фигыльләрнең бер төркемчәсенә – бер урыннан икенче урынга күчерүне белдергән лексик берәмлекләргә урын бирелә. Бу төркемгә *ияртү, китерү, җибәрү, куу, сөйрәү, сөйрәп китерү, этү, тибү, ыргыту, ташлау, төшерү, очыру, юнәлтү,*

*чыгару, тарату, кертү, җыю, үткәрү, әйләндерү* фигыльләре кирә [20: 105; 21: 98]. Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә алардан *сөрү, куу, чыгару, өстерәү* фигыльләре очрый.

*Сөр-* һәм *ку-* фигыльләренең татар әдәби телендә хәзерге көндәге эчтәлеген чагыштыру максатында, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә мөрәҗәгать итсәк, аларның хәзерге көндә төрле мәгънә төсмерләренә ия булуын күрербез. *Сөрү* фигыленә анда түбәндәге аңлатма бирелә: 1) ачуланып, куу, куып җибәрү; бөтенләйгә китәргә мәҗбүр итү; 2) җәза тәртибендә сөргенгә җибәрү; 3) көчләп хәрәкәт иттерү; куалау; 4) куу, тарату, бетерү [23: 187–188]. *Куу* сүзенең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә 21 мәгънәсе теркәлгән һәм төп мәгънәләре булып, 1) хәрәкәткә китерү, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итү; 2) билгеле бер урыннан китәргә мәҗбүр итү; 3) иректән мәхрүм итеп, туган, торган җирләрдән китәргә мәҗбүрләү, сөрү, сөргенгә озату; 4) хәрәкәтләнү тизлеген арттырырга мәҗбүр итү; 5) тарату, таркату (җыен, төркем һ. б. тур.); 5) терлекне көтүгә чыгару һәм башка мәгънәләр тора [22: 508].

Телнең лексик составы үзгәрү архаик формаларның хәзерге вариантлар белән алышынуы, телгә алынмалар кабул итү, деривация процесслары нәтиҗәсендә була. Лексемаларның телдә семантик үсешен төгәлрәк ачыклау өчен, беренче чиратта, аларның борынгы ядкәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен карау кирәк.

*Сөрү* лексемасы борынгы төрки һәм урта гасыр төрки язма истәлекләрдә үк актив лексика составында була [7: 518; 12: 423; 4: 279; 6: 406; 11: 193; 13: 130; 17: 148; 1: 171]. *Куу* фигыленең дә шул ук чорлардан ук кулланылуы билгеле [8: 55].

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләреннән булган шагыйрь Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында *сөрү* һәм *куу* фигыльләре икесе дә урын ала. Мөхәммәдьяр әсәрләрендә *сөрү* сүзе өч тапкыр очрый. Алар бүгенге көн аңлатмалы сүзлегендә китерелгән мәгънәләрдә [23: 187–188] кулланылалар. «Төхфәи мәрдан» поэмасындагы бер хикәяттә кыз, атасы рөхсәтеннән башка, фәкыйрьгә икмәк бирә. Фәкыйрь өйдән чыгып, икмәкне ашый башлый. Кызның атасы, урамнан үтеп барышлый, үз икмәген таный һәм өйгә кайткач, кызын сүгә, уң кулын кисеп, өйдән куып чыгара: *Бихәд аны қамчы(сы) берлә оруб, Чықарды (ул) ғаси эүендин сөрүб* [15: 81] ‘Аны қамчы белән кыйнап, чыгарды гази өеннән сөреп’. *Сөрү* бирелә ‘ачуланып куу, куып җибәрү; бөтенләйгә китәргә мәҗбүр итү’ мәгънәсендә кулланылган. Бу очракта эшнең сыйфатламасы телнең гомуми кулланышына караганда эмоциональ рәвештә көчлерәк. «Хәл фигыль + чыгару фигыле» формасы эшнең нәтиҗәлелеген белдерә. Тагын мисал: *Сән тәк этләр йырақдин күб өрәрләр, Ишеккә килдисә, «чық!», диб сөрәрләр* [15: 47] ‘Синдәй этләр еректан күп өрәләр, ишеккә килсәләр, «Чык!» дип куалар’. *Сөрү* фигыле ‘куу, билгеле бер урыннан китәргә мәҗбүр итү’ мәгънәсен бирә. Әлеге очракка туры килгән мисал Мөхәммәдьяр иҗатында тагын бар: *Ғиззәт илә хурлуқны күрмәгәй сән, Сөфрә башындин кешине сөрмәгәй сән* (Төхфәи мәрдан) [15: 79] ‘Хөрмәтле булсаң,

хурлык күрмәссең, Табын түреннән кешене кумассың’. Әлеге мәгънәгә мисал XV–XVI гасыр ядкәре булган «Могҗизнамә» әсәрендә дә очрый: *Мәккәдән үз кавеме аны сөрделәр* [14: 182].

*Сөрү* фигыленең ‘көчләп хәрәкәт иттерү; куалау, алга таба куу’ мәгънәсе бу чор язма истәлекләренең һәркайсында диярлек урын ала. Ул күбрәк хайваннарны куу, куалау турында сүз барганда очрый. Бу фигыль шагыйрь Мөхәммәдьяр тарафыннан «Нуры содур» поэмасында кулланыла: *Кэчә-көндүз ойумады йул йөрүб, Ашығыб тәүәсени қатығ сөрүб* [15: 190] ‘Кичен-көндез юлда йөреп йокламады, ашыгып, дөясен каты куды’. *Сөр-* лексемасы бу очракта ‘хайванны куалау’ мәгънәсендә килә һәм аның эчтәлеген биредә каты сыйфаты тулыландыра. *Сөрү* лексемасы шундый ук мәгънәдә кешегә карата «Могҗизнамә», «Сираҗел-колүб» истәлекләрендә очрый: *уйлары сул йару сөрде, нәчәмә кем сөрмәк теләде ирсә, куйлар камугы качыб, саг йару бара башлады* [19: 47]; *Мәүлә Тәгаләнең фәрманы берлә фәрештәләр кәлүб, бу ләшкәрнең соң калмышыны сөрә-сөрә кәлүб, бу дәрьяга керделәр* [19: 46]; *Тәкый фәрештәләр кяферләрне сират таба сөргәйләр* [19: 16].

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» авторлары фигыль сүз төркеменә караган *сөрү* сүзен 4 омоним пар итеп тикшерәләр. К.М. Мусаев *сөрү* фигыленең тарихын түбәндәгечә аңлата: *сөрү* фигыленең атамасы, *хайваннарны куу* атамасы кебек үк, төрки телләрне икегә бүлә һәм көнбатыш кыпчак, Идел буе, көньяк-көнбатыш, көнчыгыш төрки телләр – *сөр* фигыле, ә көнчыгыш кыпчак, Урта Азия төрки телләрендә *айда* лексемасы белән белдерелә, һәм бу ике фигыль дә төрки телләрдә терлекне кууны аңлата; бу терлекчелеккә караган мәгънә беренчел булып, соңрак игенчелеккә караган мәгънәгә күчә, ягъни җирне сөрү өчен хайваннарның тарту көчен файдаланганнар [16: 308]. Р.Г. Әхмәтьянов *сөрү* фигыленең килеп чыгышын борынгы төрки телдәге **сүүр-*, **сү-* «дошманны куу, сугышу» тамырыннан булса кирәк, ди [3: 174]. *Җир сөрү, сабан сөрү* сүзтезмәләрендә *сөрү* фигыленең ‘туфракны сабан белән ерып йомшарту’ мәгънәсе ‘куу, хәрәкәткә китерү, хәрәкәтләнергә мәҗбүр итү; билгеле бер урыннан китәргә мәҗбүр итү’ мәгънәсендәге *сөр* лексемасы белән эш объекты атамасы янәшә килеп ясала дип аңлата галим К. Мусаев [16: 309].

«Могҗизнамә» истәлегендә *Мән сөреп гомреме, киттем дөньядан* [Могҗизнамә: 284] мисалы очрый. *Сөрү* фигыле *көн, гомер, тормыш* кебек сүзләр белән килеп, күп төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә ‘яшәү, кичерү, алып бару, үткәрү; дәвам итү’ [23: 188] мәгънәсен бирә. Татар телендә бүген дә *гомер сөрү, тормыш сөрү* сүзтезмәләре белән беррәттән *гомер куу, тормыш куу* гыйбарәләре дә яшәгәнлектән, без бу очракларда да әлеге ике лексема арасында мәгънәви бәйләнеш бар дип уйлыйбыз. Күп кенә төрки телләрнең аңлатмалы сүзлекләрендә ул хәзерге вакытта да бер сүзнең төрле мәгънәләре буларак китерелә [28; 30: 593–594].

«Могҗизнамә» әсәрендә Казан ханлыгы чорының башка истәлекләрендә урын алган *баш ору, йөз ору* фразеологизмнарының сино-

нимы буларак, *йөз сөрү* тотрыклы сүзтезмәсе килә, ягъни фразеологизм ‘йөзен юнәлтү’ мәгънәсендә кулланыла: *Фатыйма илә Хәйдәр аны күрделәр, Торубән аягына йөз сөрделәр* [14: 182], *Бәс, Рәсүлнең күрекле йөзен күрделәр, Һәрбере аягына йөз сөрделәр* [14: 180]. *Ошбу хаты анда чөнки күрделәр, Һәр бере ул сандыкка йөз сөрделәр* [14: 239] мисалында шулай ук әлеге мәгънә бирелә. Бу фигыль «Могҗизнамә» әсәрендә башка фразеологизмнар составында да теркәлгән [14: 30, 233, 237].

*Сөрү* фигыленең синонимик пары буларак, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында *куу* лексемасы очрый: *Кем сачылуб чықты қуйлардин рәуан, Қачды ирсә қудың аны ул заман* [15: 183] ‘Куйлардан берсе аерылып чыкты шул вакыт, Качса, ул заман аны кудың’. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу мәгънә ‘алдарак баручының артыннан җитү, тоту’ дип аңлатыла [22: 508].

Шунысы үзенчәлекле: бу ике фигыль объект буларак тере затларның (кеше, хайван һ. б.) исемнәрен таләп итә ала. Безнең мисаллар да шуны раслый.

Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» әсәрендәге *Сүзне қуа қилдем уш, и мәрде пир, Бер хикайәт килде күңлүмгә нәзыйр* [15: 55] мисалында бу фигыль күчерелмә мәгънәдә килә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сүзне куа килә, сүз артыннан куу* фразеологик берәмлекләре урын алмаса да, бу гыйбарәләргә мисаллар татар телендә очрый: *Сүз куган бәлагә юлыгыр, юл куган казнага юлыгыр* (мәкаль) [2].

XVIII–XIX гасырлар иске татар әдәби телендә *sör-* фигыле шулай ук киң кулланыла. Мәсәлән, Г. Кандалый «Сөйгәнемгә инанмасаң» шигырендә *sör-* лексемасын 4 тапкыр файдалана, ә *Этен сөргәндәй кусайде катындин, Җәфа күрсәтсәйде көндәш хатындин* [9: 161] мисалында автор, кабатлаудан качу өчен, *сөр-* фигыленә синоним буларак, *ку-* вариантын куллана. XIX гасыр татар теленең сүзлекләрендә, борынгы һәм Урта гасырлар төрки ядкәрләрендәге кебек, *сөрү* сүзе төрле мәгънәләрдә теркәлгән: ‘куарга; озатырга’ [10: 55]; ‘куарга’ [24: 512].

Хәзерге татар әдәби телендә кулланылыштагы күтәрми генә тартып баруны, өстерәү, ниндидер өслектән шудыруны аңлаткан *сөйрәү* фигыленең тарихы кызыклы. Ул мәгънәдә Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында *сүтрә-* варианты килә: *Алыб ул балықны эүигә килтүрүб, Сүтрәйү һәзар хәйлә берлә тикүрүб* [15: 86] ‘Балыкны алып өйгә китерде, Сөйрәп, меңнәрчә хәйлә белән җиткерде’. «Сираҗелколүб» китабында әлеге фигыль бары тик *сөйрә* формасында гына кулланыла: *Буйнуна кайыш тактылар, сөйрәйү башладылар* [19: 54]; *Җүрәйҗ заһидны соумәгасындин сөйрәб* [19: 57]. Истәлекләрдә ике вариантның урын алуын, матур әдәбиятта традицияләр дәвам итү белән аңлату кирәктер. Бу лексема борынгы һәм Урта гасырлар язма истәлекләрендә дә төрле вариантларда урын ала [7: 518]; XIV гасыр ядкәре «Нәһҗел-фәрадис»та аның *сувра-* формасы кулланыла [26: 303]. В. Радлов, Л. Будагов һәм Н. Рясянен сүзлекләрендә дә бу фигыльнең төрле фонетик вариантлары теркәлгән: сӳдрӓ, сӳдрӓl, сӳдрӓт, сӳдрӓш, сӳзӳр, сӳртӓ [18: 838, 829]; сӳртмекъ, сӳрмекъ, сӳдремекъ,

сӳрӳклемекъ [5: 642, 643, 644]; söra, sürä, süjrä, söδrä, süδrä һәм südrä [29: 435]. Бу барлык сүзлекләрдә дә чагатай әдәби телендә südrä формасының ‘тартырга, сөйрәргә, өстерәргә’ мәгънәсендә кулланылуы хәбәр ителә. Хәзерге төрки телләрдә фигыль билгеле булган мәгънәдә төрле формалар белән бирелә: алт. сӱӱрте=, хак. сӧӧрте= ‘тащить, волочить’; хак. сӧзір= ‘1) тащить, тянуть, волочить; 2) тянуть на буксире’; тув. сөөрт= ‘1) возить, везти; 2) волочить, тащить’; кирг. сүйрө=, каз. сүйре= ‘волочить, тащить волоком’; тат. сөйрә= ‘тащить’; тур. sürü= ‘волочить, тащить, тянуть’; ср. также тур. sürt= ‘скитаться, слоняться’, sürtün= ‘тащиться’; узб. судра= ‘волочить, тащить’ [25: 219]. Хәзерге татар әдәби телендә ‘сөйрәү’ лексемасы белән бергә *өстерәү* фигыле дә кулланыла. Бу очракта борынгы *süträ* фигыле метатеза күренеше нигезендә *österä* формасын алган дип фараз ителә.

Төрле чорлардагы төрки ядкәрләрне тикшерү безгә мондый нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирде: *сөрү* һәм *куу* лексемалары арасында борынгы һәм Урта гасырларда күпмәгънәле фигыль *sör-* активрак булган. Хәзерге көндә *куу* фигыле белдергән аерым мәгънәләрдә *сөрү* фигыле йөргән.

**Әдәбият**

1. *Ахметгалеева Я.С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М.: Наука, 1979. 191 с.

2. Әйтем – чәчәк, мәкаль – җиләк: Халык афоризмнары. Икенче китап. Казан: Мәгариф, 2002. 191 б. URL: https://tatkniga.ru/upload/oldbook/pdf/2830.pdf (мөрәҗәгать итү көне: 07.08.2025).

3. *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II т. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. 567 б.

4. *Боровков А.К.* Лексика среднеазиатского тефсира XII–XIII вв. М.: Изд-во восточной литературы, 1963. 365 с.

5. *Будагов Л.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык: в 2-х т. СПб.: Тип. АН, 1869. Т. 1. 810 с.

6. Документы на половецком языке XVI в.: Судебные акты Каменец-Подольской армянской общины. М.: Наука: Гл. ред. вост. лит., 1967. 430 с.

7. Древнетюркский словарь. Л.: Наука, ЛО АН СССР, 1969. 677 с.

8. *Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и Мардан» и «Нур-и Содур»: лексика. Казань: Фикер, 2001. 230 с.

9. *Кандалый Габделҗәббар*. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

10. *Кукляшев С.* Словарь к татарской хрестоматии. Казань, 1859. 106 с.

11. *Курышжанов А.К.* Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. – «Тюркско-арабского словаря». Алма-Ата: Наука, 1970. 234 с.

12. *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М.-Л. Изд-во АН СССР, 1951. 906 с.

13. *Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1982. С. 68–153.

14. *Мөхәммәт Әмин.* Могҗизнамә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 295 б.

15. *Мөхәммәдьяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

16. *Мусаев К.М.* Лексика тюркских языков в сравнительном освещении: западнокыпчакская группа. М.: Наука, 1975. 359 с.

17. *Наджип Э.Н.* Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. Алма-Ата, 1975. 208 с.

18. *Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий. Т. 1. Ч. 2. СПб., 1911. С. 1116.

19. Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1903. 126 б.

20. Татар грамматикасы. Т. II. М.: Инсан; Казан: Фикер, 2002. 448 б.

21. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

22. Татар теленең анлатмалы сүзлеге. III т.: К. Казан: ТӘһСИ, 2017. 744 б.

23. Татар теленең анлатмалы сүзлеге. V т.: С–Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

24. *Троянский А.А.* Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченiй арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщашемъ учителя татарского языка въ Казанской семинарiи священника Александра Троянского и напечатанный съдозволенiя комиссiи духовныхъ училищъ: в 2 т. Казань, 1833. Т. 1. 629 с.

25. *Тюнтешева Е.В.* Лексико-семантические соответствия глаголов трудовой деятельности алтайского языка в тюркских языках Южной Сибири и кыпчакских языках // Сибирский филологический журнал. 2017. № 4. С. 214–225.

26. *Фазылов Э.И.* Староузбекский язык. Хорезмийские памятники XIV в. Т. II. Ташкент: Фан, 1971. 777 с.

27. *Чугунекова А.Н.* Глаголы со значением каузации перемещения, помещения и локализации объектов // Мир науки, культуры, образования. № 2 (27). 2011. С. 46–48.

28. Kubbealtı Lugatı. URL: https://lugatim.com (мөрәҗәгать итү көне: 23.08.2025).

29. Räsänen M. Versuch eines etymologischen Wörterbuchs der Türksprachen. Helsinki 1969. 533 s.

30. Ӯзбек тилининг изохли лугати. Ж. 3: Н – Тартибли / Масъул мухаррир А. Мадвалиев. Ташкент: «O‘zbekiston milliy ensiklopediyasi@ Давлат илмий нашриёти, 2020. 688 б.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты*
*16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы*
*Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ*
*по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Кадирова Энзе Ханафиевна,***
*кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*enge@inbox.ru*

УДК 821.512.145

*З.З. Рәмиев*

# ТУКАЙ ФАТИХАСЫН АЛГАН ШАГЫЙРЬ
## (Сәгыйть Сүнчәләйнең тормыш һәм иҗат юлы турында)

В статье освещены жизненный путь и творчество поэта, переводчика, драматурга и общественного деятеля Сагита Сунчелея (1889–1937). Автор статьи на основе архивных материалов и воспоминаний известных личностей знакомит читателя с основными этапами жизненного пути С. Сунчелея, делает попытку обобщающей оценки творчества поэта, знакомит с имеющимися научными исследованиями. Автором устанавливается, что в творчестве поэта гармонично коррелировали восточные и западные литературные традиции, также подчеркивается, что С. Сунчелей получил признание и как мастер переводов: через его тексты татарский читатель знакомился с творчеством выдающихся классиков русской и мировой литературы: Пушкина, Байрона, Гейне и др. При этом цель поэта – не точный, а свободный, имеющий национальный характер, перевод. Особое место в статье уделяется освещению взаимоотношений С. Сунчелея с татарским поэтом Г. Тукаем, который стал для молодого поэта не только наставником, но и близким другом.

**Ключевые слова:** Сагит Сунчелей, татарская поэзия, литература начала XX века, юбилей.

The article highlights the life and work of the poet, translator, playwright and public figure Sagit Suncheley (1889-1937). The author of the article, based on archival materials and memoirs of famous personalities, introduces the reader to the main stages of the life of S. Suncheley, makes an attempt to generalize the poet's work, and introduces existing scientific research. The author establishes that the poet's work harmoniously correlated Eastern and Western literary traditions, and also emphasizes that S. Suncheley received recognition as a master of translation: through his texts, the Tatar reader became acquainted with the work of outstanding classics of Russian and world literature: Pushkin, Byron, Heine, etc. At the same time, the poet's goal is not an exact, but a free translation with a national character. The article pays special attention to the relationship between S. Suncheley and the Tatar poet G. Tukay, who became not only a mentor but also a close friend for the young poet.

Key words: Sagit Suncheley, Tatar poetry, literature of the early twentieth century, anniversary.

1910–1920 елларда лирик-романтик шагыйрь, кыю тәрҗемәче, драматург, җәмәгать эшлеклесе сыйфатында танылып, татар әдәбиятының XX гасыр башындагы яңарышына зур өлеш керткән, әмма 1930 елларда совет хакимияте тарафыннан «оныттырылган» Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына август аенда 136 ел тулды.

Билгеле ки, шәхес корбаны булган тынгысыз, бик тә актив, талантлы бу иҗатчының әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге хакында 1960 елларга кадәр әдәбият тарихына караган хезмәтләрдә уңай фикер

әйтелә алмаган. Бары тик СССР Югары суды хәрби коллегиясенең 1958 елның 8 мартындагы утырышында аклангач кына, С. Сүнчәләйнең намуслы исемен, күпкырлы иҗат мирасын халкыбызга кайтару эше башлана. Халык язучысы Ә. Еники билгеләвенчә, 1959 елда абыйсы Шәриф Сүнчәләй «шагыйрьнең барлык шигырьләрен, сәхнә әсәрләрен, тәрҗемәләрен, истәлекләрен, рәсемнәрен җыеп, туплап, шуларга аңлатмалар, библиографик белешмәләр дә язып, әзер җыентык хәленә китереп», нәшриятка тапшыра. Аларның бер өлеше Г. Халит кереш сүзе белән шагыйрьнең 112 битлек «Сайланма әсәрләр»е рәвешендә басылып та чыга. Мәскәүдә Ш. Сүнчәләйнең хатыны Сорур ханымда (Ә. Еникинең туганы) сакланган бу материаллар, Н. Нәккаш тарафыннан тасвирланып, Казанга кайтарыла һәм Татарстан дәүләт музеена тапшырыла (ф. 1752).

1970–1980 елларга таба С. Сүнчәләйнең тормышы, иҗат мирасына караган фәнни-мәгълүмати тикшеренүләр дә күренә башлый [5; 6; 12]. Вакытлы матбугат битләрендә, төрле китапларда басылып чыккан Б. Урманче, Р. Ишморат, Ә. Еникиләрнең истәлекләре [3: 179–183], М. Мәһдиев, Р. Мостафиннарның [7; 9] мәгълүматка бай язмалары да С. Сүнчәләйне шәхес һәм иҗатчы сыйфатында тулырак танытырга мөмкинлек тудыра. XX гасыр азагына С. Сүнчәләй иҗаты буенча Р. Мусабәкова [8] һәм Н. Нәгыймов [10] кандидатлык диссертацияләре яклыйлар, соңгы елларда С. Сүнчәләйнең шәхесен төрле яклап ачкан Э. Галимова [2], Л. Габдрафикова [1] мәкаләләре дөнья күрә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында узган гасырның соңгы чирегендә әзерләнгән алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томында С. Сүнчәләй турында да күпмедер мәгълүмат урын ала, ә инде сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 4 нче томында XX гасыр башында иҗат иткән сигез мәшһүр татар шагыйре исәбендә аның да әдәби мирасына лаеклы бәя бирелә [4; 8]. Шагыйрьнең әсәрләрен халыкка кайтару юлында шушы язманың авторы да моннан утыз еллар элек фәнни-текстологик эш алып бара башлаган иде, шуның нәтиҗәсе буларак 2005 елда С. Сүнчәләйнең «Әсәрләр һәм хатлар» исемле китабы дөнья күрде. Анда укучыларга әдипнең табылган шигырьләре тулаем диярлек, ике пьесасы («Мансур», «Сәнгатьчеләр»), «Яман хатын» һәм «Язучы» хикәяләре, мәкалә һәм истәлекләре, 70 ләп хаты тәкъдим ителде [13]. Әлеге мәкалә исә, шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты хакында эзлекле, системалы күзаллау булдыру һәм моңарчы аның хакында әйтелгән фикерләрне тулыландыру максаты белән тәкъдим ителә.

Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев 1889 елның 14 (2) августында туган дип санала (1927 елның 2 июнендә ОГПУга бирелгән анкетасында, Наркомнац документларында 1888 елның 25 декабре күрсәтелгән). Туу урыны – Саратов губернасы Хвалын өязе Иске Мостяк авылы (хәзер ул Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына карый). 1891 елгы ачлык вакытларында бу гаилә Әстерхан шәһәренә күченеп яши башлый. Биредәге «Вәһһабия» мәдрәсәсендә укып, аны

тәмамлагач, Сәгыйть ике ел мондагы Ак мәчет мәхәлләсе мәктәбендә укыта. 1905 елгы инкыйлаби вакыйгалар вакытында исә абыйсы Шәрифҗан (1885–1959) белән бергә прокламацияләр, сул фикерле рисаләләр таратучылар арасында була. 1906 елда Казанга килгәч, ул Шакирҗан Хәмиди мәдрәсәсендә укып йөри. Бераздан, 1907 елның августында Казан татар укытучылар мәктәбенә кабул ителә (абыйсы Шәрифҗан бу мәктәптә 1903–1907 елларда укыган), тик уку түләүле булганлыктан, аны дәвам иттерә алмый. Бераздан абыйсы янына – Пермь губернасы Уса өязе Сараш авылына килеп урнаша, андагы дүртьеллык земство мәктәбендә укыта башлый (якындагы Солтанай авылы мәдрәсәсенә дә атнага өч тапкыр килеп, рус теленнән белем биргәннәр). Бу заманда ул ике мәртәбә гаилә корган. Беренче хатыны Сәлимә 1909 елда бала тапканда үлеп китә, уллары Таһир исә, исән калса да, бик иртә – 15 яшендә вафат була (шул вакытларда С. Сүнчәләй «Хәятымда ике зур кайгы күрдем, / Газиз баштан ике матәм кичердем», дип башланып киткән «Ике матәм» исемле шигырь яза, аны үзе көйгә дә сала). Икенче хатыны – Казан кызы Фәридә белән С. Сүнчәләйнең юллары 1914 елда аерыла. Бу никахтан аның Фәрит исемле улы (1912–?) булып, ул Бөек Ватан сугышында һәлак була.

Р. Ишморат истәлекләрендә шагыйрьнең Сараштагы тормышы һәм педагогик эшчәнлегендә җыр һәм музыканың зур урын биләве искәртелә. Сәгыйть үзе скрипкада һәм мандолинада оста уйнаса, абыйсы Шәриф яхшы гармунчы була. Сүнчәләйнең музыкага, сәнгатькә гашыйклыгы әсәрләрендә дә чагылыш таба. Шәхси архивында ул иҗат иткән унлап көй-җырның ноталары саклана.

1909 елның 11 февралендә «Йолдыз» газетасында шагыйрьнең «Мөгаллим Сүнчәләй» имзалы тәүге шигыре басылып чыга. Хәер, ул элегрәк тә кулына каләм алгалаган: Әстерханда яшәгән чакларында ук «Борһане тәрәккый» газетасына хәбәрләр җибәреп тора, 1908 елда Казанда «Кавказ тоткыны», «Тунгатай» исемле тәрҗемәләре, «Күл – күз яше» исемле хикәясе басыла. Әмма шигърияткә ныклап кереп китүе 1910 еллардан була: лирик геройның үзенчәлекле романтик хис-кичерешләре белән сугарылган шигырьләре, рус әдәбиятыннан ирекле тәрҗемәләре «Идел», «Бәянелхак», «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Вакыт», «Нур», «Сибирия», «Кояш», «Шура», «Сөембикә», «Ак юл» һ. б. газета-журналларда әледән-әле чыгып тора (алар «Учитель С. Сүнчәләй», «Сәгыйть бине Хәмид», «Сүнчәләй оныгы», «Сәгыйть Әбүлфәрит», «Әбелфәрит Вәккас», «Сәгыйть» тәхәллүсләре белән бастырыла) [11: 164]. 1912–1913 елларда аның «Төрле шигырьләр», «С. Сүнчәләй шигырьләре» исемле җыентыклары дөнья күрә.

Сүнчәләйнең иҗат мирасы белән танышканда, аның рус һәм Көнбатыш әдәбияты вәкилләре иҗатыннан яхшы ук хәбәрдар икәнлеген күрми калмыйсың. Бу әдәбиятлардан ул аерым әсәрләрне тәрҗемә дә иткән, кайберләре тәэсирендә оригиналь шигырьләр дә тудырган, теге яки бу шигъри юлларны эпиграф итеп тә файдаланган. Рус һәм

Көнбатыш әдипләреннән бигрәк тә Гейне, Плещеев, Надсон, Крылов, Тургенев, Жуковский, Толстой, Лермонтов, Майков, Некрасов, Никитин, Шевченко, Хомяков, Пушкин, Тан (Богораз), Бальмонт, Блок, Верхарн, Данте, Орешин, Уитмэн, Омулевский, Л. Мельшин (Якубович), Байрон, Гюгога мөрәҗәгать иткән. Р. Мостафин Сүнчәләйнең Шәрык телләреннән тыш, Байрон белән Гейнены турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә иткәнлеген күрсәтә. Шунысын да искәртергә кирәк: ул еш кына тәрҗемәләрен татар тормышына яраклаштырып эшли. Мәсәлән, 1911 елда ул Пушкинның «Коръәнгә тәкълидләр»ен татарчалаштыра (аерым өлешләре «Йолдыз», «Идел» газеталарында басыла, 1911 елда китап булып дөнья күрә). Күпмедер вакыттан Г. Гейненың атаклы «Әл-мансур»ын тәрҗемә итә. 1913 елда Сүнчәләйнең бөтен шигъри иҗатын тупас рәвештә юкка чыгарып рецензия язган Ф. Сәйфи-Казанлы бу тәрҗемәне уңышсыз дип санаган, ә Г. Ибраһимов, З. Кадыйрилар исә әлеге ирекле тәрҗемәгә уңай караштa торганнар. Патша цензурасы бу трагедиянең татар сәхнәсенә менүенә тоткарлык ясап килә, шунлыктан ул бары тик Февраль революциясе алдыннан гына сәхнәләштерелә: башта – Оренбургта, ә 1917 елның мартында исә Казанда уйнала.

1914 елларда Сүнчәләй рус язучысы Изабелла Гриневскаяның Ирандагы милли-азатлык хәрәкәте тарихыннан алып язылган «Баб» трагедиясен тәрҗемә итә, озак еллар (1912–1928) авторның үзе белән хат алышып яши («Милая Зулейха» – «Моя апа» – «Изабелла Аркадьевна!»ларга адресланган унбиш хаты белән «Әсәрләр һәм хатлар» китабында танышырга мөмкин). Сүнчәләй 1921 елгы бер хатында зур күләмле бу әсәргә Г. Рәхим, Ф. Әмирханнарның бик яхшы бәя бирүләрен шатланып хәбәр итә. Әмма никадәр югары бәяләнмәсен, шагыйрь үзе ничек кенә тырышмасын – «Баб» трагедиясе нәшер ителми кала (кульъязмалары хәзерге вакытта Татарстан Республикасы милли музеенда саклана). И. Гриневская, үз чиратында, Сүнчәләйнең берничә шигырен русчага тәрҗемә иткән. «Тормыш» газетасының 1916 елгы 30 ноябрь санында хәбәр ителгәнчә, Сүнчәләй, М. Горькийга да хат язып, аңардан «Тормыш төбендә» («На дне») пьесасын татарчага тәрҗемә итәргә рөхсәт сораган була һәм рус әдибе рөхсәтен дә бирә, әмма пьесаның тәрҗемә ителү-ителмәве әлегә билгесез.

С. Сүнчәләйнең тормышы һәм иҗатының 1910–1915 елларга нисбәтле сәхифәләре Г. Тукай белән аралашу мизгелләренә дә бәйле. «Тукай бәйрәме» (1913), «Тукай турында истәлек» (кульъязма, 1923), «Мәрхүм Тукай турында» (кульъязма, 1928) кебек язмаларын, «Хат кисәге», «Тукай рухы» кебек шигырьләрен, Тукайның аңа адресланган хатларын укыганда, бөек шагыйрьнең Сәгыйтьне «Сине мин һәр тугрыда садәдил кеше таптым», дип язуы ихластан булганлыгына инанасың. Ике шагыйрь 1910 елның маенда бер көтепханәдә (нәшрияттадыр. – *З.Р.*) йөзгә-йөз очрашкач, Сүнчәләй үз исемен әйтеп үк күрешмәгән әле («...минем шигырь язуымның башлангыч елы гына булганга, бу мөһим булмас кебек күренгән»). Шулай да көзен

Сүнчәләй «инициативасы» белән алар арасында хат язып аралашу башланып киткән. Кызганыч ки, Сүнчәләй хатларының берсе дә сакланмаган, ә Тукайның аңа язган 8 хаты, күчермәдә булса да, Шәриф Сүнчәләйдә исән калган (дүртесе югалган). 1910 елның 9 ноябре белән даталанган беренче хаттан күренгәнчә, Тукай 1910 ел дәвамында вакытлы матбугат битләрендә (мәсәлән, «Шура» журналында, «Бәянелхак» газетасында) шактый еш күренә башлаган С. Сүнчәләй шигырьләре белән инде таныш була. Аның «дустанә озаткан» кулын шатланып кабул итүен әйтеп: «...кулыма төшкәндә, шигырьләреңезне укыйм. Сездә милләткә яки шөһрәткә бик кызу мәхәббәт бар», – дип яза. Шул ук вакытта кайбер фикерләре белән дә уртаклаша. Мәсәлән, ул Сүнчәләй шигырьләре телендә «провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр» табуын, «Казанны тәхте пай һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип» санавын яза. Бу хәерхаһлы, эчкерсез хатны алган Сүнчәләй, кыюланып китеп, 4 декабрьдә икенче хатын да юллый һәм анда үзе тәрҗемә итә башлаган Байронның атаклы «Шильон мәхбүсе» исемле романтик поэмасының берничә сәтырын (өлешен) Тукай хөкеменә тәкъдим итә. Тукайның җавап хатындагы «Элек вак шигырьләр тәрҗемә кылып карарга кирәк», дигән үгетен ишетсә дә, Сүнчәләй, поэманы тәрҗемә итеп бетергәч, текстны (тулысы белән) Тукайга җибәргән. Сүнчәләйнең «Тукай турында истәлеге»ндә искәртелгәнчә, Тукай бу юлы поэманы ошаткан, «хәтта төзәткәләп күчереп тә чыккан һәм “Мәгариф” нәшриятына басарга да биргән». С. Кудашның язуына караганда, 1918 елның 2 апрелендә Уфада булган Тукай кичәсендә Сүнчәләй Тукайның үзенә язган хатларын укып та күрсәтә (кичәдә Х. Туфан мандолинада уйный).

С. Сүнчәләй Октябрь революциясен «инсаният тарихының иң мөкатдәс бер таңы» рәвешендә кабул итә (бу вакытта ул Уфа шәһәр көтепханәсенең татар бүлегендә мөдир булып эшли), хуплавын шигырьләрендә чагылдыра, «Интернационал», «Марсельеза», «Матәм»нәрне татарчага тәрҗемә итүче дә ул була.

1919 елның 16 маенда большевиклар партиясенә кергән, актив табигатьле Сүнчәләйгә шунда ук җитди эш йөкләнә: ул, үзәк органнарның кушуы буенча Кырымга килеп, Ялта өязендәге Партанет авылында мөгаллимлек итә. Шул вакытларда язып барган көндәлегеннән күренгәнчә, әдип биредә Казанны, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирханны сагынып яши. Шулай ук Верхарнның «Таң»ын, Метерлинкның «Сукырлар»ын тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Аның 1917–1920 еллар шигырьләрендә (алар әллә ни күп түгел) инкыйлаб белән бәйле мотивлар өстенлек итә, шул ук вакытта лирик «мин»не табигать үзгәрешләре, мәсәлән, язгы хисләр, интим кичерешләр дә биләми түгел. 1918 елда ул «Йосыф Акчура хәзрәтләренә» шигырен, кала тормышын тәнкыйтьләгән «Шәһәр» дигән әсәрен («Синдә нур юк!.. Син һаман сәүдәң белән мәшгуль мәгәр... Кайный бәгыреңдә мәкер, гайбәт, хәбәр...») яза.

1920 елның 25 июнендә көндәлек дәфтәренә теркәлгән түбәндәге юллар Сүнчәләйнең бу чордагы уйлары партия әгъзасы өчен бик үк хас түгеллеген ача: «Бу көннәрдә ихтилалга нык катнашу фикереннән ваз кичү нияте белән мәшгульмен... Ихтилалга иштиракем (*катнашуым*) файдасыз (хосусән, үзем өчен вә үз хәятым өчен) булыр дип уйлый башладым...»

Ике айдан соң Изабелла Гриневскаяга язган хатында Сүнчәләй үзенең каты салкын тидерүен, үпкәләре зарарлануына борчылуын да хәбәр итә. Рус шагыйрәсе белән язышкан хатларында аның «Баб» әсәренең тәрҗемәсе басылмавына, сәхнәдә куела алмый торуына кәефе юклыгы да чагыла; шул ук вакытта әсәрнең текстын камилләштерүен дәвам итүе аңлашыла.

Кырымда хакимият Деникин кулыннан Врангельгә күчкәч, С. Сүнчәләйгә биредә яшерен эшләрен алып бару кыенлаша һәм аңа 1920 елның июлендә Кара диңгез аша Төркиягә качып чыгарга туры килә. Көзен, өч айдан соң, Сүнчәләйнең Новороссийск шәһәре аша Мәскәүгә кайтып кергәнлеге, Кырым һәм Төркиядәге иҗтимагый-сәяси вазгыять турындагы фикерләрен партия Үзәк Комитетына, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына язып биргәнлеге мәгълүм.

Бераздан Врангель дә җиңелә һәм Сүнчәләйне яңадан Кырымга җибәрәләр. Биредә өч ай торгач, партия Үзәк Комитетына адресланган доклад язмасында Сүнчәләй совет властен күтәреп алган Кырым халкында ачлык хөкем сөрүен, җирләрнең крестьяннарга кайтарып бирелмәвен ачынып хәбәр итә. 1921–1922 елларда Милләтләр эше буенча халык комиссариаты вәкиле сыйфатында Кырым Республикасында эшләгән Сүнчәләй Сталинга җибәргән хисабында берише ОГПУ хезмәткәрләренең кайбер татар авылларында законсыз репрессияләрен туктату, җирләрне крестьяннарга кайтарып бирү, мәгариф эшләрен җайга салу, ачларга ярдәм итү буенча чаралар күрелмәгәнлеген яза, совет түрәләренең ачлыктан җәфа күрүче җирле татар халкы турында аз кайгыртуларына басым ясый.

1922 елда Сүнчәләй татар-башкорт композиторы Камил Йосыф улы Рәхимовның (1900–1978) туганнан туган сеңелесе, тумышы белән Азәрбайҗанның Гянҗә шәһәреннән булган актриса Әминә Милүшевага өйләнә (әдип, «Баб» сәхнәдә куела калса, төп рольне – Хөрриятел-Гайнны – Әминәсе уйнавына өметләнгән була). Кызганыч, 1925 еллар уртасында алар аерылышалар, әмма Сүнчәләй Соловкида утырганда, аларның әле хат алышулары мәгълүм. 1929 елның 2 гыйнварында Сәгыйтькә: «В театре дела идут хорошо», – дип язса да, тиздән, 23 апрельдә Әминәнең театр белән шартнамәсе туктатыла, имеш, «элементар политграмотасы юк, үз өстендә эшләми». Кызлары Таһирә дә иртә вафат була.

Әдипнең 20 нче еллардагы тормышы, әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге күпмедер дәрәҗәдә Уфа шәһәре белән дә бәйле. Биредә ул Башкортстан Республикасы Мәгариф комиссариатында кол-

легия әгъзасы һәм сәнгать бүлеге мөдире, Уфа сәнгать музее мөдире, театр сәнгате техникумы җитәкчесе булып эшли. 1928 елда Казанда Татар мәдәният йорты гыйльми секретаре вазифасын да башкара.

Шомлы, фаҗигалы 30 нчы еллар килеп җитә. Яңа гына СССРның Төркиядәге (Измир шәһәрендәге) генераль консуллыгында бер ел эшләп кайткан Сүнчәләйне 1927 елның 1 июнендә кулга алалар. Төркиядә З. Вәлиди белән бәйләнештә булуда, «солтангалиевче», милләтчеләр оешмасы эшенә катнашуда гаеплиләр. Бу юлы әле аны тиз аклыйлар, партиягә дә кире алалар. Әмма күп тә узмый, 1929 елның 28 февралендә Сүнчәләй, «солтангалиевчелек»тә гаепләнеп, кабат кулга алына. Сталинга, Ягодага, ОГПУның Көнчыгыш бүлегенә үзенең гаепсезлеген дәлилләп җибәргән хатлар да нәтиҗәсез кала, шагыйрьнең язмышы, инкыйлаб чоңгылына килеп кергән башка бик күп күренекле татар зыялыларыныкы кебек үк, фаҗигалы тәмамлана: Соловки концлагерьларында алты ел сөргендә тотылып, 1937 елның көзендә инде иреккә чыгар вакыты җиткәндә, туганнары янына тиздән кайтуны өмет иткәндә генә (бу хакта С. Сүнчәйләнең хатлары сөйли), НКВД «махсус өчлеге»нең карары белән шул елның 25 октябрендә аның гомере өзелә.

1995 елның 6 декабрендә бер әңгәмә вакытында Бакый ага Урманче «Без Сәгыйтьне Тукайның варисы дип исәплидер идек... Аның теле – Тукай теле. Тукайдан соң зур шагыйрь була торган кеше», дип сөйләгәне хәтердә. Шунлыктан да 2005 елда чыккан «Әсәрләр һәм хатлар» китабына кереш мәкалә «Тукай фатихасын да алып...» дип исемләнгән иде. Олуг аксакалларыбыз Тукайның варисы дип санаган, бөек шагыйребезнең садәдил дусты булган Сәгыйть Сүнчәләй иҗатының академик басмаларын төзү, әдәби мирасын фәнни яктан тирәнтен өйрәнү, халкыбызга кайтару вакыты җиткәндер дип уйлыйбыз.

**Әдәбият**

1. *Габдрафикова Л.Р.* Татарский поэт Сагит Сунчелей и Крым начала 1920-х гг. // Крымское историческое обозрение. Т. 10. 2023. № 1. С. 106–119.

2. *Галимова Э.М.* Сәгыйть Сүнчәләй һәм музыка // Фәнни Татарстан. 2020. № 1. Б. 100–103.

3. Замандашлары Сәгыйть Сүнчәләй турында (Зөфәр Рәмиев кереш сүзе белән) // Казан утлары. 2019. № 8. Б. 179–183.

4. *Зарипова Р., Мусабәкова Р.* Сәгыйть Сүнчәләй // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 4 т.: XX гасыр башы. Яңарт. һ. тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. Б. 398–413.

5. Ишморат Р. Сәгыйть Сүнчәләй // Яшь ленинчы. 1977. 15 янв.

6. *Камалиев Т.С.* Поэмы Сагита Сунчалея // Материалы IV конференции молодых научных работников. Казань, 1976. С. 68–70.

7. *Мәһдиев М.С.* Тукайның садә дусты // Казан утлары. 1979. № 8. Б. 177–178.

8. *Мусабекова Р.Р.* Сагит Сунчелей: Личность поэта и мотивы творчества: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 208 с.

9. *Мустафин Р.А.* Силуэты: литературные портреты писателей Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 350 б.

10. *Нагимов Н.И.* Переводы Сагита Сунчелея из западноевропейской литературы: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 173 с.

11. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе / редкол.: И.Г. Гомәров (проект җит. һ. җав. мөх-р), Ә.М. Закирҗанов, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.Н. Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021, 10 нчы чыг. Б. 164.

12. Сәгыйть Сүнчәләйнең иҗат мирасын туплау // Совет Татарстаны. 1958. 14 окт.

13. *Сүнчәләй С.* Әсәрләр һәм хатлар / төз., текстларны, иск. һ. аңлатмаларны әзерл. Зөфәр Рәмиев; ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 367 б.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор (Казан)*

***Рамеев Зуфар Зайниевич,***
*доктор филологических наук, профессор (Казань)*

УДК 821.512.145+821.512.152

***А.М. Шаронов***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕ ЭРЗЯ ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘДӘ

В статье представлен опыт переводов стихотворений классика татарской поэзии Г. Тукая на эрзянский язык. Автор переводов – поэт и ученый-филолог А.М. Шаронов – определяет принципы, которыми он руководствовался при переводе: использование оригинальных текстов для передачи ритма стихотворений и особенностей их поэтики; обращение к существующим переводам на русский язык для представления о существующей переводческой традиции. Сформулированы принципы, позволившие переводчику передать ритмику тукаевских стихотворений, несмотря на различия татарского и эрзянского языков. Сравнив некоторые переводные тексты с оригиналами, автор статьи определяет ключевые особенности творчества татарского поэта, выделяет наиболее частотные образы и мотивы: любовь к своему народу, мифологизация образа Казани, призыв к просвещению и др. В исследовании делается вывод об актуальности и своевременности перевода произведений Тукая, представляющим собой интересный, незнакомый для эрзянских читателей синтез европейских и восточных литературных традиций.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, перевод, эрзянский язык, татарский язык, поэтика.

The article presents the experience of translating poems by the classic of Tatar poetry G. Tukay into the Erzya language. The author of the translations, poet and philologist A.M. Sharonov, defines the principles that guided him in the translation: using original texts to convey the rhythm of the poems and the features of their poetics; referring to existing translations into Russian to understand the existing translation tradition. The principles that allowed the translator to convey the rhythm of Tukay's poems, despite the differences between the Tatar and Erzya languages are formulated. Having compared some translated texts with the originals, the author of the article defines the key features of the Tatar poet's work, highlights the most frequent images and motifs: love for his people, mythologization of the image of Kazan, a call for education, etc. The study concludes that the translation of Tukay's works is relevant and timely, representing an interesting synthesis of European and Eastern literary traditions, unfamiliar to Erzya readers.

**Keywords:** G. Tukay, translation, Erzya language, Tatar language, poetics.

Бер халыкның менталитеты, морфологиясе, синтаксисы, фонетикасы, поэтикасы һәм эстетикасы үзенчәлекле булган шигъри әсәрләрен икенче телгә тәрҗемә итүне бары тик шул икенче тел мөмкинлекләре чикләрендә генә башкарырга була. Шул ук вакытта, авторның исеме саклanса да, төп нөсхә текст тәрҗемә текстка субстанциональ яктан тулысынча тәңгәл килә алмый.

Тәрҗемәнең сыйфаты, әлбәттә, тәрҗемәченең әдәби сәләтенә, тырышлыгына һәм башкарыла торган эш өчен җаваплылыгына да бәйле.

1995–1997 елларда Мордва китап нәшрияты белән килешү нигезендә эрзя теленнән рус теленә үзем авторы булган «Масторава» эпопеясын тәрҗемә иттем. Үзенең шигъри билгеләре белән оригиналга тәңгәл булган текст әзерләү бурычы куелган иде. Әмма бу бурыч тулысынча хәл ителмәде: чөнки тәрҗемә, никадәр сыйфатлы килеп чыкмасын, әдәби әсәр булган һәм халыкның рухи мәдәниятендәге үзенчәлекле гуманитар катлам хасил иткән төп нөсхәдән калыша. Шигъри тезмәләр, 20–30 вариант арасыннан сайлап алынганда да, еш кына канәгатьләндерерлек булмады. Тәрҗемәдәге «Масторава» – бөтенләй башка әдәби әсәр булып чыкты. Бу бит әле төп нөсхә текстының эчтәлеген, ритмик төзелешен, сюжетларын, шигъри сөйләм үзенчәлекләрен, традицион поэтик образларын, символларны һәм мотивларны, тәрҗемә ителә торган текстның фикер һәм асмәгънә тирәнлеген, персонажларның психологиясен, эпопеяның мифологиясен һәм фәлсәфәсен бик яхшы аңлаган, белгән шартларда шулай.

2003 елда нәшер ителгән тәрҗемә [3] 2010, 2019, 2020, 2022 елларда кабат бастыру вакытында яңабаштан шактый эшләнде. Эпосның гомуми композициясенә, кайбер сюжет линияләренә үзгәрешләр кертелде (17 хикәят 21 гә әйләнде), шигырь һәм тәрҗемә теле камилләштерелде, тулырак искәрмәләр-аңлатмалар язылды. Шактый күпсанлы рецензияләрдә һәм бәяләмәләрдә [1; 4; 5] күрсәтелгәннәргә яраклашу да бар иде. 1994 елгы эрзя телендәге басмадан соң [2] 20–30 ел узгач, акрынлап «Масторава»ны Гомерның «Илиада» һәм «Одиссея», Леннротның «Калевала», Крейцвальдның «Калевипоэг» һәм башка эпопеялар белән бер рәткә куйган һәм аларны минем әсәр белән чагыштырып тагын бер кат укыган кешеләрнең бәяләмәләренә дә иярәшә башладым.

Күпьеллык тәҗрибә шуны күрсәтә: сәнгати, эстетик һәм филологик яктан тәңгәл, адекват сүзгә-сүз мәгънәви тәрҗемә ясарга кирәк булган. Шул вакытта төп нөсхә текстның нечкәлекләрен, үзеңне шигырьнең иҗек үлчәме кысаларына кертмичә һәм аның ритмикасын, көен саклап, күбрәк җиткерергә мөмкин.

Әлеге фикер Габдулла Тукай шигырьләрен эрзя теленә тәрҗемә иткәндә дә үзен гел сиздереп торды. Юлга-юл тәрҗемәләр (подстрочниклар) белән танышкач, алар белән генә чикләнеп булмаслыгы аңлашылды. Текстларның төп нөсхәләрен өйрәнү зарур иде: шигырь үлчәме, тезмәләрнең ритмик оешуы нинди, алар нинди эзлеклелектә рифмалаша, филологик һәм логик фигуралар ничек кабатлана. Гомумән, татар шигъри теле нинди? Әлеге эшне башкарып чыккач кына, Тукай поэзиясен, аның шигъри даһилыгының үзенчәлеген, шигырьләренең поэтикасын һәм эстетикасын, татар иҗади менталитеты аңлашылды. Шуннан соң гына уникаль милли аңга ия булган, туган халкына хезмәт итү, аның исемен данлау дәрте-омтылышы белән мавыккан шагыйрь сурәте килеп басты. Габдулла Тукай исә эрзя теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрендә генә шәхес һәм иҗатчы буларак тулысынча ачылды. Эрзя телендәге шигырьләрендә дә ул оригиналь

татар шагыйре булып калды. Әлбәттә, тәрҗемәләр рус шагыйрьләренең рус теленә тәрҗемәләре белән дә чагыштырылды. Алар арасында оригиналларга мөмкин кадәр якын булган иң яхшы тәрҗемәләрне А.А. Ахматова башкаруын әйтергә кирәк.

Тәрҗемәләр эшләү барышында татар теле белән якыннан танышырга мөмкинлек туды. Ул – гадәттән тыш матур, музыкаль һәм көйле, фикерләрнең һәм тойгыларның бик күп төсмерләрен, әдәби образларны һәм логик фигураларны чагылдырырга сәләтле тел. Татар теле татарларның әдәбиятта, сәнгатьтә, социаль һәм сәяси тормышта, фәндә һәм мәгарифтә гадәттән тыш маһир булуларының серен чишү өчен нигез бирде. Бу сер исә – татарларның үз исемен һәм асылын кадерләве, олылавы – Татарстанга Россиянең уңышлы, зур тизлектә үсеп килүче республикасы булырга мөмкинлек бирә.

Габдулла Тукай шигырьләрендә үз халкының яңарышы өчен җан аткан патриот-шагыйрь буларак чыгыш ясый. Ул этник сюжетларга, мотивларга һәм образларга бай катлаулы шигъри аң-фикер иясе булган. Каршылыклы тоелсалар да, бу фикерләр антагонист түгел.

Тукай революция дәверендә, яңа иҗтимагый строй туган заманда яши һәм иҗат итә. Ул чор татар халкының социаль-сәяси һәм гуманитар яңарышына кагылышлы зур һәм бөек романтик өметләр һәм иллюзияләр белән бәйләнгән. Шушы идеяләр белән илһамланып, ул Казан шәһәренә, үз халкының мәдәни һәм цивилизация үзәгенә юнәлә, бу хакта «Пар ат» (эрзя телендә «Кавто лишметь») дигән шигырендә яза:

Мон кильдин кавто алашат ды Казанев сыргинь.
Кись паро, содавикс ды секс бойкасто ардыть сынь.
Чокшне. Ковось валдо валы сэтьме масторонть лангс.
Виресь чатьмони кинть ваксcо, коштось лембе ды ванькс...

Нама, вайгель гайкстась: «Ванок, икеленек Казань!
Кенярд, шакирд! Рангстак, шакирд: «Мон мазый ошов сан!
Мон сан ине ошов, кеняркс валдомты седеем».
Лишметне бойкасто ардыть, топавтыть монь мелем.

Сы валске, зоря кирвази, гайги мазый азан.
Вай, ине ош! Вай, паро ош! Вай, валдо ош, Казань!
Тесэ покштянь-бабань таркат, минек седеень рай.
Тесэ превть-содамот, книгат ды цеця потсо рай.
Тесэ превть-содамот, книгат ды цеця потсо май.
Тесэ тамашань тейтерькат, мазяргот-гурият...

(Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый <...>
Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит – Казан!». <...>
Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...)

Эрзя текстында Габдулла Тукайның шигырь формасы һәм эчтәлеге 70–80% ка саклана. Эрзя теле, татар теле белән чагыштырганда, ритмик яктан салмак хәрәкәтле, фонетик яктан озынлыкны ярата, синтаксик яктан сузынкы һәм сыгылмалы түгел, ә бу тәрҗемә иткәндә шактый кыенлыклар тудыра. Шуңа да карамастан, анда тиешле филологик структура һәм форма эзләү өчен мөмкинлекләр бар, һәм алар матур нәтиҗә бирделәр.

Казан образы «Туган җиремә» / «Тиринь масторнэнь» шигырендә дә сурәтләнә:

Куш мон каднытинь тонь умок ютазь од шкасто,
О Казань, таго велявтынь ва, тон а паневат седейстэнь ды прястон.
Тонь паксятне-лугатне таго элезэст тердить,
Монь псистэ кутмордамо прок авам венстизь кедест...
Весе тесэ Пазонь: лейтне, виртне, паксятне..,
Весе паро ломантне – и сыретне, и одтнэ.

(Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.
Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми.
Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың.)

Тукай өчен Казан – ана кочагы ул!

Габдулла Тукай «Бер татар шагыйренең сүзләре» / эрзя телендә «Татаронь поэтэнь валт» шигырендә туган җиренә һәм якыннарына мәхәббәтен, җанына якын татарларына мөнәсәбәтен белдерә. Эрзя телендә бу болай яңгырый:

Сёрмадан стихть, морот моран тонеть, тиринь мастор.
А пелян ёвтнемс тынк кувалт, монь вечкевикс татарт.
Куш ружиясо кортадо, вечкевиксэм, мартон,
Кадован мон яла теке эрямом перть мартонк...

Кувака кинть мон изняса, сон ва нурькалгады,
Бути мелем виев, сэстэ пильгтнеяк а сизить.
Аволь сокоро мон, валдось мастор келес срады,
Пазось молицятнень вечки, ськамост сынст а кадсы.

(Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да. <...>

Максуд җитәр: бара торгач – юл кыскарыр;
Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр;
Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,
Тәңрем фәйзы минем күңлемгә эз салыр.)

Татар шагыйре эрзя телендә татар һәм эрзя менталитетлы шәхес булып тоела. Аның татар шагыйре булуын татарларга мөрәҗәгате генә искәртә:

А пелян ёвтнемс тынк кувалт, монь вечкевикс татарт.

(Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да.)

Мондый шигъри әверелеш – күрәсең, әдәби тәрҗемәнең кирәкле шарты, чөнки төп нөсхә текст тәрҗемә ителә торган тел чикләрен җиңеп чыгу мөмкин түгел. Эрзя телендәге татар шагыйре, рус телендә – руска охшап киткән шикелле, күпмедер дәрәҗәдә эрзягә әверелергә тиеш. Мондый күренеш Габдулла Тукайның эрзя теленә тәрҗемәләрендә дә күзәтелә.

Габдулла Тукай үзенең шигъри сәләте турында югары фикердә була. «Пушкинә» / «Пушкиннэнь» шигырендә ул үз иҗатының да аның дәрәҗәсенә күтәреләчәген кире какмый:

Паряк, монгак мик сонзэ сэрьс эсень стихсэ касан.

(Минем дә дәртем-теләгем нәкъ синең дәртең белән бер)

Мондый психологик караш гадәти булмаган шигъри әсәрләр тудыру өчен кирәкле шарт исәпләнә, сәнгать даһие аны үзенең көчле иҗади энергиясе белән тулыландыра. Бу хәрәкәтне, шигырьгә юлны ачык аңлаган шагыйрь Аның илһамландыргыч көченә өметләнгән:

Истямо бажамом... паряк Пазось максы тень вийть,
Тонь кондямот Сон, паряк, максы валморонь вийть.

(Әйе, теләгем бер генә, әмма юк шул миндә куәт;
Өмет итәм, кодрәтле зат бирер дип, дәрман да, шаять.)

Һәр талантлы шагыйрь диярлек – философ, миф тудыручы, үзен Илаһның сөеклесе дип уйлаучы һәм иҗади мөмкинлекләрен Аллаһ образы белән бәйләүче, үзе иҗат иткән әсәрләрнең аңа бик озак рухигаклый тырышлык-хезмәттән соң күктән иңүен аңлаучыдыр. Мөгаен, шуңа күрә дә аның шигырьләрендә һәрвакытта да ахыргы максатны ачык билгеләп булмый. Интуиция алгы планга чыга.

Габдулла Тукай кешеләрне Аллаһ хакына бердәм яшәргә өнди:

Эряви ве мельсэ эрямс Аллахонь вечкемать кисэ.
Эряви каштанчинть киртямс Аллахонь вечкемать кисэ.

(Без дә бер кешедәй дус булыйк, Алла гыйшкы хакына;
Эрелек, төче теллелекне ташлыйк, Алла гыйшкы хакына.)

Аллаһны ярату, акыл, игелек, мәхәббәт, яктылык, иминлекнең бетмәс-төкәнмәс изге чыганагы буларак, бәла-казалар, бәхетсез-

лекләрне юкка чыгарачак, нәтиҗәдә имин, тыныч тормыш башланачак. Бу өметтә – беркатлылык түгел, ә шагыйрьдәге күрәзәчелек чагылыш таба.

Габдулла Тукай туган халкын агартуга, китаплар, газета-журналлар чыгаруга зур әһәмият бирә. «И каләм!» («О Толга!») шигырендә ул халыкның социаль, гуманитар һәм менталь алгарышын белем һәм мәгърифәт таралу, явызлык тудыручы авырлыклардан котылу белән бәйли:

О Толга, кадык майсематне ютыть, макст миненек кенyarkсчить.
Тонь марто кадык минь муйтяно виде кить…
Мик менельс Европанть тон, Толга, кепедик,
А минек туртов нать лавшомсть тонь кедеть…
О Толга! Сюлмазь мартот минек уцяскась.
Учотано кеняркст, сынст максы сыця шкась...
О Толга! Свал ванок тон валдо сельмесэ.
Кадык ёмить зыянтнэ – аволь сядо, весе.

(И каләм! Китсен газап, ит син безне шат;
Без дә синең арканда туры юлга басыйк аяк. <...>
Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр,
Ник төшердең безне – җиде кат җир астына кадәр? <...>
И каләм, бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер;
Якты киләчәгебез дүрт күз белән рәхмәтеңнән көтелә <...>
И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит;
Хәсрәт, хурлык, мескенлекләр – мәңгегә кит!)

«Син булмасаң» («Бути аволь ули тон») шигырендә шагыйрь үзенең сөйгәненә хисләрен белдерә. Аның дөньяга карашы-тоемы һәм яшәү сыйфаты шул хисләргә бәйле:

Аволь палы бу седеем, бути аволить ули тон.
Авольть чуди бу сельведем, бути аволить ули тон...
Сэтьме сельмесэ вановлинь валдо чинть ды ковонть лангс.
Апак кавтолдо эрявлинь, бути аволить ули тон...
Прям монь валдо улевель, бути аволить ули тон.

(И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң! <...>
Юаныр идем бераз кояшка йә айга карап, –
Матурлыгың белән аларны каплаучы булмасаң! <...>
Дәрвиштәй, Аллага чын күңелдән кол булыр идем, –
Тәшвиш белән күңелемне аздыручы булмасаң!)

Эрзя шигъриятендә Габдулла Тукайдагы Шәрык шагыйрьләре шигъри әсәрләреннән үк килгән, иҗатына аерым бер гүзәллек, аһәң өсти торган шигъри формалар юк. Болар рус поэзиясендә дә юк. Мөселман дөньясы шигърияте, мөселман дөньясының үзе кебек үк, Тукай өчен метафизик субстанция булып хезмәт иткән. Һәм эрзя әдәбиятында мондый шигърият пәйда булу, һичшиксез, уңай роль уйнаучы кызыклы да, уникаль дә күренешкә әверелә. Ничек кенә

булмасын, Габдулла Тукай эрзя шагыйрьләрен яңа образлар, мотивлар, сюжетлар, идеяләр, персонажлар белән таныштыру һәм баету ягыннан сизелерлек йогынты ясаячак.

XX–XXI гасырның эрзя әдәбиятында Мордовия Республикасыннан читтә артык танылмаган талантлы шагыйрьләр бар. Болар – Пётр Кириллов, Артур Моро, Серафим Вечканов, Василий Радаев, Пётр Гайни, Иван Калинкин. Алар совет чорының талантлы рус шагыйрьләре дәрәҗәсендә иҗат иттеләр. Кызганычка каршы, шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итү һәрвакытта да оригиналга туры китереп эшләнмәгән. Бу раслау, мөгаен, башка рус телле булмаган авторларның тәрҗемә ителгән текстларына карата да кабатлана аладыр.

Габдулла Тукай әсәрләре Россиянең һәм дөньяның күп кенә халыклары телләренә тәрҗемә ителгән. Аның шигырьләре белән бергә, көчле таланты яктысында, яңа биеклектән татар халкының – аңа бөек әдәби талант бүләк иткән милләтнең – гуманитар образы да калкулана. Әлеге талантны Тукай, олы рәхмәт белән һәм илһамланып, халкы файдасына тормышка ашыра алган. Шигырьләре эрзя телендә дә бөек мәгънәләр һәм романтик шигъри гүзәллек белән тулып яңгырар дип өметләнәсе килә. Шул ук вакытта алар үз милләтенә ихластан һәм бирелеп хезмәт итү ягыннан эрзя шагыйрьләренә үрнәк булырлар. Бу исә аның образында яктылык һәм нур, мәхәббәт һәм романтик сулыш белән өретелгән, матур, җырлы-моңлы, мифологик һәм фәлсәфи цивилизацияле, заманча технологияләр һәм борынгы бабалардан кыйммәтле мирас булып калган риваятьләр һәм әкиятләр дөньясында яшәүче татар халкының җан җылысын чагылдырырга тиеш.

**Әдәбият**

1. *Демин В.И.* Свет «Масторавы» // Вестник Мордовского университета. 1996. № 2. С. 59–62.

2. Масторава: кемгавксово ёвтамот эрзянь ды мокшонь раськетнеде / эрзянь ды мокшонь кезэрень пингень мифтнень, эпической моротнень ды ёвтамотнень коряс сёрмадызе А.М. Шаронов = Масторава: восемнадцать сказаний о народах эрзя и мокша / на основе эрзянских и мокшанских древних мифов, эпических песен и сказаний написал А.М. Шаронов. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1994. 496 с.

3. Масторава / на основе эрзян. и мокшан. мифов, эпич. песен и сказаний написал А.М. Шаронов. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 2003. 488 с.

4. *Федосеева Е.А.* Масторава // Регионология. 2003. № 4. С. 328–330.

5. *Чиняев Н.И.* «Масторава» – эпос эрзи и мокши // Мордовия. 1995. 23 марта.

***Шаронов Александр Маркович,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Социаль-икътисади мониторинг фәнни үзәгенең баш фәнни хезмәткәре (Саранск)*

***Шаронов Александр Маркович,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник Научного центра социально-экономического мониторинга (Саранск)*

*sharon.ov@mail.ru*

УДК: 821.512.145

***Д.Ф. Заһидуллина***

# ФАТИХ ӘМИРХАН ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ТОРМЫШ (1906–1912)

Статья посвящена публицистической деятельности Фатиха Амирхана в 1906–1912 годах. Рассматриваются малоизвестные публикации, увидевшие свет на страницах газеты «Әлислах», анализируется творческая эволюция его политических, национальных, общественно-философских и культурно-эстетических взглядов. Установлено, что Ф. Амирхан стал одним из ведущих авторов социально-политических аналитических статей, при помощи пера превратился в лидера татарского возрождения. Он был сторонником идеи прогресса татарского народа, в критике и публицистике выступал за развитие национального образования, науки, культуры.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, возрождение нач. XX века, «Аль-ислах», публицистика, критические статьи.

The article is devoted to the journalistic activity of Fatih Amirkhan in 1906–1912. Little-known publications published on the pages of the newspaper “Al-Islah” are considered, the creative evolution of his political, national, socio-philosophical, cultural and aesthetic views is analyzed. It is established that F. Amirkhan became one of the leading authors of socio-political analytical articles, and with the help of his pen he became the leader of the Tatar renaissance. He was a supporter of the idea of the progress of the Tatar people, and in criticism and journalism he advocated the development of national education, science, and culture.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, renaissance of the beginning. Twentieth century, “Al-Islah”, journalism, critical articles.

Фатих Әмирханның татар журналистикасын һәм публицистикасын үстерүгә керткән саллы өлеше турында күзаллау 1984–1989 елларда әдипнең 4 томлыгы басылып чыкканнан соң шактый төгәлләшкән иде. М. Мәһдиев, Р. Әмирханов, Т. Гыйлаҗев һ. б. галимнәрнең эзләнүләрендә әдип – туып кына килгән татар матбугатының үткен карашлы журналисты, халык мәнфәгатьләрен алга куйган каләм иясе буларак күзалланды.

Ф. Әмирханның 6 томлыгы аның бай һәм күпкырлы язма мирасын тагын да тулыландыра, татар яңарышының әйдаманы булырлык акыллы һәм фикерле шәхесен дә укучыга төрле яклап күрсәтә. Бу яктан, 4–5 нче томнар өр-яңа материалларның күплеге, моңа кадәр билгесез кала килгән тирән эчтәлекле, татар дөньясындагы, илдәге, дөньядагы һәр вакыйгага мөнәсәбәт белдереп язылган, замандашларының фикер-карашларын үзгәртүгә, үстерүгә юнәлтелгән, аларны милләтнең якты киләчәге өчен хезмәт итәргә өндәгән күпсанлы текстларга байлыгы ягыннан аерылып тора.

4 нче том 1906–1912 елларда язылган публицистика һәм әдәбият-сәнгать тәнкыйтен үз эченә ала. Публицистик язмалар арасында иҗтимагый-сәяси тематика өстенлек итә. Аларның зур күпчелеге «Әлислах» газетасында дөнья күрә. Гомумән алганда, газета исеме (реформа, яңарыш, үзгәреш) Ф. Әмирхан өчен символик мәгънәгә ия була [2: 105–115]: ул татар халкының алгарышына хезмәт итүне гомерлек максат итеп ала; шул исемдәге гектографта басылган мәдрәсә газетасында шәкерт Фатих журналистика һәм хөр фикерне укучыга җиткерү серләренә төшенә; шул исемдәге тулы канлы басмада ялкынлы каләм иясе булып җитешә.

Әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендә дә Ф. Әмирхан шушы елларда канат ныгыта. Т. Гыйлаҗев фикеренчә, «тәнкыйтендә рецензия, фельетон, монографик мәкалә, әдәби портрет, әдәби күзәтү кебек жанрлар актив. Ф. Әмирханның эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең предметы, бурыч-максатлары, принциплары ачыклана һәм фәнни яктан эшләнә» [5: 113].

Ф. Әмирханның басылып чыккан беренче публицистик мәкаләсе – «71 нче ел коммунасы (Париж эшчеләренең 1871 елда күтәрелүләренең кыска тарихчасы)» – «Әлгасрелҗәдид» журналының ике санында 1906 елның июнь-августында басылган. Асылда, Марек Конкольнең шул исемдәге поляк теленнән тәрҗемә ителгән һәм 1906 елда Санкт-Петербургта басылган китабыннан файдаланып эшләнгән булса да, язма яшь Ф. Әмирханның социалист-революционерлар позициясен якын күрүе турында сөйли. Бер яктан, анда Франция эшчеләренең буржуазия тарафыннан изелүе хакында сүз бара, инкыйлабларның асыл максатын аңлату омтылышы ясала. Уңай мисал итеп чит илдәге парламент идарәсе күрсәтелә. Шунысын да искәртергә кирәк: Россиягә Европадагы үрнәктә реформалар кирәклеге һәм конституцияне үзгәртү мәсьәләсе алдагы елларда Ф. Әмирханның Дума эшчәнлегенә багышланган һәр мәкаләсендә диярлек әйтеләчәк. Европадагы хәлләр белән татар укучысын таныштыру, күрәсең, Ф. Әмирхан өчен халыкның иҗтимагый-сәяси аңын-фикерен уяту, кузгату максатына ярашлы санала. Рухи хөрлек идеясе белән сугарылган брошюраны ул, мөгаен, шуның өчен сайлап алгандыр. М. Мәһдиев, архив материалына нигезләнеп, аның бу тәҗрибәсенең символик мәгънәгә ия булуын билгели, «тормышта нинди юл сайлавын, дөньяга карашын һәм рухи-политик үсешенең, эзләнүләренең кай тарафка юнәлгән булуын ачык күрсәтә» [6: 317], ди.

1907 елдан инде Әмирханның актив журналистлык эшчәнлеге башланып китә. Ул Мәскәүгә «Тәрбиятел-әтфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле беренче татар балалар журналы редакциясенә җаваплы сәркатип итеп чакырыла. Басманың һәр санындагы баш мәкаләләре журналны тулысынча планлаштыручы да, саннарның концепциясен эшләүче дә Ф. Әмирхан булганлыкны күрсәтә. «Идарәдән» дип исемләнгән бу мәкаләләр яшь буынның милли-иҗтимагый, мәдәни карашын формалаштыру юнәлешендә язылганнар.

Журналның 1907 елның 1 гыйнварында чыккан иң беренче саны «Идарәдән (Безнең киң ватанымызның...)» дигән язма белән ачыла. Анда 1905 ел башлаган демократик хәрәкәтнең татар җәмгыятенә тәэсире анализлана. Ф. Әмирхан карашынча, «Безнең киң ватанымызның бер читеннән икенче читенә барып чыккан халык хәрәкәтенең дулкыны, бу заманга кадәр таш кеби фикердә вә гамәлдә бер урында тик торырга гадәтләнгән мөселманнарны да эләктереп бераз кузгалтты» [7: 16]. Бу кузгалышны ул мәктәп-мәгариф эшләренең көн кадагына куелуында, заманча китаплар кирәклегенең аңлана башлавында күрә. Шушы шартларда ачылган балалар журналының бурычларын аңлатып үтә: укучыларны мәдәниятле халыкларның әдәбияты, тарих һәм хәзерге заман хәлләре белән таныштыру, табигыять хакында мәгълүмат бирү, журнал мәйданында алар белән әңгәмә алып бару шундыйлардан.

Икенче сандагы (1907 ел, 12 гыйнвар) «Идарәдән (Бу көн Мәккәи Мөкәррәмә...)» мәкаләсе Корбан гаете уңаеннан, шушы олы бәйрәм турында мәгълүмат биреп ачыла. Әлеге бәйрәмнең әһәмиятен Ф. Әмирхан мохтаҗларга ярдәм итүдә дип аңлата. Балаларга эндәшеп, әйләнә-тирәдәге ач-ялангачлар белән ризык бүлешүләрен, шуның белән башкаларга, хәтта бөтен дөнья халкына үрнәк күрсәтүләрен сорый: «Күрсәтеңез бөтен дөньяга ничек тәрбияле сабак балалары кызганучан вә ярдәм итүчән булганлыкларыны!» [7: 29].

Өченче сандагы «Идарәдән (Яңа ел мөбарәк булсын!)» дигән баш мәкалә һиҗри 1325 ел тулу уңаеннан әзерләнгән. Укучыларына «милләтебезнең булачак әгъзалары» дип эндәшеп, әдип балаларга үз халкын бәхетле якты киләчәккә чыгару өчен тырышу кирәклекне, моңа ирешү өчен гыйлем һәм фән генә ярдәм итә алачакны сөйли, «өйрәнеңез, укыңыз, зыяланыңыз» дигән сүзләр белән мөрәҗәгать итә [7: 31].

Дүртенче сандагы (1907 ел, 15 февраль) «Идарәдән (Хөкүмәт, халыкның...)» мәкаләсе II Дәүләт думасы ачылыр алдыннан, укучыларга Дума эшчәнлегенең хакимияткә – үз эшен тәртипкә салу өчен һәм халыкка – аның ихтыяҗларын ачыклау һәм канәгатьләндерү өчен мөһимлеген аңлату максатыннан язылган. Шактый катлаулы әлеге мәсьәләне Ф. Әмирхан гади һәм бала өчен аңлаешлы итеп шәрехли. Шуның белән бергә, басым ясамыйча гына, автор җитди сәяси мәсьәләләр күтәрә: илдә идарә тәртибенең үзгәрүен «халыкның дәгъва-таләпләренә (требованияләренә) каршы тора алмаганлыктан» дип күрсәтә, хөкүмәткә адресланган тәнкыйтен дә («Думага (халык вәкилләре җыенына) хөкүмәт, падишаһ хәзрәтләренең һәр теләгенә юл куярга тиешле бер җәмгыять дип кенә карый иде»; «Икенче Дума да әүвәлгесе шикелле тыңлаусыз булмасын өчен, аннан башка да үзенең мәкъсудына ирешүдә һич нәрсәдән чирканмый торган хөкүмәт золым вә истибдад сәясәтене дә тагы да куәтләндерде»; «Сенат үзенең сайлау низамнарыны тәфсыйле белән әүвәлдә сайлау хакы булган бик күп гражданнарны бу хакларыннан мәхрүм итте» һ. б.) [7: 33].

Җәмгыятькә бәя биргән: «хөкүмәтнең бу кысуларына карамыйча, халык әүвәлге урыннарына кайта вә хөкүмәт Русиянең дошманы дип саный торган кешеләрне сайлый башлады», дигән сүзләр әлеге аналитик өлешкә нәтиҗә ясап куя [7: 34]. Ф. Әмирхан Дума эше нәкъ менә «хөкүмәт Русиянең дошманы дип саный торган» кешеләрнең кимүенә китерә дип исәпли. Сөйләшүнең дәвамы бишенче санга күчеп, аерым депутатлар, аларның сәяси позицияләре хакында фикерләшү төсен ала. Шул рәвешле, Ф. Әмирхан яшь укучысын уйландыра, гражданлык активлыгына чакыра, алар белән тиң куеп, үзен дә борчыган күзәтүләре белән уртаклаша.

Журналда Әмирхан кечкенәләргә аңлаешлы һәм тәэсирле итеп мәшһүр шәһәрләр (Истанбул, Мәскәү һ. б.), табигать күренешләре (кояш, йолдызлар, җир тетрәү), бакыйлыкка күчүләре нисбәтле – мәшһүр шәхесләр (Д.И. Менделеев, Галимәтелбәнат Биктимерия), бәйрәмнәр, фәнни һәм иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр (әйтик, Дума ачылу) турында сөйли, яңа татар әдәбиятының беренче карлыгачларыннан Г. Исхакый әсәрләрен укырга тәкъдим итә. Язмалар күләмле, мәгълүматлы булуга аерым игътибар итәргә кирәк. Әйтик, «Күктә күренә торган нәрсәләр» язмасы 3 санда (1, 3, 5) басыла һәм Галәм, аның төзелеше, планеталар һәм йолдызлар, Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе кебек бик күп күренешләргә туктала. Заманча фәнни мәгълүматлар – борынгы кешеләрнең ышанулары турында сөйләү белән үрелеп китә. «Гаяз» язмасы Г. Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләрен балаларга шәрехләп бирә.

«Тәрбиятел-этфаль», 5 нче саны нәшер ителгәч (1907 елның гыйнвар – март айлары), чыгудан туктый. Казанга кайтып киткән Фатихның аякларын, уң кулын 1907 елның 15 августында паралич суга. Шушы авырудан 21 яшьлек егетнең аяклары йөрми торган булып кала. Сау вакытында көчле оптимист, җилкенчәк Фатих, коляскага беркетелгәч, җитдиләнә, ләкин күңел көрлеген җуймый, беркайчан да авыруыннан зарланмый. Казанда ул гаять мөһим эшкә – «Әлислах» газетасын чыгаруга алына. Радикаль карашлы яшьләр матбугаты органы саналып, атнага бер тапкыр 16 битлек булып нәшер ителүче газетаның рәсми мөхәррире Вафа Бәхтияров исәпләнсә дә, рухын һәм эчтәлеген билгеләүче мөхәррире Ф. Әмирхан һәм Г. Тукай була [1: 4]. Бу хакта Ф. Әмирханның баш мәкаләләре (зур күпчелеге беренче тапкыр томлыкларга кергән) дә сөйләп тора. Алар, барыннан да бигрәк, әдипне олы фикер иясе һәм күренекле татар иҗтимагый-сәяси эшлеклеләренең берсе итеп таныта.

Газетаның иң беренче санындагы «Казан, 3 октябрь» дигән баш мәкалә татарларда иң актуаль тема буларак мәктәп-мәдрәсәләрне яңартуны күтәрә, нәкъ менә шуның газетада үзәк урынны биләячәген әйтә. Ф. Әмирхан мәсьәләне башка халыклар мәгарифе, татар мәгариф тарихы контекстында карый, ачынып болай ди: «...мәктәп вә мәдрәсәләремез безнең мәгыйшәтемезне (*тормышыбызны*) дә үзләре белән бергә XII–XIII гасыр халәтендә тотып килгәннәр <...> татар ба-

ларын <...> бөтен галәм мәгыйшәтендә иң вак вә хәкыйрь роль уйнаучылар итеп калдырганнар» [7: 48]. Шуннан чыгып, ул газетаның мәсләген аңлата: «лозунгымыз – “Гыйлем-мәгарифнең милләтемез арасына интишаре (*таралуы*) вә сәгадәте гомумия”дер». Чөнки: «Татарның мәгыйшәтене асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк» [7: 49]. Газета яңа мәгыйшәтнең контурларын билгеләргә, шуңа ирешү юлындагы каршылыкларны барларга, татар мәгарифенең кыйбласын ачыкларга алына.

Чыннан да, басма тематик яктан бик бай булып чыга. Монда белем-мәгърифәт, әдәбият-мәдәният, татар теле, театр, музыка мәсьәләләре дә, илдәге һәм дөньядагы сәяси-иҗтимагый вазгыять тә, хатын-кыз проблемасы да, дин, тарих, фәлсәфә дә игътибар үзәгенә куела. Ф. Әмирханның күпсанлы язмалары арасында берничә төп тема аерылып чыга.

Беренчесе – басманың төп максатына тәңгәл килгән ***гыйлем-мәгърифәттә алгарыш*** мәсьәләсе. Ул төрле яклап, төрле ракурсларда күзәтелә башлый. Икенче санга баш мәкалә итеп язылган «Казан, 10 октябрь» шәкертләр хәрәкәтенең асылын һәм әһәмиятен билгеләүгә багышлана. Үзе дә яңарак кына шул хәрәкәттә кайнаган Фатих сүзне 5–6 ел дәвам иткән әлеге хәрәкәтнең алты нәтиҗәсен күрсәтүдән башлый: 1) шәкертләрдә мәгълүматка ихтыяҗ тәрбияләү; 2) аларда мөгаллим булу куәсен көчәйтү; 3) русча белә торган шәкертләрнең нык артуы; 4) белемсез мөдәррисләрнең укытуны ташларга мәҗбүр булуы; 5) яңа ачыла торган уку йортларының яңа программаларга йөз тотуы; 6) халыкның мәдрәсәләрдә белем һәм тәрбия бирүне күзәтү-контрольдә тота башлавы.

Бу нәтиҗәләрне мөһим дип санавы белән бергә, Ф. Әмирхан, бер яктан, татар җәмгыятендә барган бу хәрәкәтнең Европадагы үзгәрешләргә тәңгәл булуын әйтеп хуплый, бер үк вакытта, Кавказ мөселманнарындагы тискәре тәҗрибәне телгә алып, татар җәмәгатьчелеген, яңа мәдрәсәләр ачу белән бергә, иске мәдрәсәләрдәге укыту тәртибен үзгәртүдә активлашырга чакыра.

Шул ук санга әдипнең «Гыйлемгә һәвәсне ничек арттырырга?» мәкаләсе кертелгән. Ф. Әмирхан Мәскәү һәм Петербург университетларында укыткан профессор И.Х. Озеровның соңгы ике елдагы сәяси вакыйгаларга анализ биргән хезмәтендәге Россия яшьләре гыйлемгә һәвәсләнде дигән фикерне, рус мәгариф системасын Германиянеке белән чагыштырып тәнкыйтьләвен сөйли. Күрәсең, язма шушы караш белән укучыны таныштыру максатын куя да. Автор ирониясенең «“профессорлар”ымызның <...> шәкертләрдә тәнкыйть куәләрен арттырырга тырышуның ярамаганлыгын» [7: 59] исбатлауларына юнәлтелгән булуы Ф. Әмирханның, Озеров кебек үк, шәкертләрдә үзфикерлелелек, тәнкыйди караш, заманча аң үстерүне яклавын дәлилләп килә.

«Казан, 17 октябрь» баш мәкаләсе татар мәгарифендәге шулай ук бик тә актуаль булган мәсьәләне күтәрә: югары белем бирә торган (галия баскычы) 10 мәдрәсә булып та, бары тик алты башлангыч

(ибтидаи) мәктәп эшләүгә укучының игътибарын юнәлтә. Европа мәгарифенә күз төшереп, ул 10 югары мәктәпне эшләтер өчен 200 башлангыч мәктәп кирәклекне искәртә. Ф. Әмирханга хас нечкә ирония белән: «Без алай башка кавемгә охшарга яратмыймыз», – ди дә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылгач, җәмгыятьтә урта (рөшдия, игъдадия) мәктәпләрнең кирәге калмады дигән караш урнашуны тәнкыйтьли. Шулай автор дөрестән дә тиз арада төзәтү таләп ителгән проблемага күз сала. «Әгәр Казан татарларының ун хәзерге кеби дарелфөнүннәре урынына ике-өч мөкәммәл рөшдия (*урта баскыч мәктәпләре*) вә бер мөкәммәл игъдадияләре (*башлангыч мәктәпләре*) булса, никадәр бәхетле булырлар иде. Әгәр ун дарелфөнүннәремезне тәрбия кыла торган акчаларымыз шул ике-өч рөшдия һәм бер игъдадиягә сарыф кылынса, никадәр урынлы сарыф кылынган һәм хуҗаларын бәхетле ясаган булырлар иде. Әгәр шул ун дарелфөнүннән ел саен җитешә торган илле-алтмыш надан имам-хатыйп, мөдәррисләр урынына рөшдия вә игъдадияләремездән зыялы унбиш-егерме генә кеше җитешә барса да, истикъбалемез (*киләчәгебез*) якты булыр иде» [7: 65–66]. Бер ел да узмас – без әдипнең бу хыялы тормышка ашканны аның үз язмаларында күрербез.

«Казан, 25 октябрь» баш мәкаләсе (Ф. Әмирхан томлыкларына беренче тапкыр кертелә) алдагы баш мәкаләнең дәвамы кебек тоела, ул мөгаллимнәр әзерләү мәсьәләсенә кагыла. Мөгаллимнәр җитешмәгәнгә – татар мәктәпләре ачылмый, мөгаллимнәр җитешмәгәнгә – укыту сыйфаты түбән, диюче Ф. Әмирхан бу юнәлештәге адымнарның каршылыкка очравын билгели: җәй көне бер сыйныфлык булып оешкан мөгаллимнәр әзерләү курсларын шикаять язып яптыруларын сөйли. Халыкка мөрәҗәгать итеп, тиз арада Казанда бер укытучылар әзерләүче уку йорты ачарга өнди, язмасын: «Татар милләте үзенең мәгариф эшен үзе илтә алудан гаҗизлек күрсәтерлек бер гайрәтсез милләт түгел!» дигән ышаныч белән тәмамлый. Бу өндәмә Ф. Әмирхан публицистикасында озак еллар кабатланып барачак әле.

«Казан, 5 ноябрь» баш мәкаләсе (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) 1906 елның 31 мартында Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан каралган Россиянең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш өлешләрендә яшәүче башка милләт кешеләре өчен башлангыч училищелар турында закон проектын кабат тикшерү өчен комиссия эшчәнлеге хакында бара. Әмирхан бу комиссия эшенә Ибраһим Акчурин, Гайсә Еникиев, Ризаэддин Фәхреддин, адвокат Бат кебек кешеләрнең катнашуы матур бер нәтиҗәгә китерүне – татарлар өчен яңа кагыйдәләр тәкъдим ителеп, татар мәктәпләрен Диния нәзарәте карамагына бирдерү мәсьәләсе көн тәртибенә куелуны зур канәгатьлек белән сөйләп уза.

«Казан, 12 ноябрь» баш мәкаләсе (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) дөнья үзгәрешенә бәйле мәдрәсәләрдә фәннәр укытуга ихтыяҗга тукталса, шулай ук беренче тапкыр кабат басыла торган «Казан, 19 ноябрь»дә Россиядә югары уку йортларына керергә

теләүчеләр башка милләт вәкилләренең күплегенә кагылышлы күзәтү ясалып, татарларда моның пассив булуы искәртелә. Әмирхан бу хәлнең сәбәпләре дип уку программаларының заман таләпләренә җавап бирмәвен, уку йортларының искелек учагы булып калуын саный. «Казан, 26 ноябрь» Әмирхан өчен яңа темага – кыз балаларны укыту һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган. Хисси-эмоциональ язылган бу мәкалә татар матбугатында шушы мәсьәләнең гаять активлашуына китергән сәбәпләрнең берсенә әйләнә. Бигрәк тә 1912 елдан соң хатын-кыз мәгарифе татар матбугатындагы иң актив темалардан булып китә.

«Казан, 3 декабрь» язмасы (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) кабат мәктәпләр мәсьәләсенә әйләнеп кайта. Полякларның, махсус фонд оештырып, күпсанлы башлангыч һәм урта мәктәпләр ачуын мисалга китереп, автор татарларның мәгарифне түгел, кием һәм чәч йөртүне миллилек нигезе дип карауларын тәнкыйтьли. «Болар бик күптән, бик яхшы итеп кием вә сач белән миллият сакланмый, бәлки аның мәдәнияте вә мәгарифе белән саклана икәнчелеген белгәннәр вә үзләренең мәгарифләре аркасында миллиятләрен җуялтмый киләдерләр», – ди ул. Мәсьәләне хәл итү өчен, автор зәкят акчасын мәктәпләр ачуга тотарга чакыра. Чыгымнарны санап, ул моның китерәчәк уңай нәтиҗәләрен дә барлый.

Томлыкларга беренче тапкыр кертелгән өч мәкалә көн кадагына суккан күренешләргә кагылалар. «Казан, 10 декабрь» Казан муллаларының, җыелып, казыйлыкка вәкилләр сайлавын хәбәр итә һәм автор: «Татар милләте үзенә файдалы булачак кешеләрне яхшы таный башлаган, үзенең идарәи руханиясе әгъзаларыны вә мөфтине сайлап куяр дәрәҗәдә үскән икән», – дип шатлана. «Казан, 17 декабрь» исә татар халкының 5 мохтаҗлыгын билгеләүдән бшлана: гыйлемгә, хөрриятkә, байлыкка, иркенлеккә, рухи байлыкларга (әдәбият, сәнгатькә) ихтыяҗ турында әйтеп, Ф. Әмирхан аеруча икесен – гыйлемне һәм байлыкны – милләткә хезмәт иттерүнең хәзерге көн татар җәмгыяте өчен аерата мөһимлеген сөйли. «Казан, 24 декабрь» Уфада, Казанда башланган мәктәп-мәдрәсәләрне баскычлап үзгәртү вазгыятенә тәнкыйть күзлегеннән карап язылган.

1908 елда дөнья күргән баш мәкаләләрдә дә гамьле сөйләшүләр дәвам итә. Шулай ук томлыкларга беренче тапкыр кертелгән мәкаләләр Әмирханның үткен күзе күп проблемаларны ачып салганлыкка дәлил була ала. «Казан, 1 гыйнвар» язмасы – татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку вакытының тәртипкә салынмавы турында. Ф. Әмирхан рус һәм татар уку йортларындагы дәресләр санын чагыштыра: кышкы каникулга кадәр рус шәкертләре – 400 сәгать, аннары 500 дәрес укыячаклар, татар шәкертләре – 60 сәгать дәрестә булып, ел дәвамында күп дигәндә 150 дәрес тыңлаячаклар, дип, бу исрафның гыйлем сыйфатына сугуына сызлана. «8 гыйнвар» мәкаләсе татар тормышындагы күңелсез яклар: эшләп тә ач-ялангач яшәү, наданлык, хатын-кызларның изелүе, яшьләр өчен тормышның тарлыгы турында

сөйли. Боларны милләтнең авыруы дип атап, автор аңа дәваны гыйлемнән табу мөмкинлеген искәртә, моның өчен «татар милләтенең дә иң зур кайгырткан нәрсәсе мәгариф вә мәдрәсәләр мәсьәләсе булырга тиеш», – дип белдерә. «Казан, 14 гыйнвар» III Дәүләт думасы депутаты Гайсә Еникиевның татар мәктәпләре һәм аларны ничек үзгәртү хакында мәгълүмат сорап җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итүенә нисбәтле языла. Ф. Әмирхан, бер төркем зыялылар исеменнән, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе 1907 елда Түбән Новгород шәһәрендә үткәргән съездда әзерләнгән карарларның иң мөһим бишесен искә төшерә һәм эшне шуларны тормышка ашырудан башларга кирәклекне искәртә. Бу карарлар мәдрәсәләрне Диния нәзарәте карамагына тапшыруны; башлангыч белемне туган телдә алуның мәҗбүрилеген; татар шәһәрләрендә һөнәр һәм сәнгать мәктәпләренең татар телендә эшләвен; һәр җирдә татар телендә мәктәпләр ачарга рөхсәт ителеп, аларны хокукый яклау; мәктәп эшләрендә ирек бирү кебек пунктларны үз эченә ала.

«Казан, 21 гыйнвар» баш мәкаләсе, узган елга нәтиҗә ясап, яңа елга гамьле максатлар билгеләү кебек язылган. Ф. Әмирхан, сүздән эшкә күчәргә вакыт җиткәнлекне әйтеп: «Безнең яңа елда яңа лозунгымыз: “Никадәр вак булса да – эш; сүз белән генә ерак китеп булмый икән” булырга тиештер» [7: 88], дип ассызыклый. Әмма тормыш үзгәрешләр алып килә: әдипнең «Казан, 2 февраль» язмасы «Реакция башланды!» [7: 90] дип ачыла. Әмирхан моның ысулы җәдид мәктәпләренә һөҗүмнәрдә, әдәбият кичәләре уздыруга каршы комиссияләр оештыруда, мәгарифне үзгәртүгә каршылыкта, халыкның кабат йокыга талырга теләвендә аеруча көчле чагылуын күрсәтә. Әмма ул үзе – оптимист, аның кысуларга каршы җавабы да әзер: ирония белән әйткән, татар кичәләре һәм мәктәпләре ябылса – татарлар үзләренә кирәк гыйлем һәм мәгарифне рус театрларында һәм кичәләрендә, рус гимназияләрендә табачак, дигән сүзләре татар дөньясының үзгәргәнлегенә, кабат искелек заманнарына әйләнеп кайтмаячагына ышаныч булып яңгырый.

«Казан, 9 февраль» баш мәкаләсе кабат 14 гыйнварда күтәрелгән мәсьәләгә әйләнеп кайтып, татар мәктәбен үзгәртеп кору планнарының аерым моментларын шәрехләп уза. «Казан, 16 февраль»дә исә рус телендә белем алган яшьләрнең татарча белүен таләп итү, татарлар укый торган рус мәктәпләрендә татар мөгаллиме булдыру кирәклек күтәрелә. «Казан, 23 февраль» реакциянең мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсенә тискәре йогынты ясавына игътибар итсә, «Казан, 2 март» Дәүләт думасында мәгариф эшләренә карашлар төрлелеген анализлап үтә. «Казан, 9 март» исә кабат татарлар өчен гимназияләр, мәктәпләр ачу ихтыяҗын көн тәртибенә куя. «Казан, 17 март» (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) мәктәп-мәдрәсәләрдә сыйныфтан сыйныфка күчү имтиханнары кертү тирәсендә бара.

Көчле яңгырашлы «Мәктәпләрдә хөррият рухы» язмасы шулай ук баш мәкалә булып басыла (1908 ел, 3 һәм 11 апрель). Фран-

цуз һәм инглиз мәгариф системаларын чагыштырып, Ф. Әмирхан беренчесенең – буйсындыруга, икенчесенең ирекқә корылган булуын белдерә. Татар мәгариф системасының киләчәген хөррият рухы тәрбияләүдә күрергә тели. Бу мәкаләдә әйтелгән фикерләр Г. Тукайның «Хиссияте миллия» (1906) язмасына аваздаш, алар күпкә соңрак, 1914 елда, Г. Ибраһимовның «Тәрбиядә хөррият вә шәхсият нигезләре» язмасында да күтәреләчәк әле.

«Мәдрәсәләрне берләштерү» (1907 ел, 19 апрель) күләмле мәкаләсе Казанда 12 югары мәдрәсә, 12 игъдадия, 12 рөшдия, 13 башлангыч мәктәп барлыкны әйтеп башлана. Бу саннар бер ел элек Ф. Әмирхан «Казан, 17 октябрь» мәкаләсендә күтәргән проблеманың – урта баскычларда мәктәп булмауның – хәл ителүенә, ягъни газетада әйтелгәннәрнең җәмәгатьчелек тарафыннан тормышка ашырылуына мисал булып тора. Бу материалдагы төп мәсьәлә – Казан шәкертләренең мәдрәсәләрне берләштерү идеясе белән мөрәҗәгате. Ф. Әмирхан моны хуплый һәм белем сыйфатын күтәрү җәһәтеннән дә, икътисади яктан да кирәклеген аңлата. Бу сөйләшү «Зурлар белән мәдрәсәләр берләштерү хакында мөзакәрә»дә (1908 ел, 19 һәм 27 апрель), «Мәдрәсәләр[не] берләштерү (Без 27 номер...)» (1908 ел, 27 апрель; томнарга беренче тапкыр кертелә), «Мәдрәсәләр[не] берләштерү (28 номердагы мәкаләгә гыйлавә)» (1908 ел, 4 май; томнарга беренче тапкыр кертелә) кебек язмаларда дәвам итә, аларда Ф. Әмирхан Казандагы аерым мәдрәсәләрнең киләчәгенә караган планнары белән уртаклаша, әйтерсең, шушы берләштерүнең стратегиясен, план-проспектын төзеп күрсәтә. «Казан, 26 май» баш мәкаләсендә (1908 ел, 27 май, томнарга беренче тапкыр кертелә) Казан татар укытучылар мәктәбенең (КТУШ) программасы белән кыскача гына таныштырып, шуның үрнәгендә укытучылар әзерләүче уку йорты ачарга чакырып, Ф. Әмирхан «Кырык мең мөселманы, әллә никадәр байлары булган Казан бер дарелмөгаллимин вөҗүдкә китерүдән дә гаҗиз калыр микәнни?» дигән сорау куя. Бу язмаларда әдипнең татар мәктәп-мәдрәсәләренең программаларын да, алардагы укыту тәртибен дә эчтән, яхшы белүе, андагы мөгаллимнәр, аларның гыйлем дәрәҗәсе, уку йортындагы мохит, фәннәрнең ничек укытылуыннан хәбәрдарлыгы күренеп тора.

Томлыкларга беренче тапкыр кертелгән баш мәкаләләрдән «Казан, 24 июнь. Хөкүмәт урта мәктәпләрендә искелек» хөкүмәтнең мәгарифкә мөнәсәбәте мәсьәләсенә кагыла. «Казан, 2 июль» һәм рус яшьләренең, һәм татарларның ватаннан читтә гыйлем эзләүләрен үзәккә ала. «Казан, 12 июль» исә татар фикер ияләрендә мәгариф реформасы хакында татарның күренекле эшлеклеләрендә фикер төрлелегенә сызланып язылган. Автор: «Без – татарлар, милли мәктәпләр вөҗүдкә китерер өчен, башлап, рус мәктәпләрендә тәхсилгә җабырылырга мәҗбүрмез», – дип, татар мәгарифен шушы үрнәктә үстерүдән башка юл булмауны дәлилли.

Газета чыга башлаганга ун ай тулуга нисбәтле Ф. Әмирхан баш мәкалә итеп «”Әлислах”тан ни көтәргә ярый?»ны (1908 ел, 20 июль;

томлыкларга беренче тапкыр кертелә) яза. Басманың төп кыйбласын тагын бер кат билгеләп, «фәкать халыкка бездә мәктәп-мәдрәсәләр юклыгын аңлатырга тырышамыз», ди дә, болай шәрехләп бирә: «Мәктәп-мәдрәсәләремезнең эчен-тышын ачык иттереп күрсәтәбез. Халыкның хәзер мәктәбе ибтидаиларны (*башлангыч мәктәпләрне*) гына бертөрле тәрбияләргә вә, иң чиге дә, рөшдиләр (*урта баскыч*), яхуд городскойлар образованиесе бирерлек мәктәпләр генә ачарга кулыннан килүен уйлаганга, мөгаллимнәр җитештерер өчен дарел-мөгаллиминнәр ачарга вә рөшдиләргә дәрес китаплары хәзерләргә иҗтиһад итүне вә шуннан артыкка куәтемез җитмәүне ачык иттереп әйтәбез. Менә “Әлислах”тан нәрсә көтәргә ярый». 3 ай узуга, «Казан, 13 октябрь» язмасында әдип тагын бер кат газетаның мәсләге мәсьәләсенә әйләнеп кайта.

Шулай ук томлыкларга беренче тапкыр кертелгән чираттагы баш мәкаләләр сәяси мәйданга кереп китә. «Ике катлы реакция» (1908 ел, 27 июль) илдә башланган реакциянең мәгариф эшләренә тискәре тәэсире турында сөйләсә, «Казан, 14 август» (1908 ел, 14 август) Госманлы дәүләтендә иректе фикернең җиңүенә шатланып язылган. «Казан, август 21» (1908 ел, 21 август) мөфтинең мәгариф мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган съезд җыю теләге турындагы сүзләргә нисбәтләнә. Бу хәбәрне хуплап каршылаган автор җыенның «руханилар съезды түгел, бәлки татар зыялылары съезды булырга» тиешлеген, әйтеп, фикердәшләрен бу эштә катнашырга чакыра. «Казан, 31 август» шулай ук уку-укыту мәсьәләсенә көтелмәгән яссылыкта якын килеп язылган. Ф. Әмирхан биредә татар мәдрәсәләрен диниятне һәм миллиятне көчләп тагуда гаепли, моны тәрбия чаралары белән алып барырга чакыра.

Ф. Әмирхан башка матбугат органнарында мәгариф мәсьәләсенә караган мәкаләләргә дә мөнәсәбәт белдереп бара. Әйтик, «Казан, сентябрь 15» (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) – шундыйлардан.

Әдәбиятны үстерүне халык аңы-фикере белән турыдан-туры бәйләп карый торган Ф. Әмирхан («Казан, 30 сентябрь. Мәктәпләремездә әдәбият дәресләре»): «Вакыт түгелме мәдрәсәләребездә татар әдәбияты дәресләре башларга?» дигән чакыру белән чыга [8: 77]. Аныңча, укучыларга әдәбият дәресләре бирү – татар әдәбиятын-мәдәниятен камилләштерүнең туры юлы. Балалар һәм яшүсмерләрне тәрбияләү генә түгел, әдип фикеренчә, милли үзаңны булдыру һәм ныгыту да сүз сәнгатенә йөкләнә: «Әдәбият – дөньяга карашны киңәйтүдә вә теләгән фикерне аңларлык кешеләргә чәчүдә иң куәтле корал» [8: 78], – дип яза ул.

«Казан, 25 октябрь» язмасы (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) «Хөсәения»дән 33 шәкертнең «Иж-Буби» мәдрәсәсенә китүе уңаеннан язылган. Ф. Әмирхан әлеге күренешнең мәдрәсәләрне яңарту мөһимлеген, яшь мөгаллимнәргә юл бирү кирәклеген күрсәтүче дәлил булуын да, шәкертләрнең гыйлем алу мәсьәләсенә аңлы төстә якын килүләре күрсәткече икәнен дә билгели.

«Казан, 2 ноябрь» мәкаләсендә автор: «Казан яшьләре быел чынлап уку һәвәсенә төшеп, чынлап гомерләренең һәр дәкыйкаларын тәкъдир итә башладылар», дип шатлана. «Казан, 1 ноябрь»дә яшьләрне матди яктан кайгырту өчен бер союз төзү тәкъдиме белән чыга.

Ф. Әмирхан томнарына беренче тапкыр кертелгән 1909 елгы баш мәкаләләр, нигездә, сәяси яссылыкта язылганнар. «Казан, 7 гыйнвар»да, узган елга йомгак ясап, автор Госманлы дәүләте конституцияле булып яшәүне зур казаныш буларак телгә ала, татар дөньясында артык күзгә ташланырлык алгарыш булмауны билгели. «Казан, 15 гыйнвар» мәкаләсе халыкара теманы дәвам итә. Автор конституцияле Госманлы дәүләтенең монархиядән өстенлекле сыйфатларын берәм-берәм санап бара. Бигрәк тә Ф. Әмирханны Госманлы дәүләтенең халыкның үзаңын һәм мәдәниятен «мәгърифәт белән саклау юлына» керүе рухландыра. «Казан, 15 февраль. Азеф вакыйгасы һәм Лопухинны хибес» – провокаторлыкта гаепләнгән Евно Фишелевич Азеф вакыйгасын бәян итә. «Казан, 10 февраль» тагын бер кат Госманлы дәүләтендәге вазгыятькә күз ташлый. «Казан, 26 февраль» исә татар матбугат органнарының актуаль мәсьәләләргә кагылмый узуын тәнкыйтьли. «Казан, 9 март», шушы сөйләшүне дәвам итеп, газеталарның халыкара сәясәт белән мавыгуына игътибар бирә. «Казан, 21 апрель», «Казан, 30 апрель», «Казан, 21 июль» кабат Госманлы дәүләтендәге хәлләрне күзәтүгә багышлана.

Бу юнәлештә Ф. Әмирханның каләме сәясиләшә бару күзгә ташлана. Бәлки, үзенең полиция күзәтүе астына эләгү, газетаның ябылу сәбәпләренең берсе дә шул булгандыр.

Гомумән алганда, «“Әлислах” үз алдына татар мәктәп-мәдрәсәләрен нигезеннән үзгәртеп, Европа һәм алдынгы рус уку йортлары дәрәҗәсенә күтәрү, аларда дөньяви фәннәр, туган тел, әдәбият укыту, динчеләр кулыннан аерып, үзидарә урнаштыру, яхшы кадрлар белән тәэмин итү һ. б. шундыйларны максат итеп куя. Ләкин газетадагы мәкаләләрнең эчтәлеге моның белән генә чикләнми, чынлыкта ул күпкырлы. “Әлислах” киң планда алдынгы рус, Европа мәгариф системасын, мәдәниятен, әдәбиятын пропагандалый, хатын-кыз азатлыгы һәм мәгарифе өчен көрәшә. Кара реакция котырынган еллар булуга карамастан, ачыктан-ачык искелек, тар милләтчелек кебек тискәре күренешләргә каршы көрәш мәйданына әверелә» [1: 4]. Бу юнәлештә газетаны Ф. Әмирхан әйдәп бара, үзенең киң карашы белән яңа бурычлар куеп тора, аларны хәл итәргә өнди.

Икенче юнәлеш – ***сәясәт***, ул да газетаның иң беренче санынан, Ф. Әмирханның сәяси мәсләкле, III Думага вәкилләр сайлау белән бәйле «Думалар» (1907 ел, 3 октябрь) мәкаләсеннән үк башлана. Балалар журналындагы алдагы Дума белән бәйле язмадан аермалы буларак, мәкалә сәясәттән хәбәрдар кешеләргә адресланган. Ул Россиядәге сайлаучылар партияләренә һәм аларның мәсләкләренә анализ ясый. Сайлау законнарына кертелгән 3 июнь үзгәрешләрен, ягъни югары сыйныфлардан күбрәк вәкилләр сайлау хокукы бирүне,

Ф. Әмирхан хөкүмәтнең вак халыкларның (инородецларның) хокукларын кисүе дип гаепли. Әмма шушы вазгыятькә карамастан, язма сайлауларда активлык күрсәтергә чакырып тәмамлана.

Шушы законга тагын да төгәлрәк анализ биргән «3 июнь кануны вә партияләр» (1907 ел, 10 һәм 17 октябрь) татар укучысын илдәге вазгыятькә мөһим тәэсир ясаган 3 июнь канунының беренче нәтиҗәләре белән таныштыра. Аерым алганда, Ф. Әмирхан бу канунның кадетларны куәтләнергә мәҗбүр итүен, аларның октябристлар белән берләшү мөмкинлеген, эсерлар һәм социал-демократлар партияләренең генә үз мәсләгенә – халыкка сүз ишеттерүне алга алуына – тугрылыгын телгә ала. Шунысы кызык: Ф. Әмирхан бу язмасында социал-демократлардан большевиклар һәм меньшевиклар канатларының позициясе, асылда, бер-берсеннән аерылмауга игътибар итә һәм барлык партияләрне көчсезләндергән 3 июнь канунының боларга тәэсир ясамавын искәртә. Авторны, бигрәк тә, Бөтенроссия мөселманнарының «Иттифак әл-мөслимин» партиясендәге хәл борчуга сала, автор партиянең таркаулыгы нәрсәгә китерәсен алдан күрә. Мондый күзәтүләр Ф. Әмирханның бик көчле аналитик-сәясәтче, хәтта борынлап кына килә торган күренешләрнең киләчәген алдан күргән шәхес булуын тагын бер кат дәлилли.

Алга таба да Ф. Әмирхан Дәүләт думасы эшчәнлеген аңлаткан язмалар белән чыгыш ясавын дәвам итә. Алар халыкка аңлаешлы һәм сәяси төпле булулары белән аерылып торалар: «3 нче Дума» (1907 ел, 25 октябрь), «Дума ачылды» (1907 ел, 5 ноябрь), «Думада центр» (1907 ел, 12 ноябрь), «Дума» (1907 ел, 3 декабрь) һ. б. Аларда хакимияттәге вазгыять, һәр үзгәреш оператив рәвештә күзәтеп барыла, әйтик, «Сәясәт галәмендә» (1907 ел, 17 декабрь, томлыкларга беренче тапкыр кертелә) язмасында дәүләт бюджеты турында сүз алып барыла. «Беренче Дума әгъзаларына хөкем» (1907 ел, 24 декабрь, беренче тапкыр кабат басыла) парламент депутатларының хөкемгә тартылу вакыйгасын аңлата. «Тәгълим мәҗбүри, хөкүмәт һәм Дума» (1908 ел, 25 март) мәкаләсе (томлыкларга беренче тапкыр кертелә) Думада мәҗбүри белем бирү системасы кертү мәсьәләсе тикшерелүгә бәйләнә. Баш мәкалә итеп әзерләнгән «Казан, 17 июнь» Думада мәгариф хакындагы вазгыятькә багышлана (томлыкларга беренче тапкыр кертелә). «Дума сәламәт вакытта Толстой режимына кайту юк!» (1908 елгы 21 август) язмасы Россиядә югары уку йортлары өчен яңа устав эшләнгәнне хәбәр итә һәм «хәзердә сайланып куела торган ректор, декан һәм секретарь моннан соң тәгъйин белән (*өстән билгеләп)* куелачаклар. Дарелфөнүн эчендәге таләбә җыеннары (*шәкертләр җыелышлары)* бөтенләй бетереләчәк. Хәзердә шәкертләргә күп уңгайлык бирә торган предметный система урынына курсовой система кертелү ихтималы да тотыла икән» [7: 132] дип, боларның югары уку йортларының мөстәкыйльлеген бетерәчәк гамәлләр булуын искәртә.

Бу урында Ф. Әмирханның вакытлы матбугат чараларында эшләве аны әдип итеп формалаштыра дип күрсәткән Ф.Г. Галимуллинның

бер фикерен кабатлап узу урынлы булыр: «Ул илдәге, татар җәмгыятендәге хәл-әхвәлләрне игътибар белән күзәтеп бара, аларга карата үткен һәм йөгерек каләме белән шәхси мөнәсәбәтен белдерүне заман тарафыннан үзенә йөкләтелгән бурыч дип саный. Ул елларда еш сайланган думаларның сәяси составын һәм шуннан килеп чыга торган язмышын билгеләүче язмалар дисеңме; мәдрәсәләрдә укытуның торышы, аларның җанлы тормыштан артта калулары, моның бер сәбәбе буларак, татар әдәбиятының укытылмавына борчылып язган аналитик мәкаләләреме; татарның алга китешенә комачау итүчеләрне ачып салган “Газеталар галәмендә” дигән күзәтүеме – болар һәммәсе аның журналистика жанрларын, аларның табигатен яхшы аңлап, кыю эш итүен күрсәтә» [3: 7].

Өченче юнәлеш – ***татар тормышындагы кимчелекле якларны барлау,*** алардан көлү. Ф. Әмирханның 1907 елгы 3 октябрь санында басылган «Мөтәгассыйб Казан татарларына ачык хат» дигән кискен сатирик мәкаләсе – шундыйлардан. Хат формасында, Печән базарының иске карашлы фанатикларына риторик эндәшеп, автор тормышны ике чиккә аера: татар дөньясының тулысы белән наданлык, караңгылык диңгезендә чайкалуы – һәм берничә еллар элек аның бер өлеше өчен «ул мөхтәрәм вакытлар» үтеп, «эзләп тә табылмаслык җиргә» китүе: «Хәзер без үземезне һәм сезне бик яхшы таныдык, белдек» [7: 52]. Ф. Әмирхан иске карашлы татарларның көнитешен, эш-гамәлләрен күзәтеп, аларны милләткә, халыкка каршы кылынган дошманлык дип атый. Ул: «Дин вә миллият! Шушы кадәр гали нәрсәләргә сез нинди ифтиралар кыласыз (*ялалар ягасыз*)» дип ачына һәм шушы ике сүз астында фанатиклар башкара торган килешсез эшләрне күзәтеп уза. «Миллияткә килсәк, сезнең ул хактагы эшлеклелегеңез дә бик кайгылы вә егларлык бер халәттә: милләтне инкыйраздан *(югалудан)* котылдыра торган ялгыз бер чара – тәрәккый вә зыялануга сез бөтен куәтеңез белән каршы торасыз. Милләтнең рухы булган әдәбиятына сез тумышыннан бирле дошман булып килеп, хәзергә кадәр хәлсез вә эшлексез кулларыңыз белән аны буарга тырышасыз. Милли театр, милли музыка, милли әдәби әшгарь (*шигырьләр*)... – боларның һәммәсен сез, табигать хилафына уларак, тудырмаска вә, туса да, яшәтмәскә тырышасыз. Кыска гына әйткәндә, сезнең динеңез – диянәтсезлектән, миллиятеңез – милләтне һәлакәт чокырына алып барудан гыйбарәттер» [7: 54].

«Казанның “педагоглары”» (1907 елгы 10 октябрь) исемле мәкаләсе, укыту-тәрбия мәсьәләләре турында сөйләшүне дәвам итеп, Казан татарларының бу эшләргә бернинди мөнәсәбәте булмаган кешеләрне Петербургка мәгариф эшләре тикшерелә торган махсус киңәшмәгә җибәрүеннән көлеп язылган. Бераздан «Зур “педагоглар” зур эш эшләп кайттылар» (1907 елгы 5 ноябрь) исеме астында бу көлке хәлнең нәтиҗәсе дә укучыга җиткерелә.

«Әлислах»ның Гает бәйрәменә багышланган 1908 елгы 1 гыйнвар санында басылган «Бәйрәм вә бәйрәм!» мәкаләсендә Ф. Әмирхан

татарларда дини һәм милли бәйрәмнәрнең күңелсез, кызыксыз узуына ачына, рус бәйрәмнәренең мәдәни рухын үрнәк итеп куя. Бу караш әдипнең хикәяләрендә тагын да образлырак төстә тасвирлана. «Гәзитәләр галәменнән» исеме белән даими күренеп килгән бер төркем язмалар матбугат мәйданындагы хәлләрне, тартышларны бәяләп бара.

Бу җәһәттән, Ф. Әмирханның ярым публицистик, ярым әдәби әсәр итеп язылган «Авырулар галәмендә» (1908 ел, 20, 27 июль һәм 14 август) тексты аерым бер урын тота. Беренче карашка, ул дәва эзләп килүчеләр турында булып тоела, әмма гомумән тормыш-яшәешкә, дөньядагы хәл-әхвәлгә метафора кебегрәк язылган һәм символлар (җил, тау, кояш, креслода утыручы кыз, музыка аһәңе) теле белән җәмгыятьтәге хаос, тигезсезлек, кайгы-моң, гаделсезлек турында сөйли. Хикәяләүнең Иранга, Госманлы дәүләтенә, Македониягә күчеп, андагы хокуксызлыкка кагылуы «авырулар галәме»нә бөтен җир шарын, яшәешне сыйдыра. Аннан татар җәмгыятенә, Казаннан килгән хатларга тукталып, татар дөньясын чолгап алган пессимизмны, өметсезлекне билгеләсә дә, Ф. Әмирхан болай ди: «Ләкин мин иптәшемнең бу пессимизмыны мөшарәкәт итмим (*уртаклашмыйм*). Бу халәтләрнең безнең башта вакытлы гына икәнчелегенә ышанам. Дөнья, мәгыйшәт безне эшкә тотынырга үзеннән-үзе мәҗбүр итәр дип уйлыйм» [7: 131–132]. Автор язмасын якты киләчәккә ышаныч сүзләре белән төгәлли: «И таң, ат инде тиз генә! Мин сине көтәм һәм тиздән булуыңа ышанам!» [7: 132].

Дүртенче юнәлеш – ***татар дөньясындагы яңа, матур башлангычлар*** турында сөйләү. Монда яңа китаплар бастырылу да, кичәләр һәм спектакльләр оештырылу да, эсперанто телен үстерү мәсьәләләре дә күздән кичерелә. «Әдип бу публицистик әсәрләрендә татар яшьләре күңелендә “әдәбият”, “театр”, “музыка вә хәяте гомумия хасиятләренең” җирләшәчәгенә ышана һәм татар халкында “әхлакы хәсәнә тәгаммем” итә башлавына чын күңелдән сөенә» [2: 275].

Беренче язма бишенче санда, «Әдәбият кичәсе» исеме белән басылып килгән бер бәйләм мәкаләләр Казанда оештырылган әлеге кичәләрне барлык детальләрендә: кемнәр чыгыш ясауны, бу чыгышларның сыйфатын, нинди фикерләр яңгыратылуны, татар тормышындагы яңа күренешләрне... – барысын да тасвирлап бара. 1908 елдан башлап шулай ук җентекләп татар театрындагы премьераларга күзәтүләр ясый («Егерме бишендә татарча театр уены», 1908, 4 май; «Татарча спектакльләр», 1908, 24 ноябрь; «Татарча спектакль», 1909, 17 март һ. б.), аның рецензияләрендә генә түгел, теләсә нинди мәдәни вакыйга-күренешләрне тәкъдим итүе вакытында уңай һәм тискәре яклары әйтелмичә калмый. Әйтик, «Гаспринский юбилее» (1908 ел, 25 март; томлыкларга беренче тапкыр кертелә) «Тәрҗеман» газетасының 25 еллыгы уңае белән язылган, әдип зур канәгатьлек хисе белән басманың әһәмиятен билгели һәм Исмәгыйль Гаспралы карашларын анализлап уза. Әмма Әмирханның үткен күзе монда да тәнкыйтьләр-

лек урын таба: бераз соңрак басылып чыккан «У-у... шатлык, никадәр юбилей ясыйсымыз бар әле!» (1908 ел, 3 июнь) дигән язмада ул татар дөньясының юбилейлар уздыру белән артык мавыгуыннан көлә, мөһим вакыйгаларны гына зурлау кирәклеген, югыйсә, бәйрәмнәр белән вакыт уздырып, кирәкле эшләрнең читтә торып калу ихтималын сөйли.

Дүртенче юнәлештә әдип эшчәнлеген гомумиләштереп бәяләп, Р.К. Ганиева болай ди: «Аның күпчелек әдәби-тәнкыйди мәкаләләре Г. Тукай (“Габдулла Тукаев шигырьләре”, 1907; “Габдулла Тукаев шигырьләре”, 1908; “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш”, 1908; “Азмы какканны вә сукканны...”, 1913; “Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим”, 1923) иҗатына багышланганнар. Гаяз Исхакый прозасы һәм драматургиясенең мәгънәви-әдәби үзенчәлекләре “Гаяз”, 1907; “Алдым-бирдем”, 1907; “Зиндан”, 1908; “Солдат”, 1908; “Мөгаллим”, 1914; “Зөләйха”, 1917; язмаларында тикшерелә. Аның шулай ук З. Һади, Ф. Кәрими, Я. Вәли, М. Гафури, С. Рәмиев, Г. Колахмәтов һ. б. иҗаты турындагы тәнкыйди мәкаләләре бар». Мондый нәтиҗә чыгарыла: «Фатих Әмирхан – XX йөз башы татар реалистик әдәбият белеме фәненә һәм әдәби тәнкыйтькә нигез салучыларның берсе» [4: 116].

Р. Мәрданов «Әлислах»ның һәр санында яңа дөнья күргән әсәрләргә рецензияләр басылуга игътибар итә: «Бу рубриканы, нигездә, Фатих Әмирхан алып бара» [1: 5]. Р. Әмирханов әдипнең, әдәби әсәрләргә генә түгел, бәлки дин гыйлеме, тарих, математика, тел гыйлеме, сәнгать, әхлак дәресләре һ. б. юнәлешле хезмәтләргә дә күзәтүләр башкаруын, тәрҗемәләрне һәрдаим бәяләп баруын тикшерә [2: 277].

Әдип әдәбият мәйданына чыккан китапларның берсен дә күз уңыннан төшермәскә тырыша, язмаларының зур күпчелеге заманча татар әдәбияты нинди булырга тиеш дигән сорау контекстында әзерләнгәннәр. Рецензияләрдә һәр әсәрне, хезмәтне хуплап, шатланып каршы алу белән бергә, һәм уңай, һәм кимчелекле яклары бик төгәл күрсәтеләләр. Әйтик, «Алдым-бирдем» рецензиясе Гаяз Исхакыйның әле генә табадан төшкән шул исемдәге пьесасына бәя бирә. Әсәрдәге типларның тормышчанлыгын мактаган Ф. Әмирхан җитди кимчелекләр буларак, мәхәббәткә аз урын бирелүне, Ибраһимның кызны чынлап та сөяме-юкмы икәнлеге ачыкланып бетмәүне, Исхакыйның «романтизмда саранлык» итүен күрсәтә. Гомумән алганда, яңа китапларга күзәтү ясаганда Ф. Әмирхан аларның татар укучысына нинди фикер җиткерүен, моның өчен кеше образларының – типларның – никадәр төгәл, тормышчан эшләнүен һәм тел-стиленең укучыга аңлаешлы, матур, нәфис булуын күз уңында тота.

Ф. Әмирханның әдәби тәнкыйтенә тәфсилле анализ ясаган Т. Гыйлаҗев аның эчтәлеген болай бәяли: «Ул исемнәре бүгенге көн укучыларына аз таныш булган Ярулла Вәли, Кәбир Бәкер, Галиәсгар Гафуров, Шакир Мостафа, Гомәр Терегулов кебек әдипләрнең

әсәрләренә бәя бирә. Мәгърифәтче язучылардан З. Бигиев, З. Ади, Ф. Кәрими, М. Гафуриның шушы рухтагы аерым әсәрләренә күзәтү ясый. XX гасыр башы классик әдипләре Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Камал, Г. Колахмәтовлар иҗаты әдәби тәнкыйтенең төп бәяләү объекты булып тора» [5: 113].

Ф. Әмирхан иң еш мөрәҗәгать иткән автор – якын дусты Тукайдыр, мөгаен. «Габдулла Тукаев шигырьләре. Шигырьләр көтебханәсеннән; 3 нче дәфтәр» җыентыгы басылып чыгу уңае белән Ф. Әмирхан «Габдулла Тукаев шигырьләре (Һәр милләтнең шөгарасы...)» дигән рецензия (1907 ел, 3 декабрь) яза һәм иҗатында теленең татарчалаша, камилләшә баруын мактый. М. Мәһдиев: «Тукай иҗатына Ф. Әмирханның мөнәсәбәте аеруча әһәмиятле: ул ипләп-җайлап кына Тукайны халыкчанлыкка этәрә, аның Уральскидан алып кайткан госманлы-төрки телен чистартуга булыша. Гомумән, тәнкыйтьче буларак, Ф. Әмирхан гомере буе Тукай иҗатын ялгыш бәя алудан саклап, шагыйрь исән вакытта исә аңа ярдәм итеп килә» [6: 314], – диюе белән хаклы.

«Габдулла Тукаев шигырьләре (Габдулла әфәнденең...)» (1908 ел, 2 февраль) язмасында һәм тәнкыйть, һәм бик югары дәрәҗәдә мактау урын ала. Касыйм Уралецның Тукай иҗатына гадел булмаган бәяләренә җавап итеп, Ф. Әмирхан 1908 елгы 17 июнь һәм 13 июль саннарында «Татар шагыйрьләре» дигән күләмле мәкалә белән чыга. 1909 елның 26 февралендә басылган «Габдулла Тукаев диваны» мәкаләсендә исә шагыйрь иҗатында тирән хис-кичерешләр, гүзәл тасвирлар булуны мөһим дип күрсәтә. Алга таба да Тукай иҗаты Әмирханның игътибар үзәгендә кала.

«Мавәраэннәһердә сәяхәт» (1908 ел, 2 март) Заһир Бигиевнең шул исемдәге әсәре басылу уңае белән язылган. Автор әсәргә бик югары бәя бирә, бер үк вакытта кайбер хата фикерләрен дә күрсәтеп бара. «Низамлы мәдрәсә» (1908 ел, 9 март) С. Рәмиевнең шулай аталган пьесасына кагыла. Ф. Әмирхан әсәрдә Садыйк образының тулы эшләнмәвенә игътибар итә, ә инде 1908 ел 3 апрель санында чыккан М. Гафуриның «Үги балалар» китабына тәнкыйтендә «фикерне типлар вә каһарманнар» ярдәмендә аңлатуның гына әдәбилек хакында сөйләвен ассызыклый. «Хыялмы, хакыйкатьме?» дә («Әлислах», 1908, 19 апрель) Фатих Кәриминең шул исемдәге китабына мөнәсәбәтле «ачы каләме белән берәр ачы милли мәсьәлә кузгатуын» әһәмиятле саный.

1908 елда Әмирхан яшьләр темасына махсус мәкаләләр багышлый. Аның «Яшьләр колагына бер сүз» (1908 ел, 4 май) язмасы татар яшьләрен милләткә файдалы булырга өндәп язылган. Баш мәкалә итеп эшләнгән «Казан, 3 июнь» 21 майда Петербург яшьләренең «Нәшре мәгариф» җәмгыяте оештыруын хуплап иҗат ителгән. Елдан-елга әдипнең яшьләргә адресланган язмалары саны арта. Шул ук вакытта ул «яшьләр» сүзен еш кына «яңарыш яклы, аның әһәмиятен аңлаган кешеләр» мәгънәсендә дә куллана.

1908 елны «Әлислах»ның 8 һәм 30 сентябрь саннарында аның «Әдәбиятка гаид (*бәйләнешле)*» мәкаләсе басыла башлый. Татар әдәбияты хакында сүз алып баручы бу хезмәт «Нәрсә ул әдәбият?» дигән сорауга җавап белән башланып китә, әдәбиятка шактый киң (фәнни әдәбият, публицистик әдәбият һ. б. керә) һәм төп билгесе итеп авторы булу күрсәтелгән билгеләмә бирелә. Әдәбиятның башлангычын халык авыз иҗатында дип, Ф. Әмирхан аны дини әдәбият, рухани әдәбият алыштырганлыкны, аннары ярым дини, ярым дөньяви әсәрләр иҗат ителүне билгели. Дөньяви әдәбият туу баскычын әдип Каюм Насыйридан башлый һәм монда рус әдәбиятының тәэсире зур булуны күрсәтә. Шулай итеп, татар әдәбият тарихын баскычларга аерып, ул шуларга хас сыйфатларны барлый, әдәбият күренешләрен өйрәнү һәм бәяләүгә хронологик таныл-белү ысулын алып килә.

Финанс кыенлыгы сәбәпле 1909 елның 22 июнендә «Әлислах» чыгудан туктагач, Ф. Әмирханның әлеге тематик бәйләмнәре башка газета-журналларга күчә. 1909–1912 елларда мәкаләләренең саны азая, алар «Йолдыз», аннары «Идел», «Кояш» газеталарында, «Ялт-йолт» журналында ешрак басыла. Боларда ул мәгълүмат җиткерү максатын алга чыгара. Әдипнең каләме матур әдәбиятка, аның повесть, драма кебек катлаулы жанрларына ешрак мөрәҗәгать итә башлый.

«Әлислах» чоры Ф. Әмирханның вакытлы матбугат мәйданында иң актив эшләгән чоры була. Ул үзен милләтпәрвәр фикер иясе, сәясәтче итеп таныта. Аның иҗтимагый-сәяси язмалары белән танышканда бер нәтиҗә тынгы бирми: әгәр авыруы булмаса, Ф. Әмирхан татар халкының иң кыю сәясәтчеләреннән берсе, Дума депутаты, сәяси әйдаман булыр иде! Юкка гына япь-яшь Фатихны Бөтенрусия мөселманнарының II съездына (1906 елның гыйнвары) укучы яшьләр исеменнән делегат итеп сайламаганнар!

Аның публицистик мәкаләләрен бер омтылыш, авторның татар дөньясын, татар җәмгыятен – мәгарифен, мәгърифәтен, фәнен, татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен үстерү аша – үсеш юлына чыгару нияте берләштерә. Нинди генә темага алынмасын, әдип эмоциональ тәэсир итү яки башка халыклар тормышы белән чагыштыру аркылы яңарышның, алгарышның мөһимлеген, заруриятен ассызыклый. Шуңа да, Р. Әмирхан бик дөрес билгеләгәнчә, «...ул бәхетле иде: үзе исән вакытта ук гаҗәеп үзенчәлекле талант иясе буларак танылды, шөһрәт казанды, милли әдәбиятыбызның йөген төптән җигелеп тартучы фидакяр затлардан саналды. Мәгълүм ки, мондый сәгадәт фәрештәсе һәркемнең дә иңбашына кунмый» [2: 332].

Фатих Әмирханның газета-журналларда эшчәнлеген күз алдыннан кичергәндә, аның тулы бер буын татар милләтпәрвәрләре өчен рухи таяныч, якты маяк, иң гүзәл үрнәк булганлыгын искәртергә кирәк. Күренекле «Могикан» (1969) поэмасында Х. Туфанның «Шәмен түгел, җанын гүя ягып / Яктыртты да безнең йөзләрне...» дигән бәясен аның бу дәвер публицистикасына карата кабатларга мөмкин.

**Әдәбият**

1. «Әлислах» газетасының библиографик күрсәткече / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1991. 78 б.

2. *Әмирханов Р*. Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 384 б.

3. *Галимуллин Ф.Г.* Фатих Әмирхан – әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесе // Фатих Әмирхан: традицияләр һәм заманчалык: (Тууына 120 ел тулуга багышланган республикаара фәнни-гамәли конференция материаллары). Казан, 2006. Б. 3–17.

4. *Ганиева Р.К.* Фатих Әмирхан // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т.: XX йөз башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. Б. 99–116.

5. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман: Тукай фәне. Әдәби тәнкыйть. XX гасыр башы татар әдәбиятында традицияләр һәм яңачалык / Кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

6. *Мәһдиев М.* Сызып ак нур белән...: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр / М. Мәһдиев; [төз. Г. Хәсәнова; кереш сүз авт. Д. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 583 б.

7. *Фатих Әмирхан*. Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

8. *Фатих Әмирхан*. Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*zagik63@mail.ru*

УДК 82-95

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ФИКЪҺ ХАКЫНДА УЙЛАНУЛАРЫ

***(Муса Бигиев хезмәтенә бәяләмә)***

Вниманию читателей представлена статья-рецензия классика татарской литературы, публициста, литературного критика Ф. Амирхана на книгу публициста, писателя, общественного деятеля Мусы Бигиева (1873/1875–1949) «Кавагыйде фикъһия» («Свод правил об исламском праве»). Данный сборник был подготовлен М. Бигиевым по просьбе ученого-просветителя, религиозного и общественного деятеля Ризы Фахретдинова (1859–1936) и является результатом создания проекта шариатского журнала для российских мусульман. Сразу же после выхода в свет книги «Кавагыйде фикъһия» Ф. Амирханом напечатана статья на страницах газеты «Йолдыз» («Звезда», 1910, № 595, 598) за подписью «Фатих Амирхан».

Ф. Амирхан был грамотно осведомлен и подготовлен в вопросах религии, исламского права, истории, тем самым представил объективную оценку данного сочинения. Об этом свидетельствует упомянутая выше критическая статья, в которой он подробно останавливается на истории исламского права, предпосылок написания, необходимости среди общественности и дает положительную оценку книге.

Представленная статья-рецензия печатается на кириллице впервые в текстологической обработке с дополнениями и подстрочным словарем.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, Муса Бигиев, фикъһ, «Кавагыйде фикъһия», рецензия, публицистика.

The readers are presented with an article-review by the classic of Tatar literature, publicist, literary critic F. Amirkhan on the book by the publicist, writer, public figure Musa Bigiev (1873/1875–1949) “Kavagyde fiqhiya” (“Code of rules on Islamic law”). This collection was prepared by M. Bigiev at the request of the scientist-educator, religious and public figure Riza Fakhretdinov (1859–1936) and is the result of the creation of a project of the Sharia magazine for Russian Muslims. Immediately after the publication of the book “Kavagyde fiqhiya”, F. Amirkhan published an article in the pages of the newspaper “Yoldyz” (“Star”, 1910, No. 595, 598) signed “Fatih Amirkhan”. F. Amirhan was competently informed and prepared in matters of religion, Islamic law, history, thus he presented an objective assessment of this work. This is evidenced by the above-mentioned critical article, in which he dwells in detail on the history of Islamic law, the prerequisites for writing, the need among the public and gives a positive assessment of the book. The presented article-review is printed in Cyrillic for the first time in textual processing with additions and a word-by-word dictionary.

**Keywords:** Fatih Amirhan, Musa Bigiev, fiqh, «Kavagyide fiqhiya», review, journalism.

*Татар әдәбияты классигы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның (1886–1926) тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Мәгълүм ки, яңа китап, җыентыклар яки берәр әсәр нәшер ителү белән газета-журнал битләрендә тәнкыйть-*

*бәяләмәләр күренә башлый, моны XX гасыр башы өчен хас булган күренешләрнең берсе дип тә әйтергә мөмкин. Ф. Әмирханның Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Камал, К. Әмин, Т. Соловьев, З. Һади, З. Бигиев һ. б. әдипләрнең яңа басылып чыккан басмаларына карата язган бәяләмәләре шул чор матбугатының әйдәп баручы басмаларында – «Әлислах», «Йолдыз», «Кояш» газеталарында басыла. Күбесе соңрак әдип күптомлыкларының эчтәлегендә дә урын ала. Ләкин бүгенге көнгә кадәр киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаганнары да бар. «Фәнни Татарстан» журналының әлеге санында Ф. Әмирханның «Йолдыз» газетасында (1910 ел, 595 (10 октябрь) һәм 598 (17 октябрь) саннарында) «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган «Кавагыйде фикъһия» (Муса әфәнде Бигиевнең соңгы әсәре) дип исемләнгән мәкалә-бәяләмәсе тәкъдим ителә.*

*Дин галиме, публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Муса Җарулла улы Бигиев (1873/1875–1949) 1909–1910 елларда мәгърифәтче галим, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Риза Фәхреддин (1859–1936) үтенече белән ислам хокукы мәсьәләләренә багышланган махсус журнал проектын эшли, һәм шушы эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, «Кавагыйде фикъһия» («Фикъһ кагыйдәләре», 1910) хезмәте дөнья күрә. Ф. Әмирхан әсәргә уңай мөнәсәбәтен белдерә, аның шәкертләрләрнең, имам-мөгаллимнәрнең фикри үсеше өчен ярдәм итүче басма булуын күрсәтеп, авторын «заман ихтыяҗын аңлаучы, вә ачык күз белән карый алучы фәкыйһ» буларак бәяли. Бәяләмәдән Ф. Әмирханның дин, фикъһ, тарих мәсьәләләрендә әзерлекле булуы һәм хезмәткә тиешле бәя бирә алуы ачык күренә, әлеге язма – шуңа дәлил.*

*Түбәндәге мәкалә-бәяләмә текстологик яктан эшкәртелеп һәм астөшермәләр белән тулыландырылып, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Ул алга таба Ф. Әмирханның алты томлы «Әсәрләр» академик басмасының дүртенче томында урын алачак.*

## «Кавагыйде фикъһия»
## *(Муса әфәнде Бигиевнең соңгы әсәре)*

### I

Хосусый «Кавагыйде фикъһия» тугрысында сүз сөйләүдән элек гомум фикъһ тугрысында берничә сүз әйтүне кирәк табам. Ислам голәмасының фикъһ дип исем биргән гыйльми ике җәһәтне хавидер[1]: берсе – Мәгъбүд[2] белән бәндә арасындагы мөнәсәбәткә гаид[3] кавагыйд, кыйсем дигәре[4] дә бәндәләрнең үз араларында булган мөнәсәбәтләренә гаид кавагыйддән гыйбарәттер. Бу соңгы кыйсемен, хәзерге фән тәгъбире белән әйткәндә, «хокук» кыйсеме дияргә кирәк буладыр.

[1] Хавидер – эченә алган.
[2] Мәгъбүд – Аллаһ.
[3] Гаид – караган, бәйләнеше булган.
[4] Кыйсем дигәре – башка өлеше.

«Хокук» – инсанның мәдәнияте шикелле үк иске бер нәрсә, болар бергә туганнар, бергә тәрәккый иткәннәр вә бергә баралар вә илә[1], машааллаһ, бергә барачаклар. Дине ислам дөньяда нәшер ителә[2] башлаудан 3–4 мең еллар мөкаддәм[3], шул карньнең[4] мөтәмәддин[5] милләтләре арасында, үзләренең әхлак вә табигатьләренә муафыйк хокуклары (фикъһлары) булган. Мәдәният Асия елгалары буенда дөньяга килә башлаганда, хокук әле вакты тофулиятендә[6] генә булып, шул карньнең кешеләре шикелле үк, шәфкатьсез һәм гадаләтсез булган. Затән[7], әле ул вакытта аны тыйфел[8] дип әйтергә дә ярамый... мозгасы, галякасы,[9] теләсәгез нәрсәсе диегез, ничек тә бер башы. Мәдәният юнанлыларга күчкәч, демократия сыйныфының иҗтиһады аркасында хокукның артык гадаләтсез кагыйдәләре гадаләткә якынрак кагыйдәләр белән алмаштырыла башлый; мәдәният инде румалыларга күчкәч, ул бөтенләй бер мөтәзабыт[10] кавагыйд сурәте алып, инсаннарның зәгыйфь бер кыйсеменә дә беркадәр химая күрсәтә[11] башлый. Бу хокук кагыйдәләрен Европаның башка милләтләре дә акрын-акрын румалылардан күчерәләр вә үзләренең дәрәҗәи мәдәниятләренә вә заманнарына мөнасиб[12] сурәттә эшли баралар.

Ләкин Европаның бу хокукы XVIII гасырга кадәр шәфкатьтән ерак хәлдә бара, монда җәзаның җинаятьтән җиңел булмавы кагыйдәсе бөтен мөлхакате[13] белән хөкем сөрә вә бигрәк тә мәхәббәтсез тарафы – бу хокук җир эшләүчеләрнең җир хуҗаларына кол булып торуларын үз өстенә алып килә (крепостное право[14] яки феодализм) унсигезенче гасыр голәмасы хокукның бу каты күңеллелегенә бик ныклап һөҗүм итә башлый һәм италияле Беккариянең «Җинаять һәм җәза» исемле әсәре[15] бу хосуста бик күп тәэсир күрсәтә; икенче тарафтан, Франциянең ихтиляле кәбире[16] феодализмга актыккы

[1] Илә – чаклы, кадәр.
[2] Нәшер ителә – тарала, җәелә.
[3] Мөкаддәм – элек, әүвәл.
[4] Карньнең – чорның, гасырның.
[5] Мөтәмәддин – мәдәниләшкән, алга киткән.
[6] Вакты тофулиятендә – балалык вакытында.
[7] Затән – нигездә.
[8] Тыйфел – бала, сабый.
[9] Галякасы – бәйләнеше, мөнәсәбәте.
[10] Мөтәзабыт – билгеләнгән, тәгаенләнгән.
[11] Химая күрсәтә – яклый.
[12] Мөнасиб – яраклы.
[13] Мөлхакате – кушылулары, өстәмәләре.
[14] Чыганакта кириллицада язылган.
[15] Италияле хокук белгече (юрист), фәлсәфәче, икътисадчы һәм җәмәгать эшлеклесе Чезаре Беккариа Бонезана (1738–1794) тарафыннан язылган «Җинаятьләр һәм җәзалар хакында» («О преступлениях и наказаниях», 1764) трактаты. Трактат рус теленә 1803 елда тәрҗемә ителә.
[16] Франциянең ихтиляле кәбире – Бөек француз инкыйлабы (1789–1799), XVIII гасырдагы Франциянең социаль һәм сәяси системасы дучар булган иң көчле үзгәрешләр. Үзгәрешләр нәтиҗәсендә Франциядәге феодаль «Иске тәртип» һәм абсолют монархия юкка чыгарылып, ирекле Беренче француз җөмһүрияте оеша (1792).

зарбәне[1] ясарга ашыга. Күп тә үтми җинаятькә мөтәгалликъ[2] хокукта «Җәзаи сәйеә[3] – сәйеәи мислүһә»[4] әсасы гокубәтнең[5] җинаятьтән җиңел булуы әсасына урын бирергә мәҗбүр була.

Бу яңа әсас ибтина[6] иткән фикер, ягъни «Җинаятьтән тыелу җәзадан курку белән түгел, бәлки аның кабахәтен аңлау белән генә була ала» дигән фикер әүвәл эшкә куелган дәкыйкасыннан башлап бу көнгә кадәр бик күп имтиханнарга очраса да, һәммәсеннән мозаффариятле[7] чыга килә. Мөтәмәддин[8] Европаның бу көнге хокукы менә шушы хокук инде. Аның бу көнге тәкәммеле[9] дә – шушы кадәр тәдриҗи исляхат[10] нәтиҗәсе булган тәкәммел.

Дине ислам белән мөтәдәйин[11] халык арасында мөтәдавил[12] хокук шәригате – исламиягә бинаән кылынган[13] һәм гарәб мәдәнияте эшләп чыгарган хокуктыр. Гарәб мәдәнияте кәмаленә[14] ирешкән вакытларда бу хокук шул вакытта Европада мөтәдаваһ хокукка караганда бик күп гадаләтле[15] вә бик күп шәфкатьле булган. Бу хокук алдында иң фәкыйрь бер хөр һәм сөлес көррәи әрызның[16] хакиме[17] хәлифә мөсави[18] булганнар. Бу хокук һичбер вакытта үз җилкәсендә феодализм шикелле инсаниятkә килешми торган бер афәтне асрамаган. Бу хокук заманына тәбгыять[19] белән коллар дигән бер сыйныфны аерса да, аларга ул заманның башка хокукларына нисбәт күбрәк хак бирергә тырышкан.

Димәк, бу хокук чыккан вә тәрәккый иткән заманнарында бик югары урын тоткан һәм бихак[20] ул көннең бик мәдәниятле милләте – гарәб милләтенең вә гарәб хөкүмәтенең бөтен мөгамәләи дахилиясендә әсас игътибар ителгән. Гарәб мәдәнияте тәрәккый итә барган мөддәттә[21] бу хокукта (фикъһ) мөтәхассыйс[22] голәма, фикъһан рәхимәһүм

---

[1] Зарбәне – бәрүне.

[2] Мөтәгалликъ – бәйле.

[3] Сәйеә – явызлык, начарлык.

[4] Мәгънәсе: Явызлык җәзасы – шундый ук явызлык (яки начар гамәлнең җәзасы – шундый ук начарлык).

[5] Әсасы гокубәтнең – җәзаның нигезе.

[6] Ибтина – нигезләү.

[7] Мозаффариятле – өстен.

[8] Мөтәмәддин – алга киткән.

[9] Тәкәммеле – камилләшүе, үсеп җитешүе.

[10] Тәдриҗи исляхат – эволюцион реформалар.

[11] Мөтәдәйин – динле, диндар.

[12] Мөтәдавил – һәркем тарафыннан кулланыла торган.

[13] Бинаән кылынган – нигезләнгән.

[14] Кәмаленә – тулылыгына, бөтенлегенә.

[15] Гадаләтле – гадел.

[16] Сөлес көррәи әрыз – җир шарының өчтән бер өлеше.

[17] Хакиме – казые, хөкем итүчесе.

[18] Мөсави – тигез, бер дәрәҗәдә.

[19] Тәбгыять – иярүчелек, буйсынучылык.

[20] Бихак – хаксыз.

[21] Мөддәттә – вакытта.

[22] Мөтәхассыйс – белгеч.

Аллаһу[1] тарафыннан эшләнә вә тәкмил ителә[2] барган. Исламның бөтен рухын бик яхшы аңлаган бу голәма (бу көнге тәгъбир буенча мөҗтәһидин[3]) фикъһда иң вак тәфсыйлатны бик дикъкать белән ислам рухыннан тышкары чыкмыйча эшли барган вә шул ук вакытта шул көнге тереклек вә тормышның моктәзасына[4] да татбикъ итүне[5] онытмаган. Әлхасыйль, фикъһ ул заманда тормыш белән кулга-кул тотышып тәрәккый иткән. Әгәр дә без хәзрәти Гомәрнең (разыяллаһу ганһу) Коръәндә мәсариф[6] зәкявәттән[7] саналган мөәллифә[8] кылып, җәмәгасен зәкявәттән мәхрүм иткәнлеген вә ул аять белән гамәлне мослихәте[9] беткәнлектән мәнсух[10] дип игълан иткәнлеген хәтеремезгә китерсәк, фикъһның бәндә белән бәндә арасындагы кавагыйдендә моктәзый[11] хәл вә тереклек моктәзыйсы ул көннәрдә, ягъни әсхаб вә табигыйн[12] (ризван Аллаһу галәйһим) көннәрендә мөһим шәраиттән хисаб ителгән икәнлегендә шөбһә итәргә урын калмыйдыр.

Безгә бу көнгә кадәр мөҗтәһидин[13] вә фикъһаи ихтиляфын[14] бер дә аңлашылмаслык сәбәпләр белән бәян итәләр иде. Фикъһка югарыда күрсәтелгән караш белән караганда, моңар бер төрле дә хаҗәт калмый: заман вә мәкяннең[15] вә моктәзый хәлнең икътизасы[16] тугрыдан-тугры шушы төрлелекне тугдыра вә бу төрлелектә икътиза хәлгә нәзарән булганлыктан[17], фәкать фикъһның тәрәккыйсе хисап кылынырга тиеш була.

V вә VI гасырларда ислам дөньясында бер торгынлык башлана. Мөтәмәддин[18] мөселманнарны үзләренең вакытына нисбәт югары мәдәниятләре гаҗәбкә сәвекъ итә[19] башлый. Коруне уляның[20] мәдәни милләтләре харап иткән һәм бу көндә күз алдымызда күреп торганымыз кытай милләтен бер урында туктатып калдырган бу гаҗәб ислам мәдәниятенең башына да йитә. Галим исламда «Ләйсә фи-л-имкян

---

[1] Рәхимәһүм Аллаһу – Аллаһ сезгә рәхимле булсын.
[2] Тәкмил ителә – җитештерелә.
[3] Мөҗтәһидин –тырышучы, дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы.
[4] Тормышның моктәзасына – биредә: тормышта кирәк булган нәрсәләргә.
[5] Татбикъ итүне – килештерүне, яраклаштыруны.
[6] Мәсариф – чыгымнар.
[7] Зәкявәттән – аңлаудан, зирәклектән.
[8] Мөәллифә – китап язучы.
[9] Мослихәте – реформаторы, төзәтүчесе.
[10] Мәнсух – юкка чыгарылган.
[11] Моктәзый – кирәкле.
[12] Әсхаб вә табигыйн – сәхабәләр һәм иярүчеләр (сәхабәләрне күргәннәр).
[13] Мөҗтәһидин – дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы.
[14] Фикъһаи ихтиляфын – фикъһ берлеге булмау.
[15] Мәкяннең – урын, дәрәҗә.
[16] Икътизасы – кирәклеге.
[17] Нәзарән булганлыктан – карап.
[18] Мөтәмәддин – алга киткән.
[19] Сәвекъ итә – алга этәрә, сөрә, юнәлтә.
[20] Коруне уляның – борынгы гасырларның.

әбдагъ мимма кяна»[1] мәфһүме хөкем сөрә башлый. Шул көннең тормышында күрелгән һәммә нәрсәләр мөкаддәс күрелә башлый, һәммәноксаннар[2] да кәмаль санала башлый вә шул дәкыйкадан үз нәүбәтендә фикъһ та килеп җиткән урынында туктап кала. Ислам галәмендә гаҗәп куәтләнә, куәтләнгәннән-куәтләнә; дөньяви тәрәккыйдә дини фанатизм катыштырыла башлый, берничә гасырлар үтү белән Мавәраэннәһернең гакылсыз мөтәгассыйблары[3] иҗтиһад мөнкаризлык[4] дәгъвасын кылып, фикъһны туктаган урынында тимер сәлясил[5], әгълял[6] белән бәйләп куялар.

Нәтиҗәсендә ислам шәригатенә бинаән кылынган хокукның, тормыштан фәрсәхләр[7] белән артта калуы вә мәмалике исламиядә дә[8] мәтрүк булуы[9] туа.

II

Гәзитәләрдә укыгансыз, төрекләрнең гадлия[10] нәзарәте бу көн мәмләкәт хокукыны яңадан карап чыгу тәшәббесатында[11] тора. Әсас – Рим правосы тотылачагы игълан ителә.

Аллаһ ризасы өчен җавап бирегез, ник? Әллә госманлы хөкүмәтенең башында утырган кешеләр мөхәммәдиләр түгелме?

– Эш – хөкүмәт башында кемнең утыруында түгел, бәлки хәл вә заманның икътизасында[12]: вакыйган да, VII гасырдан бирле инде бер хәлендә калдырылган вә шул көннән бирле инде тормыш белән интыйбактан[13] чыккан бер хокукны, үз-үзен ихтирам иткән вә катле нәфес[14] итәргә риза булмаган бер милләт, ничек итеп әсас мөгамәлә итә алсын? Ислам шәригатенә бинаән ителгән фикъһ да иҗтиһад мөнкаризымы? Ул инде артык заман белән интыйбак итә алмыймы? Алай булса, мәңге иҗтиһад урыны булган вә һәр көнне яңадан, яңадан тормышка интыйбак итә ала торган Рим хокукы бар, менә төрекләр шуны әсас итеп алалар. Алар шуңар мәҗбүр!

– Һәй, ахмаклар, алай итү кирәк түгел иде, дисезме?

---

[1] «Булганнан да гүзәлрәк нәрсә юк» («Невозможно быть более творческим, чем то, что было») мәгънәсендә.

[2] Ноксаннар – кимчелекләр.

[3] Мөтәгассыйблары – фанатиклары.

[4] Мөнкариз – юкка чыккан.

[5] Сәлясил – чылбырлар.

[6] Әгълял – тимер богаулар.

[7] Фәрсәхләр – ераклык үлчәве (6–7 километр чамасы).

[8] Мәмалике исламиядә – ислам мәмләкәтләрендә.

[9] Мәтрүк булуы – ташландык булуы, яраксыз булуы.

[10] Гадлия – юстиция.

[11] Тәшәббесатында – инициативасында, бер эшкә тотынуында.

[12] Икътизасында – кирәклегендә, теләгендә, кушуында.

[13] Интыйбактан – яраклы булудан, килешеп торудан.

[14] Катле нәфес – үз-үзен үтерү.

Әйдә, мәмалике исламиядә[1] дә гамәлдән мәтрүк[2] ул фикъһның бәддогасы[3], аның тәрәккыенә манигъ булып килеп, мөселманнарга бик күп зарар китергән мөтәгассыйблар башына булсын!

Тормышның бөтен һөҗүмнәреннән менә инде VI гасыр дин эчендә генә ял итәргә өйрәткән татар милләте арасында дине ислам интишар итеп[4] җиткән көннән соң бу дингә бик нык багланган булганга вә үзара мөгамәләләрендә (никах, талак, тәкъсим[5] мирас вә илх[6]) шәригате исламиягә бинаән ителгән хокукны дәстүр[7] тотканга, фикъһның бу заман белән интыйбаксызлыгын хис итмәскә мөмкин түгел иде.

Менә шул хис татар арасыннан Әбүнасыйр әл-Курсави[8], Шиһаб әл-Мәрҗани[9], Муса Бигиев вә әмсалләрен[10] чыгарды.

Игътикадатны[11] схоластикадан коткару исеме белән башланган бу дини хәрәкәт, тиз бер заманда исламның тормыш белән иң яшь очраша торган мәйданына – фикъһка күчте. Арада инкыйраз иҗтиһад мәсьәләсе кузгалды, заманының иң бәсыйрәтле[12] голәма исламиясеннән хисапланырга тиеш бу затлар үзләре башлаган бу мәсьәләгә ничек караганнардыр, анысы тугрысында минем катгый мәгълүматым юк; алар ничек карасалар карасыннар, мәсьәлә мөселман адәмнәр өчен кирәкле җиреннән тотылган иде. Ләкин бу мәсьәләдән мөселманнар кирәгенчә файдалана алмады; гакылсыз вә бәсыйрәтсез мөтәгассыйблар мөселманнарны вә үзләре хезмәт итә торган динне дә мәгънәви инкыйразга өстерәделәр. Мин бераз гомумиләштереп читкәрә чыгып киттем. Фикъһка (хокук) кайтыйк. Ислах ителмәгән хокук тормыш дулкыннары белән көннән-көн дәстүрлектән чыга барды. Телемез белә торган фикъһ китапларының мәкятибе[13], тәдбирләре[14] ничек үзләреннән үзләре сакыйт була барсалар[15], башка кыйсемләре дә көннән-көн илтифатсыз[16] калдырылырга мәҗбүр була башлады. (Мисал кирәк булса, банка белән эш күрергә мәҗбүр теләгәнеңез нинди татардан «Риба[17] дөрестме?» дип сорап караңыз. Ул сезгә «Харам!»

[1] Мәмалике исламиядә – ислам мәмләкәтләрендә.

[2] Мәтрүк – чыгарылган, калдырылган.

[3] Бәддогасы – каргышы, начар теләге, явыз нияте.

[4] Интишар итеп – таралып, чәчелеп.

[5] Тәкъсим – бүлү.

[6] Вә илх – һәм башкалар.

[7] Дәстүр – төп законнар җыентыгы, кагыйдә.

[8] Дин эшлеклесе, илаһият галиме Габденнасыйр Ибраһим улы Курсави (1771/1776–1812).

[9] Дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889).

[10] Әмсалләрен – мисалларын.

[11] Игътикадатны – ышануны.

[12] Бәсыйрәтле – аңлы.

[13] Мәкятибе – язылулары.

[14] Тәдбирләре – алдан күрүләре, тиешле чаралары.

[15] Сакыйт була барсалар – юкка чыгып барсалар.

[16] Илтифатсыз – игътибарсыз.

[17] Риба – процент алу.

дияр дә, үз хәрәкәтен юллар өчен «Дарелхәреб[1] фәлән» дигән булып, үзе дә ышанмый торган лакырдыйлар сөйләр).

Менә фикъһның шушы кризис көннәре исламия мөхибләрен көннән-көн уйга төшерде вә шуның нәтиҗәсе булып та моннан 40–50 ел әүвәл татар арасында кузгатылган ислах фикъһ мәсьәләсе бу көн билфигыль[2] вөҗүдкә чыга башларга тиеш булды.

Бу бабта әүвәлге җиде адым шәрәфе Муса әфәнде хиссасына[3] төште. Муса әфәнденең илтизам иткән[4] вазифасы җиңел вазифа түгел. Зур ихата[5] вә бик саклык һәм эволюция белән революцияне бүлгән койманы бик зур ихтият[6] белән күз алдында тоту – һәммәсе бу вазифага дахил[7]. Менә күз алдымызда «Кавагыйде фикъһия». Аны укыгач, безгә әүвәлге адымының муаффәкыятьлелеге белән Муса әфәндене тәбрик итәргә генә кала.

Бу китап Муса әфәнденең башка әсәрләре шикелле үк тәрәддед[8] вә шөбһәне белми торган каләм белән язылган, вә бер-ике сәхифәсен укыгач та, үз бабында йәд[9] тулы сахибе[10] тарафыннан язылган икәнлеген күрсәтеп торадыр.

Фикъһ, шул без «хаос» дип белә торган вә мәдрәсәләремездә әллә нинди бер буталчыклык сурәтендә тәдрис ителә торган фикъһ кавагыйде Муса әфәнде каләме астында бер тәртиб, бер көллият[11] күрсәтә башлаган. Мин ул тугрысында тәфсыйлатка[12] керешмим. («Йолдыз»да ул тугрыда мәкалә булган иде). Минем өчен иң әһәмиятле маддәсе[13] – рухы. Бу җәһәтендә Муса әфәнде башка әсәрләрендәге шикелле үк заман ихтыяҗатын аңлаучы, вә ачык күз белән карый алучы фәкыйһ[14] булып кала. «Кавагыйде фикъһия»дә мәзкүр 38–173–174 нче кагыйдәләр вә аларны бәян рәвеше Муса әфәнденең киләчәктә фикъһка гаид язачак әсәрләренең дә бик мөһим булачаклыгын белдерәләр. Арамызда исламиятнең дәвамы бу кагыйдәләрнең шәкертләремез зиһененә росух иттерелә[15] алуына баглыдыр. «Кавагыйде фикъһия»дә Муса әфәндене шактый изтыйрабка[16] төшергән маддәләр дә юк түгел, башлычасы, табигый, милек хакы мәсьәләсендә. 187–188 һәм

[1] Дарелхәреб – сугыш мәйданы, фронт.
[2] Билфигыль – чынлыкта, чынлап.
[3] Хиссасына – өлешенә.
[4] Илтизам иткән – йөкләгән.
[5] Ихата – киртә.
[6] Ихтият – саклык.
[7] Дахил – кергән.
[8] Тәрәддед – икеләнү.
[9] Йәд – кул.
[10] Сахибе – иясе, хуҗасы.
[11] Көллият – бөтенлек, тулылык.
[12] Тәфсыйлатка – җентекләүгә.
[13] Маддәсе – өлеше.
[14] Фәкыйһ – юрист, шәригать законнарын яхшы белүче.
[15] Росух иттерелә – сеңдерелә.
[16] Изтыйрабка – борчуга, икеләнүгә.

189 нчы кагыйдәләр каралса, Муса әфәнденең нарын арасында[1] калганлыгы күренә, һәм милек зарарына китерелгән дәлилләрнең шулкадәр хис кертелеп язылып та, файдасына китерелгән дәлилләрнең котылынмаслык бер зәгыйфьлек астында калуы безгә Муса әфәнденең рухының бик ләтыйф[2] бер ягын күрсәтә. Бу әсәрендә Муса әфәнде, мөнәсәбәт килгәндә, төрле дини вә иҗтимагый мәсьәләләргә дә мөдахәлә итә[3]. Бу җәһәте белән «Кавагыйде фикъһия» шәкерт вә имамларымызның фикри тәрәккыйләренә күп хезмәт күрсәтә алачактыр.

*Фатих Әмирхан*
*Йолдыз. 1910. №* 595 *(10 октябрь), 598 (17 октябрь)*

*Басмага әзерләде:*
***Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*
***Зайнеева Гульнара Нургалиевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*gulnara.zaineeva@mail.ru*

---

[1] Нарын арасында – ике ут арасында.
[2] Ләтыйф – гүзәл.
[3] Мөдахәлә итә – керешә, арага кертә.

УДК 82.091+398

***М.М. Хәбетдинова***

# ТАТАР ТЕКСТОЛОГИЯСЕ ҺӘМ НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ

В статье систематизированы сведения о вкладе ученого-энциклопедиста Наки Исанбета в разработку вопросов татарской текстологии. В ходе исследования выявлены несколько направлений его деятельности: фольклорная текстология, археографические исследования, тукаеведение, комментирование наследия авторов прошлого, установление авторства текста, датировки и др. Доказано, что ученый формировался как фольклорист в русле «школы братьев Соколовых и Азадовского». Наки Исанбет является ярким представителем культурно-исторической школы татарского литературоведения. Подробное изучение текстологической лаборатории ученого будет способствовать повышению статуса академических изданий на татарском языке.

**Ключевые слова**: татарская литература, текстология, палеография, Наки Исанбет, тукаеведение.

The article systematizes information about the contribution of the encyclopedic schThe article systematizes information about the contribution of the encyclopedic scientist Naki Isanbet to the development of issues of Tatar textual criticism. During the study, several areas of his activity were identified: folklore textual criticism, archaeographic research, Tukai studies, commenting on the legacy of authors of the past, establishing the authorship of the text, dating, etc. It is proven that the scientist was formed as a folklorist in the mainstream of the "school of the Sokolov brothers and Azadovsky". Naki Isanbet is a prominent representative of the cultural and historical school of Tatar literary criticism. A detailed study of the textual laboratory of the scientist will contribute to raising the status of academic publications in the Tatar language.

**Keywords:** Tatar literature, textual criticism, paleography, Naki Isanbet, Tukai studies.

Нәкый Исәнбәт текстология өлкәсендә гаять зур тәҗрибәгә ия булса да, моңа нисбәтле карашларын фәнни яктан нигезләп, монография яки теоретик-методологик характердагы махсус мәкаләләр рәвешендә эшләмәгән, алар фәкать фольклор текстологиясе, татар кулъязма мирасы буенча яисә элгәргеләрнең мирасларына шәрехләмәләр рәвешендә басылган хезмәтләрендә һәм гомере буена алып барган тикшеренү эшләрен документлаштырган төрле материалларда гына теркәлгән. Шул сәбәпле практик текстологның төп текстологик мәсьәләләр буенча принципиаль карашлары системасы тулысы белән ачыкланмаган, имплицив килеш кала, һәм аларны галимнең басылып чыккан фәнни мәкаләләрен, хезмәттәшләренең рецензияләрен, стенограмма рәвешендә сакланып калган чыгышларын, гомумән, безне кызыксындырган проблематика буенча фикерләре очраган материалларын өйрәнү һәм анализлауга нигезләнеп кенә реконструкцияләргә мөмкин дип уйлыйбыз.

Фәнни әдәбиятта әлегә кадәр Н. Исәнбәт мирасын төрле яклап, бигрәк тә тулаем илдәге текстология фәне белән параллель рәвештә тотрыклы һәм эзлекле үскән карашлар системасы ноктасыннан өйрәнү омтылышы ясалмаган, булган чыганаклар аерым мәкаләләр белән чикләнә. Галимнең татар текстологиясенә керткән өлеше турында беренче фикер тел галиме Ф. Ганиевның юбилей уңаеннан язылган мәкаләсендә әйтелә [4]. З. Рәмиев [32], Ф. Миңнуллина [22], М. Хәбетдинова [38; 39] мәкаләләрендә, «Идегәй» дастаны текстологиясенә багышланган М. Усманов [36], Ф. Урманче [35], М. Хәбетдинова [40], [41] һ. б. мәкаләләрендә Н. Исәнбәтнең Тукай текстологиясе буенча эшчәнлегенә кыскача гына бәя бирелә. Татар текстологиясе тарихын эшләүгә Н. Юзиев [43] һәм З. Рәмиев зур өлеш кертә [30; 31; 32].

Н. Исәнбәтнең татар текстологиясе юнәлешендәге карашларын системалаштыру максаты белән язылган әлеге мәкаләне басмага әзерләү барышында исә галимнең жанр һәм күләм ягыннан төрле хезмәтләре: фәнни һәм кереш мәкаләләре, рецензияләр, докладлар, интервьюларына, шулай ук тарихи-әдәби һәм архив материалларына анализ ясалды. Шулар нигезендә аның иҗат тарихы һәм текст тарихы (аерым алганда, цензура язмышын өйрәнү); академик һәм академик булмаган басмаларны текстологик яктан басмага әзерләү мәсьәләләре (фәнни шәрехләү принциплары, хезмәтләрне композицион яктан оештыру, текстологик материалларны тикшерү-интерпретацияләү һәм бастырып чыгару – редакцияләр һәм вариантлар); атрибуция һәм хронология мәсьәләләре кебек текстология проблемаларын хәл итү ысуллары өйрәнелде һәм төгәл мисаллар китерелде.

Тикшеренүнең фәнни яңалыгы шуннан гыйбарәт: Н. Исәнбәтнең текстология проблемалары белән турыдан-туры бәйләнгән фәнни мирасы, бигрәк тә аның басма һәм архив материалларының тематик һәм жанрлар төрлелеге, аларны куллану мөмкинлеге киңлеге, тикшерелә торган чорның зурлыгы беренче тапкыр бөтенлекле итеп анализлана.

Н. Исәнбәтнең балачагы китаплар арасында уза, аның әтисе Сираҗетдин Закиров мулла була, әнисе Таибә абыйстай – остазбикә. Үсмер чагында ул олы абыйсы Зәки белән мәчет башыннан һәм күршеләренең чарлакларыннан иске китаплар эзли торган була. Үзенең «Баһаветдин бабай фәлсәфәсе» дигән тәүге хикәяләренең берсендә язучы 1914 елның җәендә абыйсы белән шулай китап эзләүләрен түбәндәгечә тасвирлый: «Бер көнне Зәки абзый безнең авыл мәчет башыннан иске кулъязма китап алып кайтты. Әйтүенчә, анда шундый кулъязма китап күп икән. Русия хөкүмәте татарларга бары тик XIX гасырда гына үз хәрефләрендә типография булдырырга рөхсәт бирә, аңарчы һәм аннан соң да әле бездә шулай үз әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез кулдан күчереп язылган китаплар белән алып барылган. Малаязда да болар шул культура мирасыбыз иде.

Күрәсең, Зәки абзыйның алар белән танышасы килгән. Менә ул аларны күгәрчен тизәгеннән тазартты: кайсы гарәп, фарсы телендә, кайсы безнең төрки телдә!» [23: 97–98].

Моны Н. Исәнбәтнең татар китабы тарихын шулай кыскача гына сөйләп чыгу талпынышы булган дип бәяли алабыз.

Малаяз мәчете түбәсендә сакланып калган борынгы фәлсәфи трактат кульязмасын кулына алгач, «Хәсәния» мәдрәсәсен тәмамлаган шәкерт, анда борынгы юнан фәлсәфәчеләре Аристотель белән Платон исемен күреп, бик гаҗәпләнә. Ул вакытта энесенә Зәки гарәпләрнең борынгы грек хезмәтләрен югалудан саклап калуы турында горурланып сөйли: «Нигә аңа исең китә, – ди. – Әнә, борынгы грек философларының китапларын грекчадан гарәп теленә күчереп, югалудан саклап калучылар кемнәр соң? Гарәпләр түгелмени? Европалылар ул философларның әсәрләрен гарәпчәдән үз телләренә тәрҗемә итеп укып кына белгәннәр, ә безнең мәдрәсә шәкертләре, гарәпчә укый белгәч, нигә ул философларны да укымасыннар да алар турында язмасыннар. Әнә безнең әткәй шүрлегендә «Шәмсия» китабы ята. Гарәпчә, XIV гасырда Алтын Урдада язылган. Беренчесе – мантыйк, шул Аристотельдән үстерелеп язылган фән ич. Бу да шул, хәтта үзебезнең төрки телдә дә» [23: 99].

Китапларның берсен актарып, яшь Нәкый аны күчереп язучының авылдашы Баһаветдин бабай булу ихтималлыгына игътибар итә, күчергәндә, китап битләре читенә үзенең шәрехләмәләрен дә төртеп барган, дип фаразлый [23: 100].

Балачактан ук бу китапларга «ата-баба мирасы» итеп карарга күнеккән Зәки абзасы ярдәме белән инде Малаяз чорында, яшүсмер чагында ук шагыйрь булып танылган Нәкый уку-язу тарихы белән ныклап кызыксына башлый. Әтисе мәктәбендә, Уфадагы «Хәсәния», Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә алган белемнәре аңа алга таба татарларның китап мәдәнияте тарихын максатчан өйрәнү өчен ныклы нигез була.

Борынгы китаплар коллекциясе туплау бу юнәлештә беренче адым була:

«Мин дә эзләндем. Эзләгән табар. Буш кул калмадым. Яшьтән бирле телебезнең сүзлеген, халык иҗатын җыйдым. Мәчет башларында күгәрчен тизәге астында күмелеп яткан борынгы кульязма китапларны алып төшеп, әрчеп-тазартып укыдым. Кулымда тел, фольклор һәм әдәбият тарихыбыз буенча, халкыбыз һәм гыйлемебез мохтаҗ булган, кайбер моңарчы ачылмаган борынгы кульязма ядкәрләр, материаллар, мәгълүматлар тупланды, нәтиҗәдә алар турында һәм гомумән борынгы әдәбиятыбыз тарихы турында башымда фикерләр хасил булды. Аларны гыйлем дөньясына чыгарырга, халыкка җиткерергә кирәк» [23: 314].

Н. Исәнбәт татар кульязма мирасын өйрәнү эшендә остазлары итеп Шиһабетдин Мәрҗани белән Каюм Насыйрины саный:

«Белмим – тумышым белән мин дә үткән йөзнең соңгы көннәренә булса да эләгеп калгангамы, әллә тарих һәм мәдәни ихтыяҗларыбыз шуңа кыстагангамыдыр, мин дә шул XIX йөзнең үзешчән энциклопедистларыбыз Шиһаб, Каюм бабайлар башлаган, ярты юлда калган гыйльми эшләрне күреп, әдиплегем белән генә чикләнмичә, алар эзеннән дә кереп киттем» [23: 313–314].

Ата-бабаларның кулъязма мирасы кыйммәтен үсмер вакытыннан ук аңлаган Н. Исәнбәт, олы яшькә җиткәч, киләчәк буыннарга түбәндәге сүзләрен әйтеп калдыра:

«Әйтик, безнең үзебезгә хас борынгы телебез, тамга хәрефле язма культурабыз, Иделдә озак заманнар дәүләт тоткан бер халык булуыбыз, үзебезгә бер халык булып оешып, үзебез өчен үзебез бар иткән дәүләт системабыз һәм шулай ук үткәндәге үзебез катышкан Шәрык мәдәниятләре тәэсирендә үскән озын тарихлы тел-әдәбият, мәдәният әсәрләребез, мирасыбыз бар. Язмабызга гына каралса да, шулар бар да хәреф, орфография алмашлыгы эчендә үскән, әле шушы XX гасырда гына ничә кат хәреф һәм орфографияләр алыштырып, дистәләп еллар тел-әдәбият, матбугат, культура тарихыбыз шулар артында ук күмелеп, томаланып кала килгән.

Димәк, бу борынгы тамга хәрефләребездән башлап, соңгы мең ел буена гарәп хәрефләрендә дә язылып килгән бу тарихи, әдәби язма культура мирасыбызны үзебез танып, шатырдатып уку остасы булмыйча, без төпле һәм әдәби грамоталы кеше була алмабыз» [23: 717].

Башта галим үзен текстларга шәрехләмәләр әзерләү буенча белгеч итеп таныта. Бу өлкәдә беренче тәҗрибәсе X гасыр гарәп шагыйре Әбү Фирас шигырьләренең тәрҗемәсен басмага әзерләү була. Галимнең шушы китапка кереш сүзе һәм әдәби тәрҗемәләре 1922 елда Мәскәүдә чыга торган «Чаткылар» дигән кулъязма журналда дөнья күрә [28: 110]. 1934 елда исә Н. Исәнбәт «Совет әдәбияты» битләрендә татар укучысын фарсы шагыйре Фирдәүсинең иҗаты белән таныштыра. Тарихи-мәдәни шәрехләмә рәвешендә язылган әлеге мәкаләдә борынгы Иран, шагыйрь таланты феномены, аның әсәрләре, аерым алганда «Шаһнамә»нең татар әдәбиятына йогынтысы турында мәгълүматлар бар [11].

Галимнең кызы Йолдыз Исәнбәт аның борынгы кулъязма китаплар сатып алырга акча җәлләмәвен, акчасы җитмәгәндә, азык-төлеккә дә алмаштырып алуын хәтерли. 1942 елда Мөхәммәдьяр Мәхмүт углының «Нуры содур» әсәре кулъязмасын табып алуы исә татар мәдәни хәятында кыйммәткә ия зур вакыйга була [14].

Нәкый аганың 1972 елда Сәйфи Кудашка язган хатында бер кызык хатирәгә тап булдык: «Сугыштан соң татар галимнәреннән юньле бер ханым Рабига Хакимова да, өемә килеп утырып, бу кулъязма белән танышып чыкты. Аннары Яфаров «бер кичкә генә укырга» алып торды. Алар икесе дә тиздән вафат булдылар, һәм бу әсәр хакында аерым хезмәтләре күренмәде. Алардан башка тагын бу 30 ел эчендә Казанда Тел-әдәбият институты, Академия филиалларында,

университет һәм пединститут кафедраларында әллә нихәтле телчеләребез, дипломлы, чинлы әдәбият галимнәребез «борынгы әдәбият» исеменнән лекцияләр сөйләп, хәтта моңарчы табылганнарны да үз табышлары итеп күрсәтеп китаплар чыгарып, гыйльми дәрәҗәләр алып кәсеп итсәләр дә, берсе бер минем өйгә килеп:

– Каяле, Нәкый абзый, шул манускрипны кулга тотып, күз генә салгалап карыйк әле, дип тә сораган татар кешесен күрмәдем. Хәер, Музейдан Хаванская дигән ярлы гына бер поляк хатыны килеп, миндәге кулъязмалар белән бик кызыксынып, соратып йөрде, мин аңа "Нуры содур"ның фоторәсемен биргәләдем. Ул бер-ике сәхифәсен, пыяла рамкага элеп, музейга куйды. (Күрәсең, "культурный кеше" булу өчен коры диплом һәм билет күтәреп, кукыраеп утыру гына җитми, культура үзеңдә дә булырга кирәк!)» [24: 10].

«Исәнбәтнең шау-шусыз эшләп бара торган бер изге эше бар иде. Шуны мөмкин кадәр уңышлы эшләр өчен, ул туктаусыз хәрәкәттә булды. Казан артында эшләгән чагында да, Башкортстан җәйләүләрендә дә, Җаек буйларында да, Себер авылларында да һәм Казан, Уфа, Петербургның бай китапханәләрендә дә ул күп материаллар җыйды. Борынгы татар әдәбиятын – халык әдәбиятын җыюны әйтәбез. Халкыбызның бәясе чикләнә алмаслык бай хәзинәсен җыюда Нәкый иң булдыклы хәзинәдар булып, ул хәзинәне искиткеч матур һәм кыйммәтле җәүһәрләр табып, тагы да баетты һәм ул байлыкның иң ышанычлы сакчысы булды», – дип сокланып яза күренекле галим турында үз истәлекләрендә фикердәше Бакый Урманче [23: 19].

Җәүдәт Миңнуллинга 1985 елда биргән интервьюсында энциклопедист галим бу вакыйганы түбәндәгечә тасвирлап сөйли: «Мөхәммәдьяр әсәрләре белән мин беренче тапкыр кырыгынчы еллар башында очраштым һәм аларны матбугатта чыгаруга ирештем. Моның белән горурланам, әлбәттә. Дөрес, узган гасырның урталарында күренекле рус галиме, тюрколог И.Н. Березин Мөхәммәдьяр дигән шагыйрьнең булуын исемләп белмәсә дә, ул чорда "Төхфәи мәрдан" дигән бер әсәр язылган булуын белгән. Ләкин авторы кем булуын һәм аның тагын "Нуры содур" дигән әсәре дә булуын әйтә алмаган иде. Ул – шагыйрьнең "Төхфәи мәрдан" поэмасына югары бәя биргән һәм андагы мәкальләрнең, фразеологик әйтемнәрнең кайберләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгарган иде. <…>

Мөхәммәдьяр, аның әсәрләре турында сүз чыккач, шуны да әйтеп үтәсе килә: билгеле ки, борынгы чор татар әдәбиятын, һәм, гомумән, аның тарихын тикшерү, өйрәнү өчен иң элек беренче кул чыганаклар – язма текстлар кирәк. Шуңа күрә яшьләрне әлегәчә халык арасында таралып яткан әдәби, тарихи ядкәрләрне тагын да активрак эзләп җыярга, аларны мөмкин кадәр күбрәк саклап калырга өндисем килә. Археографик экспедицияләр оештыруда башка фәнни үзәкләрдә кулланыла торган уңышлы алымнарны да безгә корал итеп алырга кирәк дип уйлыйм» [41: 179].

Н. Исәнбәт «үзенең тынгысыз археографик эзләнүләре нәтиҗәсендә байтак борынгы кульязмалар таба, һәм алар хәзерге көндә аның шәхси китапханәсендә саклана» [4: 84]. Безгә галимнең борынгы китаплар коллекциясе белән танышу насыйп булды. Н. Исәнбәт ул кульязмаларны мөмкин кадәр фәнни яктан нигезләргә дә тырышып караган: һәркайсының эченә кыстырылган аерым кәгазь битләрендә кульязманың исемен, күчерүче турында мәгълүмат, күләмен теркәп калдырган, һәр китапны пөхтә итеп ак кәгазьгә төреп, бәйләп куйган.

Сәйфи Кудашка 1972 елда язган хатында Н. Исәнбәт поляк коллекционеры В.Н. Терновский белән очраклы рәвештә танышуы турында кызыклы хатирәсе белән бүлешә:

«40 нчы ел иде бугай, шулай бервакыт кыш көне мин Казанда, Чехов базарында. Күрәм: начар гына киенгән бер авыл агае кар өстенә чыпта җәйгән дә ниндидер иске кульязма китаплар сата. Салкын, җил, җәяүле буран. Агаем бии. Сәүдәсе дә зур түгел инде, бар малы бер кочакка сыеп бетмәс, икегә җитмәс. Мондый язма китапларыңны бу салкында кем кулына алып карасын? Казан татарларымы? Алар шул ун ел эчендә (сүз ул еллар турында бара, онытмыйк. – *Н.И.*) шулкадәр үскән, культурада алар шулкадәр алга киткәннәр, хәтта ки контр булудан куркып, бабаларыннан калган язма әдәби мирас, язма мәдәният әсәрләренең үз кулларында булганнарын Урта гасыр инквизитор монахлары кебек утка ягып бетергәннәр яки җиргә күмгән, суга агызганнар. Ышанмаса, хөкүмәт кешеләре әнә аларның өйләренә кереп тикшереп карасын: хәзер инде бу татарларыбызның фикерләрендә бернинди искелек калдыгы да юк, идеологияләре чип-чиста. Алар әнә синең андый китаплар яткан чыптаңа күз дә салмый үтәләр, ялгыш күз кырые төшә калса да, йөзләренә мәсхәрәле төс чыгарып, яныннан тизрәк үтәргә ашыгалар. Булса-булса, шул чыптаңа минем кебек берәр өтек байгыш килеп туктар.

Билгеле, минем өс-баш та китаплы агайныкыннан әлләни аермалы түгел иде. Шулай да, дерелди-калтырый булса да, китапларын кулга алгалап карыйм. Яныма бер һәйбәт киенгән бер урта яшьле, мәһабәт кеше туктый, пенснедән. Ул да алып-алып карый. Берсен миңа да ачып күрсәтеп, русча әндәшә:

– Укый беләсезме, кем теләндә? Нинди әсәр, әйтә алмассызмы, авторы кем, яки күчерүчесе кем? Кайчан язылган икән?

Карыйм: бик матур алтынлап-көмешләп бизәкләнгән китап башы. Бик нәфис көмеш кара, оста кул белән язылган фарсыча шигърисәнсри әсәр. Шундук танып алам.

– Бу, дим, Сәгъди “Гөлстан”ы.

– О, даже сам Саади?.. – ди, куана тегем. Ул шундый тагын берничә язулы китапны, шундук сораган хакын биреп, сатып та алды.

Мин аңардан:

– Сез аны укый белмим дисез, берәр музей өчен аласызмы әллә? – дип сорыйм.

Ул:

– Ә нигә музей өчен генә? Үзем өчен. Күптән җыям мин аларны. Мондый кадерле язмалардан өемдә зур коллекция бар. Бу бит уникум. Нинди язу бит! Жемчужина Востока! Менә сез аларны турыдан-туры укый алу бәхетенә ирешкән кеше. Ә мин аларны карарга яратам, сәнгатенә сокланам. Берәр буш вакытыгызда миңа килеп чыга алмассызмы? Зинһар, рәхим итә күрегез әле. Бергәләп карарбыз. Танышырсыз, – дип, визитный карточкасын чыгарып бирде дә, хушлашып китеп барды. Карточкасында “Казан университеты анатомия театры профессоры Терновский” дип язылган иде» [24: 10–12].

«Ә Терновский һаман истә. Инде барыйм дип сорашсам, аны инде Мәскәү Казаннан үзенә алып киткән, академикмы-кем иткән. Шулай итеп, Казанда яшәгән зур мәдәниятле профессорның татарлар кулы белән язылган, ләкин аның кыйммәтен татарлар үзләре дә белмәгән кадерле китаплар китапханәсен мин бичара татар язучысы күрә алмый калдым» [24: 13], – дип уфтанып нәтиҗә ясый Н. Исәнбәт.

Палеографик эш белән параллель рәвештә галим фольклор әсәрләрен җыю методикасын да үзләштерә. 1910 елда әле Н. Исәнбәтнең җыю-туплау практикасы беренчел язуларны теркәп кую белән чикләнсә, 1920 елда инде ул бу эш белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнә башлый. Бу юнәлештә эш башлаганда ук, Н. Исәнбәт халык авыз иҗаты ядкәрләрен билгеле бер кагыйдәләргә таянып язып алырга кирәклеген, моның ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген яхшы аңлый.

«Нәкый белән очрашкан вакытта без рөшдия бүлегендә укый идек. Бу бүлектә иң әһәмият бирелгән фәннәр – риазият (математика) фәннәре, татар теле һәм әдәбият, тарих, җәгърафия иде. Гарәп һәм рус телләре аерым тел дәресләре булып укытылалар иде», – дип яза истәлекләрендә Бакый Урманче [23: 17]. Бөек рәссам истәлекләренә караганда, Н. Исәнбәт, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда, Хуҗа Бәдигый (1887–1940) оештырган фольклор түгәрәге әгъзасы булып тора [23: 18]. 1906 елда, татар телен һәм халык иҗатын өйрәнү өчен, Казанга күренекле венгр галиме, төрки телләр белгече Дьюла Месарош (1883–1957) килә. Урта Идел халыкларының матди һәм рухи мәдәнияте белән кызыксынган галим Казан һәм Себер губерналарындагы авыллар буйлап этнографик экспедициягә чыга. Аңа ярдәмче итеп Хуҗа Бәдигыйны билгелиләр. Шул рәвешле, Бәдигый фольклор белән кызыксына һәм, 1919 елдан башлап, татар авыз иҗаты җәүһәрләрен җыеп, аларны бастырып чыгара. Хуҗа Бәдигый оештырган түгәрәк эшчәнлегендә Г. Рәхимнең дә, Г. Гобәйдуллинның да катнашуы билгеле [23: 19].

К.В. Чистов үзенең Современные проблемы текстологии русского фольклора («Рус фольклоры текстологиясенең хәзерге замандагы проблемалары») дигән темага докладында фольклор текстологиясенең төп төшенчәләренә билгеләмәләр бирә, аның ике бүлеген аерып чыгара һәм бурычларын билгели. «Тарихи-фольклористик текстоло-

гия – текстлар ничек яшәгән, аларны ничек язып алганнар һәм ничек бастырып чыгарганнар дигән кебек сорауларга җавап бирергә омтыла. Бу бүлек фольклорны өйрәнүчеләр өчен аеруча әһәмиятле. Аның максаты – текстларның оригинальлеген бәяләү алымнарын һәм принципларын эшләү, икенче төрле әйткәндә, текстларның филологик тәнкыйте». К.В. Чистов икенче бүлекне «эдицион текстология» дип атый, ул фольклор текстларын язып алу һәм бастырып чыгару типларын, принципларын, алымнарын һәм кагыйдәләрен билгели, ягъни текстларны ничек язып алырга һәм бастырып чыгарырга дигән сорауга җавап бирә [42].

Билгеле булганча, фольклор текстологиясе халык иҗаты әсәрләрен язып алу һәм бастыру кебек гамәли бурычлар белән тыгыз бәйләнгән. 1928 елда Н. Исәнбәт халык җырчысы (чәчән) Сукыр Фәррахның әсәрләре җыентыгын [33] һәм инкыйлаб елларында иҗат ителгән җырлардан торган «Әйдә җырлыйк!: (Революция чорында халык җырлары)» җыентыгын [5] төзеп бастыра.

Фольклорчы буларак, Н. Исәнбәт XX гасырның беренче утыз елында формалашкан «Соколовлар һәм Азадовский фольклор мәктәбе»нә (инкыйлабка кадәр – «рус мәктәбе», 1917 елдан соң – «совет фольклор мәктәбе» [29: 216]) нигезләнә. Мәктәпнең үзенчәлеге – «чичәннең шәхесенә игътибар, традицион фольклор текстына индивидуаль йогынтының котылгысызлыгын тану, әлеге йогынтының ни дәрәҗәдә булуы мәсьәләсен өйрәнү» [3: 11]. 1927 елда Б.М. Соколов мәктәпнең төп характеристикаларына биографик һәм социологик ысуллар арасындагы бәйләнешне дә кертә [3: 11].

Билгеле булганча, Сукыр Фәррах Н. Исәнбәт фатирында өч ай яши. Күрәсең, шул вакытта галим, чичән белән турыдан-туры элемтәдә торып, моңа кадәр язып алганнарын чагыштыру белән шөгыльләнә, кайбер өзекләрне яки аерым сүзләрне ачыклый, төгәллекләр кертә. Шунысы мәгълүм: Ю. Соколов та фольклор экспедицияләрендә катнашучылардан язып алган материалларны урында ук чагыштыруны таләп итә.

1928 елда Н. Исәнбәт, СССР Фәннәр академиясенең Башкорт комплекслы экспедициясе әгъзасы буларак, масштаблы эшкә тотына: «Идегәй» дастанының җыелма текстын басмага әзерләү белән шөгыльләнә башлый (тулырак карагыз: [40; 41]). Дастанның 500 еллыгына багышланган күләмле фәнни мәкаләсендә [23: 489–561] «Бу җыйнама текстның барлыкка килүе» параграфы аерым игътибарга лаек: галим анда дастанны җыйнау эшенең методикасын тәфсилләп бәян итә [23: 526–527]. Башкортча җыйнама текстны әзерләгәндә, ул үзе экспедицияләрдә язып алган өч язмага таяна, шулай ук аларны хезмәттәшләре теркәгән үрнәкләр белән дә чагыштыра. Текст белән эшләгәндә, Н. Исәнбәт укылыш вариантларын битләп китерү ысулын куллана, бер уңайдан «Идукай менән Морадым» дастанының теге яки бу вариантлары сакланган кулъязмалардан шәрехләмәләр дә китереп бара, аларны башкаручыларның фамилияләрен һәм кайда яшәүләрен

дә күрсәтә. Җыйнама текстның татарчасын әзерләгәндә исә Н. Исәнбәт тагын да күләмлерәк эш башкара. Башта текстолог 34 вариант нигезендә гомуми сюжетны, аннан соң 17 татар чыганагы буенча, текстның милли үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап, татарча версияне реконструкцияли. Беренче җыйнама текст «Совет әдәбияты» журналында басылып чыга, икенчесе – институтта саклланган кулъязмаларны өйрәнеп төзелгәне – фәнни-тикшеренү институты грифы белән нәшриятка кадәр барып җитә, әмма Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле бастырылмый кала, соңыннан махсус күрсәтмәгә бәйле бөтенләй тыела. Н. Исәнбәтне, Алтын Урда һәм Идегәйне идеаллаштыруда гаепләп, ярты гасыр дәвамында эзәрлеклиләр (тулырак карагыз: [23: 691–710]. Аның әлеге текстологик хезмәтендә иң кыйммәтлесе – фәнни мәкаләсендә үзе кулланган чыганакларның исемлеген бирүе [23: 503, 523–527]. Галимнең күптөрле һәм күп телдә иҗат ителгән вариантлар белән эш итү ысуллары бүген дә әһәмиятен югалтмаган, чагыштырулар бик кызыклы [23: 503–518].

«Оры аккан» бәете буенча текстологик тикшеренү аерым игътибарга лаек. Әлегә Н. Исәнбәтнең бу хезмәтен өлешчә генә бастыру мөмкин булды [6], [23: 471–476]. Башта галим бәетнең документаль һәм тарихи нигезен җентекләп өйрәнә (туфан вакыйгасы, телгә алынган персонажларның прототиплары һ. б.), аннан соң халык телендә сакланып калган риваятьләрне язып ала. 44 ел узгач, бәетнең төрле җирләрдә язып алынган вариантларына чагыштырма анализ ясый. Н. Исәнбәт үзенең чагыштыру эшен түбәндәгечә тасвирлый:

«Бәет шактый озын. Вариантларында, әлбәттә, кайбер аермалар, башкалыклар, үзенчәлекләр бар. Кайберләрендә васыять сүзләре озын һәм гомумән кабатлаулар бар. Күрәсең, үлем фаҗигалары зур һәм күп кешеләр башыннан үткәнгә, башта бер генә бәет чыкмыйча, берничәләп чыккан, бара-бара, алар кулдан кулга күчерелә-күчерелә, үзләреннән-үзләре бергә кушылып киткән булырга кирәк.

Кыскасы, бәетне укучылар алдына куйганда, мин андагы кайбер кабатлауларны кыскартып, аерым кеше исеменә караган юлларны үз тирәсенә җыеп, әһәмиятлерәк күренгән юлларын сайлап алып, монда күчердем» [6: 93].

Радиодан «Коңгыр бога» көен дөрес башкармаганнарын ишетеп, Н. Исәнбәт тарихи реконструкция ысулына мөрәҗәгать итә. Тикшеренү материалы буларак җыр тексты гына түгел, шул ук исемдәге башкорт эпосы һәм аның башка төрки халыкларда очрый торган вариантлары да, шулай ук эпосның туган җирендәге җирле үзенчәлекләр дә алына [8].

«Текстологик тикшеренүләрнең бурычлары арасында иң мөһимнәре булып өч нәрсә – текстларның авторлыгын ачыклау, укучыларга әсәрләрне авторлары ирке-ихтыярын бозмый тәкъдим итү, текстларны басмаларга дөрес урнаштыру санала» [32: 111], – дип билгели текстолог З. Рәмиев. 1940–1970 елларда Н. Исәнбәт Тукай иҗатын мөмкин кадәр тулырак бастыру өчен күп көч куя. Шул максаттан

1960–1970 елларда галим өч мәкалә бастырып чыгара («Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре» (1966) [18], «Тукайның әлегә игълан ителмәгән бер шигыре» (1969) [17], Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында (1971) [13] һәм алар аша киң җәмәгатьчелекне Г. Тукайның җыентыкларга кермәгән шигырьләре белән таныштыра. «Академик басманың икенче томына «Ялт-йолт» журналындагы текстларның бары тик 20–25 саннарындагысы гына алынып, аның 30 лап санынннан алынмауны, шулай ук «Уклар» һәм «Яшен» журналларыннан аз кертелүне «псевдонимнарны ачу өстендә җитәрлек гыйльми тикшеренүләр уздырылмау» нәтиҗәсе итеп саный. Н. Исәнбәт «Кәфештатыюш» имзалы текстларны томга кертүгә каршы чыга, чөнки Г. Тукай бу вакытларда инде каты авыру хәлдә Клячкин шифаханәсендә ята һәм, әйтик, һич тә үзе катнашмаган җыелышның хисабын – «Татар мәҗлесе» исемле мәкаләне яза алмый. 60 нчы еллар ахырында Н. Исәнбәт Г. Тукайның тугыз шигырен «Казан утлары» журналында тәфсилле аңлатмалар белән бастырып чыгарды. Юкка гына ул аларны үзенең мәкаләләрендә «әлегәчә игълан ителмәгән», «моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән» дип атамый, чыннан да, аларның җидесе Г. Тукай томлыкларында урын алмаган була әле. Исәнбәт белән якыннан аралашып, киңәшләшеп яшәгән Рашат Гайнанов икенче дүрттомлыкны һәм биштомлыкларны әзерләгәндә, боларны җентекләп өйрәнде һәм томлыкларга урнаштырды, икенче дүрттомлыкның аңлатмалары һәм искәрмәләрендә исә бу турыда әйтте дә», – дип хатирәләр белән уртаклаша З. Рәмиев [32].

Галим әдәби әсәрләрнең текстын өйрәнү буенча да шактый зур эшчәнлек алып бара. Бигрәк тә аның Г. Тукай җыентыклары нәшер ителү уңаеннан язылган мәкаләләре игътибарга лаек [19; 20]. Н. Исәнбәт шагыйрьнең академик басмасын эшләүне текстология мәктәбен үстерүгә тиңли: «Тукайны бастыру – зур гыйльми имтихан, шуның белән бергә безнең культура үсешебездә, әдәбият һәм тәнкыйть өлкәсендә әлегечә яхшылап каралмаган күп кенә мәсьәләләрне яңадан карау, әдәбиятыбыз тарихын һәм классикабызны өйрәнү, барлау ягыннан зур тәҗрибә һәм күрсәткеч булып тора. Тукай артыннан Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Мәрҗани, Насыйри, Кандалый... шикелле классика һәм әдәби мирасыбызны бастыру эше һич кичектерелмәстән көн тәртибендә тора. Шуның белән дә Тукай академик басмасы өстендә эшләү, аны яхшы иттереп бастыру үзе бер мәктәп булып тора» [20: 59]. Галим академик басма төзүнең шартларын билгеләп үтә: «Академик басманың иң беренче шарты дөреслек икәне – мәгълүм нәрсә. Тукай шигырьләрен Тукай язганча дөрес кенә иттереп бастырып чыгарырга кирәк. Дөреслек дигәннең астына иң элек хәреф, орфография, тыныш билгеләре, тезмә шигырьнең текст калыпларын, ритмнарын саклау шикелле элементар кагыйдәләр керә. Бу шартлар шулкадәрле гомуми ки, хәтта академик булмаган басмалар өчен дә болар канун хөкемендә.

Икенчедән, академик басманың дөреслеге әсәрләрнең хронологик дөрес төзелешендә, аларга бирелгән аңлатма һәм искәрмәләрнең дөрес һәм төпле булуында, шулай ук сүзлекчәдәге сүзләрнең дөрес бирелү һәм дөрес аңлатылуларында булырга тиеш.

Өченчедән, гыйльми басмада Г. Тукайның үзенә генә хас булган шигырь графикасы, сүз үзгәртүләре шикелле яклары хисапка алынырга, Тукай спецификасы өйрәнелеп, аның саклануы күзәтелергә, шулай ук бәхәскә юл калдыра торган нәрсәләргә урын бирелмәскә, андый нәрсәләр алдан ук бер нигезгә китерелеп чишелгән булырга тиеш» [20: 59–60].

Н. Исәнбәт, Г. Тукай басмаларындагы җитди кимчелекләрне ачып салып, аларны төзәтү юлларын күрсәтә. «Галимнең текстология өлкәсендәге эшчәнлеген күз алдына китерү өчен, аның Г. Тукай басмасындагы кимчелекләргә анализ бирүенә күз салу да җитә. Басмадагы текстларны лингво-стилистик тикшерү барышында Н. Исәнбәт анда күптөрле кимчелекләр таба, аларны классификацияли: шигырь калыбын һәм ритмын бозу, бер сүзне икенчесе белән алыштыру, тыныш билгеләрен ялгыш кую, орфографик һәм морфологик хаталар, ялгыш аңлатмалар, хронологик хаталар һ. б. Басмадагы кимчелекләрне классификацияләп бирү үзе генә дә галимнең бик күп аналитик эш башкаруы турында сөйли. Н. Исәнбәт кимчелекләрне классификацияләп кенә калмый, бәлки аларны конкрет фактлар китереп дәлилли дә. Әйтергә кирәк, галим дәлилләренең барысы да диярлек нигезле.

Мәсәлән, Г. Тукай басмасында «Кәфәштатыюш» имзасы белән бирелгән материаллар бар. Н. Исәнбәт бу имза белән китергән мәкаләләрнең Г. Тукайныкы булуы шикле дип таба. Чөнки: 1) ул мәкаләләрнең тел-стиль үзенчәлекләре Г. Тукайга туры килми; 2) бу мәкаләләрнең язылу вакыты Г. Тукайның үләр алдыннан Клячкин больницасында яту көннәренә туры килә, хәтта Г. Тукай үлгәч тә бу имза белән «Ялт-йолт» журналында мәкалә чыга. Болар барысы да Н. Исәнбәтнең текстология өлкәсендә эшләвен, тексттагы бик нечкә үзенчәлекләрне тотып ала торган галим икәнен исбатлыйлар», – дип нәтиҗә ясый Ф. Ганиев. [4: 85]

З. Рәмиев үзенең мәкаләсендә бер истәлек белән уртаклаша: «1978 елның 15 ноябре иде. Ул көн Бауман урамындагы Тукай клубында Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе һәм безнең институт әдәбиятчыларының яңа чыккан икенче дүрттомлыкны тикшерүгә багышланган берләштерелгән утырышы уздырылды. Бу утырышта Исәнбәтнең дә катнашуы һәм ике мәртәбә чыгыш ясавы хәтердә калган. Кайчандыр үзе төртеп күрсәткән кимчелекләрдән арыну буенча Рашат Гайнановның шактый зур эш башкаруын таныган хәлдә, ул Г. Тукай текстологиясенә кагылышлы һәм чишелми кала килгән мөһим проблемаларны да кузгатты. Орфографиянең камил булмавы аркасында текстларны дөрес итеп бирү читенлеген, азәрбайҗаннардан үрнәк алып, яисә Саблуковның «Коръән»ендәгечә Г. Тукай әсәрләрен дә гарәп язуы һәм кириллицада янәшә бастыру турында

уйларга кирәклекне, киләчәктә шагыйрьнең академик басмасын әзерләп, анда дини шигырьләрен дә урнаштыру, аларга мөнәсәбәттә вульгар социологизмны бетерү тиешлекне, томнарның техник яктан начар эшләнгәнлеген әйткән иде ул» [32].

Борынгы кулъязмаларга һәм әдәби әсәрләргә караган мәкаләләре арасында Н. Исәнбәтнең «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре» (1966) [10] һәм «Бу шигырьнең шагыйрәсе кем?: XVIII гасыр татар поэзиясе үрнәкләреннән» [12] дигән хезмәтләре игътибарга лаек. «Бу шигырьнең шагыйрәсе кем?» дигән язмасында галим Себергә җибәрелгән татар хатыны тарафыннан иҗат ителгән бер шигырь табуы турында сөйли, аның текстын бирә. Бу әсәрнең теле турында галим болай дип яза: «Казан татарларының әдәби теле XVIII гасырда һәм аннан да элек күптән формалашып килгән булуына бик матур мисалларның берсе була ала» [12: 148]. Җыр-көйләргә багышланган кызыклы язмасында – «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре» мәкаләсендә 1853 ел белән 1875 еллар арасында Янгилде авылында иҗат ителгән, шунда язып алынган никрут җырлары китерелә, һәм алар шактый киң тикшерелә. Шул җырларга анализ ясап, галим ул чор татар авылларының рухи тормышын бик калку итеп күз алдына китереп бастыра.

Бу җырларның характерын билгеләп, Н. Исәнбәт болай дип яза: «Шулай итеп, йөз ел элекке бу җыр дәфтәре бездә үткәндә никрутлар озату йоласы булуын, аның зур мәҗлесләр белән үзенә багышлап чыгарылган махсус «наз» дип аталган җыр-көйләр белән уздырылганын күрсәтә. Ихтимал ки, бу назлар башка җирләрдә дә табылса, аларны үзенә бер жанр җырлар дип тә атап була торгандыр» [10: 151].

Югарыда телгә алынган хезмәтләр Н. Исәнбәтнең борынгы кулъязмаларны, әдәби әсәрләрне актив җыючы, барлаучы һәм тикшерүче тынгысыз галим булуын күрсәтә.

Язучы архивында басылмый калган хезмәтләре дә шактый. Алар арасында бездә аеруча кызыксыну уятканнары да бар. Мәсәлән, Татарстан Язучылар берлегендә 1946 елның 26 апрелендә Габдулла Тукайның тууына 60 ел тулу уңаеннан үткәрелгән кичәдә Н. Исәнбәт тарафыннан сөйләнгән доклад тексты саклана. Әлеге хезмәттә галим киләчәктә дөнья күрәчәк Г. Тукай томнарының күләме аның басылып чыккан беренче томы кадәр өч том булырга тиеш дип билгели [16: 20].

С. Рәмиевнең 1924 елгы истәлекләренә таянып язган мәкаләсендә Н. Исәнбәт Г. Тукайның «Бер шәехнең мөнәҗәте» дигән кечкенә бер сатирик шигыренең ерак тамырларын ачыклый [9].

«Чыгтай һәм аңа карата Тукайның сатиралары» мәкаләсендә галим, шагыйрь әсәрләренең документаль нигезен күрсәтеп, Галиәсгар Чыгтай һәм Пётр Чаадаев шәхесләре турында кызыклы фактлар китерә [21].

Мирза Бәрхиевнең истәлек кулъязмасында Г. Тукайныкы дип аталып йөртелә торган кайбер шаян эпиграммаларны өйрәнеп, Н. Исәнбәт бу әсәрләр чыннан да Тукай тарафыннан иҗат ителгән,

дигән нәтиҗәгә килә [15]. Мәкаләдә галим Г. Тукай иярченнәренең исемнәрен (Габдулла Харис, Габдерәшит Рамазанов, Кыям Юлдашев кебек яшь шагыйрь-шәкертләр) китерә.

Күл буе мәдрәсәсе шәкерте истәлекләрендә сакланган хатирә безгә аеруча кызык тоелды:

«Тукай шулай сөйләшеп утырган арада, күп уйлап тормыйча, шул сүз уңае белән тоткарсыз рәвештә тиз генә берәр кисәк шигырь эпиграмма язып куя яки телдән әйтеп ташлый торган булган. Шәкертләр бер шулай аңардан:

"Сез, Тукай абый, бу хәтле шигырь чыгарырга материалны кайдан табып, кайдан уйлап бетерәсез?" дип сораганнар. Тукай җавабында: "Чишмәдән суны ала торасың, аның урынына яңа су килә тора", – дигән». Бу истәлеккә Н. Исәнбәт аңлатма биргән: «Ягъни, илһам чишмәсе дә шуның кебек берне язуга икенчесе хәзер булып тора, дигәне» [15: 1]. Галим әлеге мәкаләсендә Г. Тукайның Күл буе шәкертләренә багышлап язылган һәм шәкертләр дәфтәрендә сакланып калгалаган берничә эпиграммасын китерә:

«Кабан күленә боз катса,
Шәкертләргә юл була.
Ике шәкерт хәтем чыкса,
Җиңгәчигә пул була».

Н. Исәнбәтнең бу текстка биргән шәрехләмәсе:

«Хәтем чыгу – үлгән кеше атына Коръән укып садака төшерү. Иске фикерле шәкертләр кәсебе. Пул – акча. Җиңгәчи – фахешханә тотучы, ягъни, фахешханәләргә шундый Коръән хәтем чыгып акча җыючы иске тип шәкертләр йөриләр, дигәне» [15: 1].

Н. Исәнбәт мәкаләсеннән тагын бер өзек китәресәбез килә:

«Галләм хәзрәт мәдрәсәсе
Кабан күле буенда,
Галләм хәзрәт шәкертләре
Көн дә "тәтәй" куенында».

Яки:

«Җиңгәчигә бар дип әйтсә бәлфараз иблис сиңа,
Бар вә ләкин саклана күр, ләкмәсен сифлис сиңа».

«Әйтәсе дә юк, бу соңгысында үзара гына әйтерлек дорфа сүз катышкан. Тышкы яктан ул тискәре мәгънәдә дорфарак шаяру кебек тоела. Ләкин шул ук вакытта бу сүзләр астында элекке Казанда татар җиңгәчиләренең, Прахуп-Махуп абыстайлар тоткан фахешханәләрнең начар авыру тарату урыны булуы бик катгый әйтелә һәм шуның белән шәкертләрне андый йортларга йөрергә өндәү түгел, киресенчә, кисәтү ята. Үткен, кыска итеп, шәкертләр теленчә, "бәлфараз"-лар кыстырып, пародия белән әйтелгән бу ике юлы белән дә тукайлык ачык, шунлык аныкы дип исәпләргә кирәк», – дип нәтиҗә ясый Н. Исәнбәт [15: 2].

Аерым мәкаләсендә галим Г. Тукай турында бер авыл ямщигы хатирәләренең Гали Рәхим тарафыннан язып алынган булуын ачыклый: «Бу хатирә (12 елларда булса кирәк) карандаш белән ике битле кәгазьгә язылып алынган, астында “ишетеп язып алучы” дигән сүз янында бик уратмалы-бормалы имза – “Мөхәммәд Г.” дигән хәрефләре танылa. Гали Рәхим булмак кирәк» [7: 2].

Бу хатирә үз вакытында цензура аркасында басылмыйча калган, ләкин Н. Исәнбәт башка фикердә булган: «Тукайның үз заманында ук телләрдә дастан булып ярымфольклор сурәтчәсенә әйләнә башлавын күрсәткән бу сөйләкне игълан итүне кирәк һәм тиешле таптым» [7: 2].

Н. Исәнбәт 1941 елда «Татар шигърияте антологиясе»н төзү эшендә катнаша, бу хезмәт Казанда һәм Мәскәүдә татар һәм рус телләрендә чыгарга тиеш була. «Красная Татария» газетасында [1] дөнья күргән мәгълүматка караганда, Антологиягә «Идегәй» халык эпосыннан да өзекләр кертелергә тиеш була (Татар шигърияте антологиясе, 1941). Бөек Ватан сугышы һәм ВКП(б) ҮКның 1944 елның 9 августындагы күрсәтмәсе бу планнарны сызып ташлый. Н. Исәнбәт исеме 1957 елда редколлегия составыннан юкка чыгарыла. Антологиягә аның шигырь текстлары гына кертелә [2: 427–438]. Моның сәбәбе «Идегәй» дастаны гына түгел, «Миркәй белән Айсылу» пьесасының басмага әзерләнгән версиясе өчен Н. Исәнбәтне пантюркист дип эзәрлекли башлау булгандыр, дип фаразларга да урын бар.

1979–1980 елларда «Ялкын» журналында инкыйлабка кадәр иҗат иткән «онытылган» шагыйрьләр – Дәрдемәнд, Нәҗиб Думави, Габденнасыйр Рахманколый, Сәгыйть Рәмиев һ. б.ның шигырьләре басыла, соңрак алар «Татар балалар поэзиясе антологиясе»нә кертелә (1980) [34]. Һәр шагыйрь турында галим кечкенә биографик белешмә әзерли.

Н. Исәнбәтнең хатларын барлаганда, текстология белән бәйле берничә хат таптык.

1975 елда Равил иптәшкә язылган хатында, мәсәлән, Н. Исәнбәт, Уфага барып, «архивка бикләнеп, Риза Фәхреддиннең басылмаган 2 том «Асар»ы белән танышып чыгуга ирештем», – дип, шатлыклы хәбәре белән уртаклаша [24].

Хатларның берсе 1979 елда Ташкентта яшәгән галим Җәвад Алмазның вафатына мөнәсәбәтле аның туганнарының кайгысын уртаклашып язылган. Хатта аның Җәвад Алмазга биргән бәяләмәсе игътибарга лаек:

«Һәм мин шушы көнгә кадәр бу тәәссефле зур югалтуның тәэсиреннән чыга алганым юк. Чөнки... Җәвад борынгы татар әдәбияты буенча безнең иң зур белгечебез, бердәнбер зур хәзерлекле җитешкән галимебез иде. Бердәнбер дим! Чөнки ул Казаннан киткәннән соң, безнең әдәбият тарихы бабында аның дәрәҗәсендә этрафлы һәм шуның белән бергә Шәрык телләрен дә белгән галимебез юк» [25: 1].

Галим аның туганнарына үзенең үтенечен җиткерә: «Җәвадның кулъязма гыйльми эшләре, мирасы кулыгызда калды. Аның мирасы

нәкъ менә академия филиалы өчен бик кирәк. Шунлыктан алар бу хакта әлбәттә, кызыксынырлар. Һәм сезгә мөрәҗәгать тә итәрләр дип уйлыйм, бәлки, Җәвадның васыятьнамәсе дә бардыр.

Кыскасы, галимнең үзе үләр, аты калыр дигәндәй, аның эшләре югалмас, дигән өметтә калабыз» [25: 2].

Галим Җ. Алмазның апасы Мөгаззәмә ханымнан аның басылган хезмәтләрен җыеп, библиографик күрсәткечләр биреп, «Казан утлары» редакциясенә җибәрүен үтенә [25: 2].

Шул рәвешле, үз вакытының әйдәп баручы текстологларының берсе булган Н. Исәнбәтнең әлеге өлкәдәге роле түбәндәгеләр белән билгеләнә: татар текстологиясе аеруча актив формалашкан 1920–1980 еллар дәвамында ул археологик, текстологик, шәрехләүләр эшчәнлегенең үзәгендә кайный, икенчедән, күп мәсьәләләргә (Г. Тукай шигърияте һәм чәчмә әсәрләренең текстологиясе, «онытылган» мирасны кайтару һ. б.) һәм, текстологик проблемаларга (атрибуция һәм әсәрнең язылу вакытын билгеләү, әдәби әсәрләрнең иҗат ителү тарихы, әдәби текстларның цензура проблемасы) беренче булып тотынып, аларны хәл итүгә зур өлеш кертә.

Н. Исәнбәт үзенең хезмәтләрендә текстологиянең археография, палеография һәм әдәби чыганаклар белеме белән тыгыз бәйләнеше булуын ассызыклый.

Н. Исәнбәтнең фәнни мирасы аны милли әдәбият гыйлемендә мәдәни-тарихи мәктәпнең (әдәби әсәрне «кыйммәтле тарихи документ» итеп ассызыклый һәм әдәбиятны җәмгыятьнең тарихи үсеше белән бәйле тарихи процесс итеп аңлата торган мәктәп) лаеклы вәкиле итеп тану мөмкинлеге бирә, шулай ук ул, тикшерелә торган чорның социаль-сәяси тарихын өйрәнгәндә, язучының даирәсен дә исәпкә ала торган биографик ысул тарафдары да була.

Тукайчы Н. Исәнбәт шагыйрьнең кайбер әсәрләренең «әдәби тарихы»н ачыклау өлкәсендә мөһим ачышлар ясый: аның авторлыгын ачыклый, әдәби реминисценцияләр, теге яки бу әдәби фикернең «тышкы этәргеч»ләрен, шулай ук автор фикеренең үсеш процессын күрсәтү максаты белән, Г. Тукай иҗат иткән әсәрләрнең язылу тарихын ачыклый.

Галим, Г. Тукай басмаларындагы җитди кимчелекләрне барлап чыгып, академик басмаларда аларны төзәтү юлларын күрсәтә. Басмадагы текстларны лингво-стилистик тикшерү барышында Н. Исәнбәт зур аналитик эш башкара. Ул кимчелекләрнең классификациясен төзеп бирә: шигырь калыбын һәм ритмын бозу, бер сүзне икенче сүз белән алыштыру, тыныш билгеләрен ялгыш кую, орфографик хаталар, морфологик хаталар, ялгыш аңлатмалар, хронологик хаталар һ. б. Галим китергән дәлилләрнең барысы да диярлек нигезле һәм ышандыра. Н. Исәнбәт шагыйрьнең мирасын халкыбызга кайтару эшенә зур өлеш кертә. Тәҗрибәле галимнең фикерләре академик басмаларның сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә. Г. Тукайның моңарчы чык-

кан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләрен барлап, авторлыгын дәлилләп, әсәр язу тарихларын билгеләп чыга.

Археографик эзләнүләре нәтиҗәсендә байтак борынгы кульязмалар табып, Н. Исәнбәт бай шәхси китапханә туплый. Галим Казан ханлыгы чоры шагыйре Мәхмүд углы Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасын беренче булып таба һәм шагыйрь тормышы һәм иҗаты турында зур мәкалә бастырып чыгара (текстларның авторын билгели, ул вакыттагы тарихи шартларга анализ бирә, әсәрнең төзелешен һәм телен ачыклый, өзекләр китерә) .

Н. Исәнбәтнең фольклор текстологиясе өлкәсендә эшләгән хезмәтләре шулай ук актуальлеген югалтмаган. Ул, фольклор текстологы буларак, җыйнаучы, кәгазьгә күчереп язучы, интерпретатор да була, фольклор текстларын басмага әзерләгәндә, танып белүче, тикшеренүче, аңлатмалар бирүче вазифаларын да башкара. Фольклорчы Нәкый Исәнбәт игезәкләр Юрий һәм Борис Соколовлар һәм Марк Азадовскийлар мәктәбенә таянып формалаша. Галим берничә җыючы тапкан текстларны чагыштыру өлкәсендә активлык күрсәтә. Җыйнама текстларны басмага әзерләгәндә, Н. Исәнбәт беренчел чыганаклар белән мөмкин кадәр сак эш итә, аның текстка төзәтмәләр кертүе даими кулланылган эпитетларны, чагыштыруларны һ. б. ны торгызуга яисә хаталы интерпретацияләрне төзәтүгә, төгәлсезлекләрдән котылуга юнәлтелгән була. Җыйнама текстны төзегәндә, галим эшнең беренче этабында төрле укылышлы текстларны битләп чагыштыру алымына мөрәҗәгать итә, аннан соң гына, шуларга нигезләнеп, үз вариантын әзерли. Без Нәкый Исәнбәтнең «тарихи-фольклор текстологиясе»нә (Т.Г. Иванова тәкъдим иткән төшенчә) керткән өлешен алга таба монография дәрәҗәсендә өйрәнүгә лаек дип саныйбыз.

**Әдәбият**

1. Антология татарской поэзии // Красная Татария. 1941. 3 апр.

2. Антология татарской поэзии. Казань: Таткнигоиздат, 1957. 606 с.

3. *Бахтина В.А.* Фольклористическая школа братьев Соколовых (Достоинство и превратности научного знания). М. : Наследие, 2000. 336 с.

4. *Ганиев Ф.* Әдипнең татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге // Әдип һәм галим. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. Б. 74–86.

5. Әйдә җырлыйк!: (Революция чорында халык җырлары) / җыючысы Н. Исәнбәт. Казан: Татиздат, 1928. 40 б.

6. *Исанбет Н.С.* Мое первое путешествие в Заказанье: «Наводнение в Ура» // Tatarica. 2023. №2 (21). Б. 79–101. URL: https://doi.org/10.26907/2311-2042-2023-21-2-79-101 (мөрәҗәгать итү көне: 22.08.2025).

7. *Исәнбәт Н.* Габдулла Тукай турында бер авыл йәмшегенең хатирәләре // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 3 кгз.

8. Исәнбәт Н. «Коңгыр бога» көе: тарих тамырлары һәм поэтика төрки халыклар мәдәнияте контекстында // Tatarica. 2023. №1 (20). С. 32–43. URL: https://doi.org/10.26907/2311-2042-2023-20-1-32-43 (мөрәҗәгать итү көне: 22.08.2025).

9. *Исәнбәт Н.* «Биш къаф» // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 2 кгз.

10. *Исәнбәт Н.* Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре // Казан утлары. 1966. № 11. Б. 141–151.

11. *Исәнбәт Н.* Бөек шагыйрь Фирдәүси // Совет әдәбияты. 1934. № 10. Б. 31–38.

12. *Исәнбәт Н.* Бу шигырьнең шагыйрәсе кем?: XVIII гасыр татар поэзиясе үрнәкләреннән // Казан утлары. 1967. № 1. Б. 147–148.

13. *Исәнбәт Н.* Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында // Казан утлары. 1976. № 4. Б. 128–135.

14. *Исәнбәт Н.* Казан ханлыгы әдәбиятыннан Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы әсәрләре // Совет әдәбияты. 1942. № 9, 10.

15. *Исәнбәт Н.* Тукай дип кулда йөргән кайбер шигырьләр // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 2 кгз.

16. *Исәнбәт Н.* Тукай иҗаты: доклад // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 1946. 21 кгз.

17. *Исәнбәт Н.* Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре // Казан утлары. 1969. № 4. Б. 128–132.

18. *Исәнбәт Н.* Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре // Казан утлары. 1966. 24–126 б.

19. *Исәнбәт Н.* Тукайның прозасы // Совет әдәбияты 1949. № 7. Б. 102–107.

20. *Исәнбәт Н.* Тукайның соңгы басмасы турында // Совет әдәбияты. 1945. № 5. Б. 59–73.

21. *Исәнбәт Н.* Чыгтай һәм аңа карата Тукайның сатиралары // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 8 кгз.

22. *Миңнуллина Ф.* Исәнбәт Нәкый (Закиров Әхмәтнәкый Сираҗетдин улы, 1899–1992) // Габдулла Тукай: Энциклопедия / [баш. ред. З.З. Рәмиев] Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 2016. 294–295 б.

23. Нәкый Исәнбәт / [төз. М. Хәбетдинова]. Казан: Җыен, 2021. 736 с.

24. Нәкый Исәнбәтнең Сәйфи Кудашка язган хатыннан // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 8–20 декабрь, 1972 ел. 16 кгз.

25. Нәкый Исәнбәтнең Җәвад Алмаз туганнарына язган хаты // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 29 май, 1979 ел. 2 кгз.

26. Нәкый Исәнбәтнең Равил иптәшкә язган җаваб хаты // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. 1975 ел. 9 кгз.

27. Нәкый Исәнбәтнең Сәйфи Кудашка язган хатыннан // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. Декабрь. 1980 ел. 2 кгз.

28. *Ногман М.* Татар телендә кульъязма газета-журналлар тарихыннан // Совет әдәбияты. 1958. № 8. 109–115 б.

29. Письмо М. К. Азадовского Ю. М. Соколову от 14 сентября 1926 г // Из истории русской фольклористики. Л. : Наука, Ленинград. отд-ние, 1978. С. 199–274.

30. *Рамеев З. З.* Текстология // Татарская энциклопедия: в 6 т. 5 т. Казань: Институт татарской энциклопедии, 2010. С. 609.

31. *Рамеев З. З.* Текстология татарской литературы начала XX века. Казань: Алма-Лит, 2008. 185 с.

32. *Рәмиев З.* Тукай һәм замандаш әдипләр: «Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә материаллар. Казан: ТаРИХ, 2004. 111 б.

33. Сүз табучы Сукыр Фәррах әңгәмәләре: [Н. Исәнбәтнең «Фәррах җырлары турында» дигән мәкаләсе белән]. Уфа: «Башкнига» һәм Башнаркомпрос нәшере, 1928. 32 б.

34. Татар балалар поэзиясе антологиясе. Казан: Татар. кит. нәшр, 1980. 368 б.

35. *Урманче Ф.* Народный эпос «Идегей». Казань: Фэн, 1999. 200 с.

36. *Усманов М.* О трагедиях эпоса и трагедиях людских // Идегей: татарский народный эпос. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 247–254.

37. Фидакарьлек: [Н. Исәнбәтнең яшь язучылар сорауларына җаваплары] / әңгәмәне Җ. Миңнуллин язып барды // Казан утлары. 1985. № 3. Б. 177–179.

38. *Хабутдинова М. М.* Наки Исанбет – исследователь-текстолог и комментатор // XXXVIII International Symposium International Scientific Symposium “Turkish Peoples: Common Heritage and Values. Andijan / Uzbekistan (29.05.2023). ANKARA. P. 119–121.

39. *Хабутдинова М. М.* Наки Исанбет и Габдулла Тукай // Габдулла Тукай в культурном пространстве XX–XXI вв.: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 135-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Тукая. Казань: ИЯЛИ, 2021. С. 339–342.

40. *Хабутдинова М. М.* Вклад Наки Исанбета в изучение Золотой Орды // Золотоордынское обозрение. 2023. Т. 11, №1. С. 181–201. DOI: 10.22378 /2313-6197.2023-11-1.181-201 EDN: NZKGGK

41. *Хабутдинова М. М.* Из истории первого сводного текста башкирского народного эпоса «Идукай и Мурадым» // Золотоордынское обозрение. 2024. Т. 12, No 4. С. 943–969. DOI: 10.22378/2313-6197.2024-12-4.943-969 EDN: YLGTPW.

42. *Чистов К.В.* Современные проблемы текстологии русского фольклора. М.: [Б. и.], 1963. 45 с.

43. *Юзиев Н. Г.* Әдәбият чыганаклары белеме. Казан: Фән, 1998. 175 б.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Хәбетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты, Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Хабутдинова Милеуша Мухаметзяновна,***
*кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы Института филологии и межкультурной коммуникации, старший научный сотрудник НОЦ стратегических исследований в области родных языков и культур Казанского федерального университета*

*mileuscha@mail.ru*

УДК 355.292.3

*Г.М. Дәүләтшин*

# ФРОНТ ҺӘМ ФӘН ЮЛЫН УЗГАН ГАЛИМНӘР

В статье дается обзор жизни и научной деятельности ученых-фронтовиков, трудившихся после Великой Отечественной войны в ИЯЛИ: Я. Абдуллина, Ш. Абилова, Б. Гиззата, А. Каримуллина, М. Мухарямова, И. Надирова, Г. Юсупова и др. Опираясь на источники разного характера и личные воспоминания, автор описывает боевой путь и военные подвиги своих коллег, воспроизводит их жизненный путь как выдающихся личностей и авторитетных научных деятелей, создает своеобразный коллективный портрет поколения ученых-фронтовиков. Очерчиваются основные направления их деятельности, устанавливается вклад каждого из них в татарскую гуманитарную науку, перечисляются знаковые труды, актуальные для исследователей по сей день.

**Ключевые слова:** ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, Великая Отечественная война, ученые-фронтовики, татарская гуманитарная наука, воспоминания.

The article provides an overview of the life and scientific activities of front-line scientists who worked at the Institute of Language, Literature, and History after the Great Patriotic War: Ya. Abdullin, Sh. Abilov, B. Gizzat, A. Karimullin, I. Nadirov, M. Mukharjamov, Kh. Yusupov and others. Relying on various sources and personal recollections, the author describes the military path and feats of his colleagues, reproduces their life path as outstanding individuals and authoritative scientists and creates a collective portrait of the generation of front-line scholars. The main areas of their activity are outlined and each of them is credited with their contribution to Tatar humanitarian science. The article also lists notable works that are still relevant for researchers today.

**Keywords:** G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and History, Great Patriotic War, front-line scholars, Tatar humanitarian science, memoirs.

*(Дәвамы. Башы журналның 2 нче санында)*

**Илбарис Нурислам улы Надиров** (1925–2009). Танылган фольклорчы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985) Надиров Илбарис Нурисламович 1925 елның 15 апрелендә Әлмәт районының Яңа Нәдер авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач, Ютазы районында Халык хуҗалыгын исәпкә алу оешмасында инспектор булып эшли. Аннан соң комсомол путёвкасы белән Уфаның авиация институтына укырга керә. 1943 елны студент Илбарисны Чкалов өлкәсенең Колтубанка авылына снайперлар мәктәбенә җибәрәләр, аннан яшь егет фронтка китә. Институтның башка сугыш ветераннары кебек үк И. Надиров көндәлек язып бара, шигырьләр иҗат итә. Мәсәлән, снайперлар мәктәбендәге хәлләрне ул болай тасвирлый: «16 январь, 1944. Без укырга тиеш снайперлар мәктәбе тирә-якка унар чакрымга

сузылган кара урман эчендә таралып утырган булып чыкты. Аны лагерь дип йөртәләр. Монда “тимер” тәртипкә, уставка буйсынып яшәргә туры килә. Нормасыз ашарга, приказсыз яшәргә күнеккән авыл малайлары биредә ябыгып беттеләр. Ни өчен дисәң, тамак туймый, көненә сигезәр сәгать занятиедә йөрү, суык кырда окоп казу, “һөҗүмгә” барулар бик ардыра. Шуңа күрә курсантлар столовойда комсызланып ашарга тотыналар, берничә минуттан өстәлдә берни калмый. Җитмәсә, кышы да яман салкын башланды. “Строевая подготовка”, “Тактика” дип аталган занятиеләргә “Заготовка дров” өстәлде. Лагерьга, землянкаларга, кухняга, пекарняга без баштарак өч-дүрт чакрымдагы урманнан җилкәләргә салып утын ташыдык, аннары безне ун-унике чакрымга куа башладылар... Биш минутта киенеп, стройга чыгып басарга кирәк. Соңга калсаң, төнлә идән юарга җибәрәләр. Лагерьда кая карама – соры шинельле солдатлар, кая карама – команда тавышы. Столовойга җыр белән, занятиегә җыр белән, әгәр җырламасаң, көчләп йөгертәләр. Бер чакрым булыр. Монда кино да, музыка да, китаплар да юк. Хәрби белем бирәләр, тик элек алган белемнәрең юкка чыга. Нишлисең, аяусыз сугыш бара, буйсынмыйча булмый...»

И. Надиров 1944 елның августыннан сугыш ахырына кадәр Балтыйк буе фронтында сугыша. Ике тапкыр яралана. Җиңүне радиотелеграфист буларак үзйөрешле артиллерия полкында каршылый. Әмма Ютазы районы Алматы авылында яшәгән ата-аналары янына 1948 елда гына кайтып җитә. Ул 1948–1953 елларда Казан университетының татар филологиясе бүлегендә белем ала. Аны «кызыл диплом» белән тәмамлап, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында «фольклористика» белгечлеге буенча аспирантурада укый. 1956 елдан ул институтта башта фәнни хезмәткәр, аннан гыйльми сәркатиб, директор урынбасары булып эшли. Ә инде 1972–1990 елларда халык иҗаты бүлеген җитәкли. Баштагы чорда бу бүлектә фольклорчылар белән беррәттән сәнгать белгечләре дә эшлиләр. Бүлектә эшчән, дустанә атмосфера хөкем сөрә. Илбарис абый ерак төбәкләргә күп кенә фольклор экспедицияләре оештыра. Тупланган материал Илбарис Нурислам улы җитәкчелегендә төзелгән 12 томлы «Татар халык иҗаты» җыелмасы өчен күп яктан нигез булды.

И. Надиров үз татар фольклоры мәктәбен булдырган Хәмит Ярми җитәкчелегендә «Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты» дигән темага диссертация яклый. Аның 1961 елда «Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышында татар халык поэтик иҗаты» исемле монографиясе дә басылып чыга. Бу хезмәт Бөек Ватан сугышы елларында татар халык иҗаты әсәрләрен җыю, туплау һәм өйрәнү өлкәсендә беренче җитди фәнни адым булды. Шуның белән бергә галим-фронтовик җиңүдә халык иҗаты, аеруча җыр жанрының да зур урын тотканын билгеләп үтәргә теләде.

Матбугатта аның бу темага багышланган бик күп мәкаләләре басылды. Аларда совет чорында татар фольклорының яңа жанрлары

туу, аларның үзенчәлекләре ачып салынды. И. Надировның 1965 елда басылып чыккан «Татар халык җырлары» китабына Татарстанннан читтә яшәгән татарларның әлегә фәндә билгеле булмаган авыз иҗаты әсәрләре дә күпләп кертелгән иде.

И. Надиров төзегән «Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) татар фольклорының алтын фондына керделәр. Исемнәреннән үк күренгәнчә, автор җырларны төрле тематикага бүлеп, татар халкы рухи мәдәниятенең төрле өлкәләре белән аерылгысыз бәйләп өйрәнде. И. Надировның үз сүзләре белән әйткәндә, бездә «халыкның ата-бабадан килгән гореф-гадәтләре, гаилә бәйрәмнәре белән бәйле йола поэзиясе» дә, «күңел ачулар, уеннар, биюләр белән тыгыз үрелештә торучы уен җырлары, бию такмаклары» да, «кеше күңелендәге иң тирән кичерешләрне, хисләр хәрәкәтен энҗе кебек бергә тезеп, шигъри бөтенлектә һәм үзара бәйләнештә чагылдыручы озын лирик җырлар да бар».

И. Надировның биш дистә елга якын сузылган хезмәт юлы турында сөйләгәндә, аның Идел-Урал төбәгендәге автономияле республикаларны һәм өлкәләрне аркылыга-буйга гизеп, халык авызыннан меңләгән җырлар, бәетләр, әкиятләр, мәзәкләр, мәкальләр язып алуын; Мәскәү, Ленинград, Казан, Тбилиси, Ташкент, Кишинёв һ. б. шәһәрләрдә уздырылган бөтенсоюз фольклор киңәшмәләрендә проблемалы докладлар белен катнашуын, фәнни-оештыру эшләренә, яшь белгечләр әзерләүгә зур көч куюын әйтми калу мөмкин түгел. Галим фәнни редакторы булган 13 томлы «Татар халык иҗаты» хезмәте Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. И.Н. Надировның күпкырлы, нәтиҗәле эшчәнлеге тиешенчә бәяләнеп, аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме дә бирелде.

И. Надировның чит илләрдә яшәүче милләтәшләребез белән тыгыз мөнәсәбәт урнаштыру өлкәсендәге эшчәнлеге дә зур игътибарга лаек. Ул, Финляндиягә барып, татар артистлары һәм галимнәренең биредә яшәүче татарлар белән эшлекле очрашуын оештырды. Финляндиядә яшәүче татарларның күренекле шәхесләре турында күпләгән мәкаләләр бастырды. Институтта гына түгел, Казан зыялылары арасында ул зур абруйга ия галим иде.

**Шакирҗан Шиһабетдин улы Абилов** (1915–2004) – татар әдәбияты белгече, текстолог. Ул 1915 елның 31 августында Чиләбе өлкәсенең Коншак районы Яңавыл (Бәгәрәктамак) авылында күп балалы гаиләдә туа. Алтынчы сыйныфны тәмамлагач, Свердловск шәһәре татар-башкорт рабфагында укый. 1934–1938 елларны Шакир Абилов Оренбург педагогика институтының татар филологиясе бүлегендә белем ала. Шакир ага үзе сөйләвенчә, Оренбург пединститутында аларны, үз мөгаллимнәреннән тыш, Казаннан Г. Нигъмәти, М. Майлин, В. Хангильдин, С. Байков, Л. Җәләй, Х. Бәдигый кебек күренекле галимнәр дә килеп укыта. Институтта уку елларында Ш. Абилов берара

«Оренбург коммунисты» газетасында да эшләп ала, биредә үзенең шигырьләрен һәм «Габдулла Тукай һәм халык авыз иҗаты» дигән күләмле мәкаләсен дә бастыра; редакция каршындагы әдәби-иҗат түгәрәгендә актив катнаша; бер еллап өлкә радиосында татарча тапшырулар да алып бара [8]. Институттан соң ул Актаныш мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

Ә 1940 елда Шакир Абиловны армия хезмәтенә алалар. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән (25 июнендә) аны фронтка җибәрәләр. Днепр һәм Дон буйлары, Сталинград, Белоруссия, Варшау, Берлин – болар бар да Шакир ага үткән урыннар. Ул сугышчы һәм офицер, штаб һәм политидарә хезмәткәре дә, хәрби журналист та була. Әүвәл – «Красная Армия», 1944 елдан, Гадел Кутуй, Гариф Галиев, Ибраһим Гази белән берлектә, «Кызыл Армия» исемле фронт газеталарында эшли. Биредә язучы Гадел Кутуй белән очраша. Алар, бергәләп, ике-өч газета чыгаралар. Язучыны соңгы күрүчеләрнең берсе дә Шакир Абилов була. Сталинград операциясе вакытында политрук Ш. Абилов контузияләнә. 1943 елда ул кабат сафка кайта.

Ш. Абилов сугышны Сталинградтан алып Берлинга кадәр уза, орден-медальләр белән бүләкләнә. 6 бертуганының өчесе Бөек Ватан сугышында ятып кала, берсе фин сугышыннан инвалид булып кайта. Ш. Абилов сугыштан соң да хезмәттәшләре-язучылар белән элемтәдә тора.

Майор Ш. Абилов армиядән туган ягы Уралга 1946 елда гына кайта. Дүрт ел Каменец-Уральск шәһәрендәге һөнәри училищеда директор урынбасары вазифасын башкара. 1951–1955 елларда туган районында урта мәктәп директоры, район мәгариф бүлеге мөдире булып эшли. Ниһаять, дөньяның ачысын-төчесен күргән, дүрт балалы, 40 яшьлек Шакир Абилов 1955 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керә һәм 1958–1986 елларда биредә үк эшли дә. Торырга даими урыны, гаиләне карарга һәм туендырырга тиешле мөмкинлекләре булмауга да карамастан, ул әдәбият, фән дөньясына чума, күпләгән чыганакларны, язма истәлекләрне өйрәнеп, күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гали Халит җитәкчелегендә Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр хакында кандидатлык диссертациясен төгәлли һәм аны 1960 елда уңышлы гына яклый. Шакир ага калган тормышын фән дөньясы белән бәйли.

1997 елда шагыйрь әсәрләренең тулы, гыйльми, бер үк вакытта үтемле, популяр да булган яңа бер басмасы дөнья күрде. Биредә Мөхәммәдьяр әсәрләренең (өчесенең дә) тәнкыйди тексты, хәзерге телгә әдәби тәрҗемәләре, гаять бай эчтәлекле кереш мәкалә (6–31 б.), «Аңлатмалар», шагыйрь турында «Библиография» (60 исемдә) урнаштырылган.

Мәгълүм ки, 1997 елның августында ЮНЕСКО карары белән Татарстанда гына түгел, гомумән татар дөньясында Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулу киң күләмдә билгеләп үтелде, төрле чаралар үткәрелде. Шушы уңай белән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт

академия театры бинасында тантаналы кичә булды. Бөек шагыйрь юбилеен әзерләүдә, иҗатын халыкка җиткерүдә башлап йөрүче һәм төп йөкне тартучы фронтовик Шакир ага Абилов булды. Гомумән, ул гомеренең ахырына кадәр Мөхәммәдьярдан аерылмады. Урта гасыр татар әдәбиятының 1999 елда русча нәшер ителгән басмасында, мәсәлән, аның бу шагыйрь турында бик саллы эчтәлекле мәкаләсе бар. Бу мөхтәрәм галимнең күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсендә Мөхәммәдьяр киң катлау укучыларга яхшы таныш, рухи тормышыбызда лаеклы урын алды, аның әсәрләре антологияләргә, дәреслек-хрестоматияләргә кертелде.

Ш. Абилов – борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбиятын өйрәнүче, тел белеме, тарих, археография, текстология, дин белеме буенча белемгә ия булган һәм гарәп, фарсы, төрек телләрен белгән кеше. Ул шулай ук Урта гасырлар әдәбиятын, Харәзми, Мәхмүт Болгари, Хисам Кятиб, Мәүла Колый иҗатын тикшергән, XVII гасыр әдәби-тарихи әсәрләрен өйрәнгән һәм археографик экспедицияләрдә катнашкан.

Ш. Абилов, борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына багышланган 1 нче томның яртысыннан күбрәген әзерләп, татар әдәбиятының күптомлы тарихы авторларының берсе була. Автор аерым язучы-шагыйрьләрдән (Кол Гали, Харәзми, Мәхмүд бине Гали, Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр) тыш, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорын тасвирлаган. Күп кенә яңа табышларны үзенә туплаган хезмәтнең әдәби, мәдәни мохитләргә багышланган бүлекләре дә бик әһәмиятле.

Ш.Ш. Абилов шулай ук әдәби элемтәләргә, аерым алганда, татар әдәбиятының Көнчыгыш классиклары белән үзара бәйләнешенә дә игътибар итте. Аның XIX–XX гасыр әдәбияты буенча тикшеренүләре, шул исәптән Акмулла, Г. Тукай, Г. Кутуй һ. б. иҗатына, тормышына багышланган хезмәтләре бүген дә игътибарга лаек.

**Рашат Габдерәшит улы Гайнанов** (1925–1990) – татар әдәбияты белгече, текстолог.

1925 елның 27 октябрендә Башкортстан АССРның Салават районы Нәсибаш авылында ишле гаиләдә туа. Ул – яшьлекләрен сугыш уты кисеп үткән, сугыштан соңгы ачлык, ялангачлык, җимереклекне күргән буыннан. Мәктәптә үк стена газетасына, аннан район газетасына шигырьләр, мәкаләләр яза башлый. Хыялы – Казан университетының татар бүлегенә укырга керү була. Әмма кулына аттестат алу белән, аны 1943 елда сугышка җибәрәләр. Апасы Мөкатдәсә дә сугышка алына. Икенче гвардия армиясендә яшь сугышчыны башта автоматчы итеп билгелиләр, аннары, яңа җирләргә тиз иярләшүен күреп, разведкага күчерәләр. Донбасс, Амбросиевка станциясе янындагы сугышларда каты яралана. 18 яше дә тулмаган егет сугыштан култык таякларына таянып кайта. Күкрәгендә 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр. Сугыш яралары да төзәлеп җитмәгән Р. Гайнановка туган авылында авыл советы секретаре эшен тапшыралар.

Сугыш беткәч, ул Казан дәүләт университетына укырга керә. Студент чорыннан башлап 1952–1965 елларга кадәр «Совет Татарстаны»,

«Яшь сталинчы», «Азат хатын», «Татарстан коммунисты» газета-журналларында эшли. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Муса Җәлил, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Кәрими, Гадел Кутуй, Нәкый Исәнбәт, Заһидә Бурнашева һ. б. иҗатлары турында фәнни мәкаләләр яза. Рашатны әйдәп баручы әдәбият белгече, зур абруйлы галим Хатип Госман университетка аспирантурага чакыра. Бу дәвердә Фатих Әмирхан иҗатына, тормышына тискәре мөнәсәбәт булуга карамастан, ул классик әдипнең әдәби-эстетик карашларын өйрәнү белән шөгыльләнә. Архивларда эшли, язучының тормышы һәм иҗаты турында күп мәгълүмат туплый, мәкаләләр яза.

1965–1986 елларда Р. Гайнанов СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1986–1990 елларда Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасының фәнни тикшеренү археография лабораториясендә эшли.

Галим үзенең фәнни гомеренең күп өлешен Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүгә, аның әдәби-публицистик мирасын туплауга, шагыйрь иҗатын чагылдырган XX гасыр башы матбугатына җентекле анализ ясауга багышлый. Шулай итеп, ул бөек шагыйрьнең иҗатын махсус өйрәнүгә керешкән башка галимнәрнең фәнни хезмәтләре өчен ныклы системалаштырылган нигез әзерли. Г. Тукайның дүрт (1975–1977) һәм биш (1985–1986) томлы әсәрләр җыентыгы басылып чыга. Аларда Р. Гайнанов әдипнең башка басмаларда булмаган 120 дән артык әсәрен урнаштыра. Җентекле тикшеренүләрдән соң, элекке томнарга кертелгән, әмма Тукайга нисбәтле булмаган әсәрләрне төшереп калдыра.

Томнар хакында фикер алышуда халык шагыйре Сибгат Хәким: «Шатландым һәм әрнедем. Соң булса да табылуына шатландым... Мин инде Тукай өйрәнелеп бетте, иҗаты буенча диссертацияләр язылып бетте, шагыйрь үзенә җитәрлек фән докторлары әзерләде, дип йөри идем. Артык ышанганмын», – дигән иде.

М. Мәһдиевнең Рашат Гайнанов башкарган титаник эшчәнлекне күздә тотып: «Тукайның бу басма томнарын мин арткы яктан укый башладым. Искәрмәләрдән... Никадәр информация, мәгълүмат. Безнең дә китапларны шундый җентекле комментарийлар белән чыгарсалар, һәр язучыга чиксез зур бәхет булыр иде», – дигән сүзләре генә дә бик күп нәрсә турында сөйли. Н. Исәнбәт: «...Рашаттан башка Тукай буенча белемлерәк кешене күрмим бүгенгесе көндә. Системалы итеп эшли белә, аңлашылып тора, җыйган материаллары да бихисап», – дип белдерде.

Ф. Урманчеев: «Һәрбер әсәрнең кайчан һәм нинди шартларда язылуы, беренче тапкыр кайда басылуы, шагыйрьнең кайсы күптомлыгына кертелүе турында искәрмәләр бай мәгълүмат бирәләр. Еш кына алар шагыйрь әсәреннән берничә тапкыр зуррак булып чыгалар», – дип искәртә.

Гомумән, Рашат аганы үзе исән вакытта ук «аяклы энциклопедия» дип йөрткәннәр. Бер кечкенә мәгълүматны фәнни яктан раслау

өчен дә, ул уннарча газета-журналны, архив материалларын, хат-истәлекләрне һ. б. анализлаган.

Р. Гайнанов 30 нчы елларда репрессияләнеп, әле генә акланган күренекле тарихчы һәм язучы Г. Гобәйдуллинның хикәяләр җыентыгын (1958) төзи, шагыйрь Н. Думавиның шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын (1960) текстологик әзерләүдә катнаша (комментарийлар, искәрмәләр яза).

Галим Галимҗан Ибраһимовның күптомлы әсәрләр җыентыгын әзерләүгә зур өлеш кертә. Әдәби, тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләрне үз эченә алган беренче алты том (1974–1986) Р. Гайнанов тарафыннан әзерләнә.

Галим классикларның әсәрләрен төзүнең, искәрмә-аңлатмалар бирүнең иң уңышлы системасын – фәнни концепциясен төзеп калдырды.

Р. Гайнанов Р. Мәрданов һәм Ф. Шәкүров белән авторлыкта, XX гасыр башы вакытлы матбугаты турындагы материаллар нигезендә, «Татар вакыты матбугаты (1905–1924)» дигән библиографик күрсәткеч төзи. Хезмәтнең нигезен Р. Гайнановның студент елларыннан ук туплый башланган «хикмәтле картотекасы» тәшкил итә. Анда 800 гә якын шәхес турында мәгълүмат бар.

Р. Гайнанов XX гасыр башы татар язучылары һәм мәгърифәтчеләренең алфавит белешмәлеге өчен сүзлек төзи (1900–1917). Шушы кульязма сүзлек нигезендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2005 елда Г. Ибраһимовның библиографик сүзлеге басылып чыга.

Галим тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Ул В. Осееваның «Васек Трубачев һәм аның иптәшләре» (1953), М. Твенның «Принц һәм хәерче», К. Станюковичның «Максимка» һ. б. әсәрләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгара.

**Фазыл Салих улы Фәсиев** (1925–2016) 1925 елның 18 октябрендә Азнакай районы Әсәй авылында укытучы гаиләсендә туа. Урта белемне Шөгер урта мәктәбендә ала. 1943 елның гыйнварында армиягә алына, 1943 елның июнендә Житомир хәрби-һава училищесында курсант була. Ф. Фәсиев, 10 нчы гвардия һава-десант бригадасы укчысы, 1944 елның февраленнән 301 нче Кутузов орденлы гвардия укчы полкы, 100 гвардия укчы дивизия укчысы буларак, Карелия фронтындагы һөҗүмдә (1944 елның 20–27 июне) катнаша. Бу сугышта яралана.

1945 елның 8 августында ул, яралануы сәбәпле, армия сафларыннан чыгарыла. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры, күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Ф. Фәсиев – укытучылар династиясен дәвам итүче. Аның нәселе атаклы татар дин белгече, фәлсәфәче, язучы һәм мәгърифәтче Габдерәхим Утыз Имәнинең якын туганнарыннан башлана.

Гаилә-ыру традициясен дәвам итеп, Фазыл Салих улы 1945 елның октябрендә Казан дәүләт университетының тарих-филология

факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы каршындагы аспирантурада белем ала. 1952 елның апреленнән ул – ТАССР радиомәгълүмат комитеты хәбәрчесе; 1952 елның сентябреннән – Казан фельдшер-акушерлык мәктәбендә татар теле укытучысы; 1955 елның сентябреннән – СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән лаборанты; 1956 елның апреленнән – кече фәнни хезмәткәр. 1961 елда «Татар әдәби телендә терминнар ясау ысуллары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Берара, 1964–1965 елларда Ф. Фәсиев Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасында доцент вазифасында эшли. 1965 елның 31 декабреннән ул янәдән Тел, әдәбият һәм тарих институтына кече фәнни хезмәткәр итеп алына. Биредә ул 1968 елдан алып 1986 елга кадәр өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли.

Тюркологиядә Ф. Фәсиев лексикограф буларак та билгеле. Әле фән юлына яңа аяк баскан галимнең 1958 елда «Лексикологический вопросник по сбору слов для толкового словаря татарского языка» (Казан, 1958) дигән китабы дөнья күрә. Бу хезмәт татар теленең бөтен лексик байлыгын бербөтен итеп җыярга мөмкинлек бирә торган итеп төзелгән.

Ф. Фәсиев – «Татар-рус сүзлеге»н төзүчеләрнең берсе (М., 1966) һәм, моннан тыш, сүзлек ахырында «Татар грамматикасы буенча кыскача белешмә»не дә ул язган. Бу калын һәм җентекләп язылган белешмәдә Ф. Фәсиев татар теле грамматик төзелешенең төп үзенчәлекләрен ача, фонетика, графика, морфология һәм синтаксис мәсьәләләре дә читтә калмый. Галим шулай ук татар теленең өч төп (урта, көнбатыш һәм көнчыгыш) диалектына хас үзенчәлекләрне анализлый. Шул ук вакытта теоретик сорауларны да мисаллар белән раслый.

Ф. Фәсиевнең турыдан-туры катнашында «Татар теленең орфографик сузлеге» (1983) әзерләнә, ул берничә тапкыр яңадан басылып чыгып, меңләгән укучыларның өстәл китабына әверелде.

Аның хезмәтләре борынгы язма истәлекләр текстологиясенә, тарихи документлар – Пугачёв хәрәкәте актларына, тарихи ономастика һәм география лексикологиясенә һәм лесикографиясенә, терминологиягә карый.

1969 елда Ф. Фәсиевнең «Основы терминологии татарского языка» монографиясе дөнья күрә. Хезмәт фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан терминологияне өйрәнүдә яңа сүз буларак кабул ителә.

1982 елда галимнең «Старотатарская деловая письменность XVIII века» исемле тагын бер монографиясе дөнья күрә. Биредә Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар сугышының төрле документлары, хатлары һәм өндәмәләре җыелган һәм тирән анализланган. Иске татар телендә язылган бу документларның күбесе автор тарафыннан беренче мәртәбә фәнни әйләнешкә кертелә. Шул ук вакытта документларның текстлары кириллицада заманча транскрипциядә һәм авторның русча тәрҗемәсендә бирелгән. Барлык текстлар, шул исәптән

тәрҗемәләр дә, шәрехләнгән, тәфсилле лингвистик искәрмәләр белән тулыландырылган.

Шулай да киң җәмәгатьчелек күренекле галим Ф. Фәсиевне Кол Галинең иске татар шигъри һәйкәле «Кыйссаи Йосыф» китабы аша белә. Галим поэманың дистәләгән фотокопиясен һәм кулъязма версияләрен җыйган һәм җентекләп өйрәнгән. Алар чагыштыру анализы һәм җыелма кануный текстны булдыру өчен нигез булып хезмәт иткән. Монда автор текстның гарәп шрифтыннан кириллицага транскрипциясен китерә, кереш сүз, искәрмәләр яза, шулай ук поэма исемлеген (160 тан артык кулъязма) тәкъдим итә. Татар теленә тәрҗемә Фазыл аганың хатыны, үзе дә күренекле тюрколог, университет укытучысы Алмазия Хаҗи кызы Нуриева белән берлектә алып барыла. Эшчәнлекнең фәнни нәтиҗәсе буларак XIII йөз татар шагыйренең әсәре дөнья күрә. Бу хезмәтнең басылып чыгуы татар мәдәниятендә зур бер вакыйга булды.

Моннан тыш, ул – татар теле һәм халкының формалашуы һәм үсеше турында тел секторының күмәк җыентыкларында басылган дистәләгән теоретик мәкаләләрнең дә авторы.

Ф. Фәсиев А. Нуриева белән берлектә татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, гимназияләр һәм педучилищелар өчен программалар төзеде.

Галим редактор буларак та билгеле. Аның фәнни редакциясендә 4 томлы «Русско-татарский словарь» (Казан, 1955–1959), Латыйф Җәләйнең «Татар теленең тарихи морфологиясе (Очерклар)» (Казан, 2000) хезмәтләре дөнья күрде.

Фронтовик галим Ф. Фәсиев үзенең хезмәтләре белән татар тел белемен һәм тулаем төрки тел белемен үстерүгә зур өлеш кертте.

**Каюм Сабир улы Сабиров** (1922–1979) 1922 елның 5 ноябрендә ТАССРның Яшел Үзән районы Бишнә авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетына укырга керә. Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтка чакырыла. Аны Саратов өлкәсенә эвакуацияләнгән Киев артиллерия училищесына җибәрәләр. Лейтенант дәрәҗәсен алгач, К. Сабиров 1942 елның кышында Көньяк фронтка юнәлә. Алга таба Дала һәм 2 нче Белоруссия фронтларында сугыша. Тамань ярымутравын, Краснодар, Киев, Варшава шәһәрләрен азат итү һәм Берлинны алу өчен барган сугышларда катнаша. Киевны немец-фашист илбасарларыннан азат иткәндә күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән, ә Варшаваны азат иткән һәм Берлинны алган өчен I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Сугыш тәмамланганнан соң, К. Сабиров югарыда аталган институтта укуын дәвам итә. 1950 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә керә.

1956 елда К. Сабировның «Татар телендә тыныш билгеләре» дигән монографиясе басылып чыга. Хезмәт галимнең диссертация

эшенең нигезен тәшкил итә. 1957 елда «Татар телен пунктуацияләү нигезләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 2017 елда бу хезмәт яңадан басылып чыга. 1963 елда «Татар теленең пунктуация кагыйдәләре» исемле икенче китабы да дөнья күрә. Әлеге хезмәтләрендә автор татар телен пунктуацияләү мәсьәләләрен җентекләп тикшерә.

Галим татар тел белеменең барлык өлкәләрендә дә: пунктуация, лексикология, фонетика, фразеология, морфология, синтаксис һәм татар теле тарихы юнәлешендә нәтиҗәле эшли.

1965 елда басылган «Хәзерге татар әдәби теле» исемле күмәк монографиясендә К. Сабировның «Кереш сүз» һәм «Лексикология» бүлекләре бар. «Татар теленең лекцикологиясе» хезмәте югары уку йортлары өчен татар (1966) һәм рус (1969) телләрендәге «Хәзерге татар әдәби теле» дәреслегенә бүлек буларак кертелгән. Әлеге монография бүген дә үзенең актуальлеген югалтмый.

Галим фәнни эшчәнлеге дәвамында татар тел белеменең төрле аспектларына багышланган дистәләгән фәнни мәкаләләр бастырып чыгарды. Ул шулай ук татар вакытлы матбугаты теленә дә зур игътибар бирде.

К. Сабиров лексикография өлкәсендә дә эшли, сүзлекләр төзүдә дә катнаша. 4 томлы «Рус-татар сүзлеге»нең өченче томы редколлегиясе составында була (Казан, 1958).

1984 елда «Русский язык» нәшриятында басылган «Русско-татарский словарь»да К. Сабиров – күп кенә сүзлек мәкаләләре авторы (М., 1984). Бу сүзлек өч тапкыр яңадан басылып чыкты. Ул өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н редакцияләүдә катнаша (1977–1981).

К. Сабиров талантлы педагог та иде. Берничә ел дәвамында галим Казан педагогика институтында укытты. Ул искиткеч галим генә түгел, ярдәмчел кеше дә, гадәттән тыш шәхес тә иде.

**Рәфкать Бәдретдин улы Яхин** (1908–1983) 1908 елда Арча районы Сеҗе авылында династияле укытучылар гаиләсендә туган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң Р.Б. Яхин Иске Мичән (хәзер Саба районы), Югары Утар башлангыч, җидееллык Яңа Сала мәктәпләрендә укытучы, укыту бүлеге мөдире булып эшли. Эштән аерылмыйча башта Арча педучилищесын (хәзер Г. Тукай исемендәге педагогика көллияте), аннары Казан укытучылар институтын тәмамлый. Татар теле һәм әдәбияты укыта.

Р. Яхин Туган илен немец фашистларыннан саклау өчен 1942 елда Арчадан фронтка китә, рядовой, аннары ефрейтор дәрәҗәсендә Курскидан Берлинга кадәр авыр сугыш юлы уза. Белоруссия өлкәсе үзәге Мозырь шәһәрен, Калинковичи тимер юл узелын, Польша, Германия шәһәрләрен азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. Батырлыклары өчен II һәм III дәрәҗә Дан орденнары, медальләр белән бүләкләнә, командование тарафыннан аңа күпләгән рәхмәтләр җиткерелә. Аларның кайберләрен укып узыйк. Тулырак аңлар өчен,

без аларны документтагыча рус телендә бирәбез: «за героические действия... при прорыве обороны немцев на западном берегу Вислы, южнее Варшавы», «...при переходе границы Германии западнее и северо-западнее города Познани и вторжения в пределы немецкой Померании», «...при развитии успешного наступления и овладение городами Бельгард, Трептов, Грайфенберг, Гюльцов, Штепениту и Массов», «...за завершение окружения Берлина и за овладение городами: Науен, Эльшталь, Рорберг», «...за овладение столицей Германии». Батыр сугышчы Р. Яхинга бирелгән һәм бүгенге көнгә кадәр сакланган бу хатлар – 13. Моннан тыш Р.Б. Яхинга мөнәсәбәтле «...за отличное знание материальной части артиллерии, умелое применение ее в бою, а также за образцовое содержание, уход и сбережение» дигән юллар булган һәм шуның өчен аның «Отличный артиллерист» күкрәк билгесе белән бүләкләнүе дә мәгълүм. Аның тубының номеры да билгеле – 1171. Р. Яхин үзе дошман снарядлары ярчыкларыннан 8 тапкыр яралана.

Яралы Р. Яхин үз профессиясен сагынып кайта. Казанның 12 нче мәктәбендә эшли, аннан соң туган ягындагы Урта Сәрдә җидееллык мәктәбендә укыта. Монда ул «Хезмәттәге батырлыгы өчен» медале белән бүләкләнә.

1959–1968 елларда Рәфкать (документларда да, коллегалары да аның исемен төрлечә: я Рифкать, я Рәфкать дип атыйлар) Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел бүлегендә өлкән лаборант булып эшли. Аның татар теле һәм әдәбияты укытучысы булу тәҗрибәсе монда да бик кирәкле булып чыга. Ул В.Н. Хангильдинның атаклы «Татар теле грамматикасы»н (Казан, 1959) кабат бастыру эшендә катнаша.

Ул коллективта искиткеч тыйнаклыгы белән беррәттән гаҗәеп тырышлыгы, намуслылыгы, игелеклеге белән аерылып тора. Хезмәттәшләренә сокланып, зур хөрмәт белән карый. Ул үзе турында сөйләргә яратмый. «Укыттым, Кызыл армиядә булдым», дию белән чикләнә. Күп нәрсәләрне без аның вафатыннан соң гына белдек. 1985 елның 9 маенда Институттагы «Фикер» стена газетасының Җиңү көненә багышланган санында күренекле текстолог Лена Рашат кызы Гайнанованың рус телендә «Боец Яхин» исемле мәкаләсе чыкты. Үтә тыйнак, күзгә бәрелеп тормаган шәхес турында архив материаллары нигезендә язылган әлеге мәкаләдә өлкән лаборантның данлы, гаҗәеп кеше булуы ачыла. Хезмәттәшләрен бу шаккатырды, күп уйлануларга этәрде. Р. Яхин турындагы бу язма да тулаем Лена Гайнанова мәкаләсенә, киңәшләренә нигезләнеп язылды. Ул Рәфкать Бәдретдин улына кагылышлы документларны, фотоларны безнең Язма мирас үзәгенә тапшырган. Шундый үзенчәлекле, тырыш, үтә тыйнак, шул вакытта батыр кешебезне ачкан өчен аңа зур рәхмәт.

Бөек Ватан сугышы ветераннары белән бергә эшләгән елларга инде 40–50 еллап вакыт үткән. Вакытында алар турында истәлекләремне дә язып бармаганмын. Күп нәрсә хәтердән юылган. Шуңа карамастан, алар, ул вакыттагы яшьрәк буынга – безгә – үзләре

дә сизмичә тырышлык, намуслылык, тыйнаклылык, шул ук вакытта үз-үзеңә ышану тәрбиясе биргәннәр. Ветераннарыбызның бүген берсе дә исән түгел инде. Әмма алар безнең хәтеребездә, омтылышларыбызда әле дә яшиләр.

**Әдәбият**


1. Они вернулись с Победой. Советский район г. Казань. Т. 2. «М» – «Я». Казань: «Книга Памяти», 2019. 376 с.

2. *Гайнанов Р.Р.* Татарская периодическая печать начала XX века = XX йөз башы татар вакытлы матбугаты: Библиогр. указ. / Р.Р. Гайнанов, Р.Ф. Марданов, Ф.Н. Шакуров. Казань: Милли китап, 2000. 315, [1] с. : табл. (Серия «Сотрудничество» / Каз. гос. ун-т. Каф. истории тат. народа, Нац. б-ка Респ. Татарстан. Отд. рукописей и ред. кн.)

3. *Галимуллин Ф.* Исән калуы – әдәбият бәхетенә // Казан утлары. 2016. № 6. Б. 139–143.

4. *Госманов М.Г.* Беренче редакторым: [әдәбият галиме Рашат Гайнанов турында] // Казан утлары. 2006. – № 4. Б. 139–148.

5. *Исламов. Р.Ф.* Тукай текстологы – Рашат Гайнанов // Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 191 б.

6. *Исламов Р.Ф.* Тукайга, Ибраһимовка... Яңа томнар өстәгән галим // Кызыл таң. 1998. 28 авг.

7. *Мәхмүтов Х.* Җырга гашыйк галим // Казан утлары. 1985. № 4. Б. 184–185.

8. *Миңнегулов Х.* Мөхәммәдьярларга тиң шәхес // Безнең мирас. 2023. № 5.

9. *Тарханова Г.* Галим хезмәте нәрсә белән үлчәнә? Әдәбият галиме, текстолог Рашат Гайнановның тууына 86 ел (1925–2011) тулуга багышлана. [Электрон ресурс]. URL: http://www.tarkhanova.ru/node/389 (мөрәҗәгать итү көне: 15.07.2025).

10. Татар вакытлы матбугаты (1905–1924). Библиографик күрсәткеч / Р.Р. Гайнанов, Р.Ф. Мәрданов, Ф.Н. Шәкүров. Казан: Рухият, 1999. 311 б.

11. Сохраняя традиции, думая о будущем. История ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова в лицах. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2024. С. 123–124.

12. *Урманчеев Ф.* Кадерлерәк була бара // Казан утлары. 1987. № 4. Б. 161–165.



***Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (Казан)*

***Давлетшин Гамирзян Миргазянович,***
*доктор исторических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан (Казань)*
*g.davletshah@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Л.Ш. Галиева***

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫНДА КАЗАНДАГЫ ӘДӘБИ ТОРМЫШ

Данная статья является кратким обзором литературной жизни Казани в годы Великой Отечественной войны. Основная ее цель заключается в обобщении имеющихся фактов по истории татарской литературы военного периода на основе опубликованных источников и представления их в хронологическом порядке. Для передачи общей картины рассматриваемого периода, автор статьи первоначально обращается к литературным событиям начала 40-х гг. XX столетия. Именно они помогают более точно передать довоенную литературную жизнь Казани. Наиболее значимые явления в литературной жизни города в годы войны были зафиксированы в пятом томе «Истории татарской литературы» в шести томах, в летописи истории татарской советской литературы «Әдәбият баскычлары» («Ступени литературы»), в книгах, написанных по поводу юбилеев Татарского книжного издательства, Союза писателей Республики Татарстан и Института языка, литературы и истории. Отличительной особенностью статьи является сопоставление конкретных литературных фактов с воспоминаниями и письмами писателей, творческих деятелей, что придает исследованию некую новизну. Восстановление хронологии литературной жизни города подобным образом позволяет более полно и ярко представить деятельность писателей-тыловиков, те условия, в которых им приходилось заниматься творческой, издательской, редакторской деятельностью, запечатлеть достижения и потери татарской литературы и литературоведения в годы войны.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, Великая Отечественная война, литературная жизнь, Муса Джалиль, Гази Кашшаф, журнал «Совет әдәбияты», Дом печати, Союз писателей Татарстана, Татарское книжное издательство.

This article is a brief overview of the literary life of Kazan during the Great Patriotic War. Its main goal is to summarize the available facts on the history of Tatar literature during the war period based on published sources and present them in chronological order. To convey the general picture of the period under consideration, the author of the article initially turns to the literary events of the early 1940s. They help to more accurately convey the pre-war literary life of Kazan. The most significant events in the literary life of the city during the war were recorded in the fifth volume of the “History of Tatar Literature” in six volumes, in the chronicle of the history of Tatar Soviet literature “Adabiyat ba skychlary” (“Steps of Literature”), in books written on the occasion of the anniversaries of the Tatar Book Publishing House, the Union of Writers of the Republic of Tatarstan and the Institute of Language, Literature and History. A distinctive feature of the article is the comparison of specific literary facts with the memoirs and letters of writers and creative figures, which gives the study a certain novelty. Restoring the chronology of the literary life of the city in this way allows us to more fully and vividly present the activities of writers-home frontiersmen, the conditions in which they had to engage in creative, publishing, editorial

activities, to capture the achievements and losses of Tatar literature and literary criticism during the war.

**Keywords:** history of Tatar literature, Great Patriotic War, literary life, Musa Jalil, Gazi Kashshaf, magazine “Sovet adabiyaty”, House of Printing, Union of Writers of Tatarstan, Tatar Book Publishing House.

Татар әдәбияты тарихында Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятын күзаллау өчен иң элек XX гасырның 40 нчы еллары башында Казандагы әдәби тормыш вакыйгаларын барлау сорала. Әлеге чор әдәби хәрәкәте алты томда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенең бишенче томында (Н. Гыйззәтуллинның «Әдәби хәрәкәт» мәкаләсе) [5], «Әдәбият баскычлары» дип исемләнгән татар совет әдәбияты елъязмасында [1], язучы Равил Фәйзуллин тарафыннан Татарстан Язучылар берлеге турында чыгарылган китапта [20], «Матбугат йорты – гомер китабы: истәлек-хатирәләр» җыентыгында [13], Татарстан китап нәшриятының 100 еллыгы уңаеннан басылып чыккан хезмәттә [17], кайбер мәсьәләләр аерым авторларның язмаларында карала. Мәкалә кысаларында билгеле фактларны бер тәртиптә урнаштырып, Бөек Ватан сугышы чорында Казандагы әдәби тормышка кыскача күзәтү ясау максат итеп куелды.

Бер яктан, Бөек Ватан сугышына кадәрге еллар татар әдәбияты тарихы өчен мөһим вакыйгаларга бай була. 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Идегәй» дастаны бастырыла. Шул ук журналда 1941 елда Мөхәммәт Галинең «Өмми Камал китабы», Нәкый Исәнбәтнең «Казан ханлыгы чорыннан Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы» дип исемләнгән мәкаләләре дөнья күрә. Ягъни Урта гасырлар әдәбиятын өйрәнү буенча ныклы адымнар ясала.

1940 елның 26 августындагы Политбюро карары нигезендә 1941 елның август аенда Мәскәүдә Татар сәнгате декадасы үтәргә тиеш була. Иҗади җәмәгатьчелекнең күп өлеше нәкъ шул чарага әзерлек эшендә катнаша. Сугыш башлану сәбәпле декада уздырылмый кала. 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасыннан соң, Г. Кашшаф шундый истәлеге белән уртаклаша: «Безнең декаданың тарихы озын. Беренче тапкыр декадага әзерләнә башлаганда, Вил Ганиев, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Рафаил Төхфәтуллин кебек яшьләрне берни дә борчымаган да, дулкынландырмаган да. Алар әле ул вакытта «Такташ абый»ларының шигырьләрен ятлап, колхоз авылының инеш буйларында каз куып йөргән малайлар. ...Әйе, 1941 елда, декадага әзерләнеп йөргәндә, безнең арабызда Гадел Кутуй, Нур Баян, Абдулла Алиш, Муса Җәлил кебек тынгысыз, ярсу йөрәкле иптәшләребез бар иде. Ул вакытта Муса белән Кутуй нинди дәрт белән, нинди ашкыну белән әле Язучылар союзында, әле сәнгать эшләре идарәсендә, әле редакцияләрдә, әле театрларда эшләп йөриләр иде, һәрнәрсәгә аларның кулы житә, һәр эшкә алар өлгерәләр иде» [11: 72]. 1941 елда узасы декадада Мәскәү тамашачысына М. Җәлил поэмасы нигезендә композитор Н. Җиһанов тарафыннан

иҗат ителгән «Алтынчәч» операсын күрсәтү планлаштырыла. Р. Ишморатның 1957 елда үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы кысаларында сәхнәгә куелган «Үлемсез җыр» героик драмасында М. Җәлил иленә герой-шагыйрь буларак әйләнеп кайта.

Шулар белән бергә, әлеге елларда татар дөньясында репрессияләр шаукымы үзен шактый сиздерә әле. 1938 елдан Ф. Кәрим төрмә газабы кичерә. 1940 елның 27 февралендә суд Гали Рәхимне 8 елга лагерьга җибәрергә хөкем итә. 1940 елның 24 августында Ф. Бурнашны алып китәләр. 1940 елның 18 ноябрендә Х. Туфан кулга алына һәм сөргенгә сөрелә.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк татар шагыйрьләре матбугат битләрендә дошманга каршы торырга чакырган шигырьләрен бастыра башлыйлар. Мисал өчен, 1941 елның 24 июнендә «Кызыл Татарстан» газетасында К. Нәҗминең «Фашизмга үлем», Г. Кутуйның «Коммунизм өчен», С. Батталның «Хаклык бездә! Җиңү безнеке!», Ә. Фәйзинең «Һәркем үзенең көчен барласын!» исемле шигырьләре дөнья күрә. 28 июньдә Язучылар берлеге эшчәнлеген хәрби вазгыятькә яраклаштыру турында мәсьәлә күтәрелә: «Моннан соң Союзның бөтен эшчәнлеге дошманны тар-мар итүгә юнәлтелгән булырга тиеш» [1: 207]. 3 июль көнне Татарстан язучыларының гомуми җыелышы уза, анда түбәндәге карарлар кабул ителә: «1) Язучыларның ПВХО төркемен оештырырга, беренче занятиене 6 июльдә үткәрергә; 2) 5 июльдә язучыларның Тукай исемендәге кабинетында сугышка һәм фашизмга каршы җырлар һәм патриотик музыка тыңлау уздырырга; 3) якын араларда фашизмга каршы кичә оештырырга» [1: 207–208]. «Совет әдәбияты» журналының август ае санында язучылар тарафыннан хикәяләрдән, шигырьләрдән торган «Ватан өчен» дигән җыентыкның әзерләнүе һәм нәшриятка тапшырылуы, язучыларның оборона фондына акча, җылы киемнәр җыюы, Язучылар берлеге каршында агитация һәм пропаганда бүлеге оештырылу турында хәбәр ителә [3: 95]. Аның әгъзалары булып Ш. Маннур, Т. Гыйззәт, Р. Ишморат һәм Г. Кутуй сайлана.

Билгеге булганча, сугышта 124 татар язучысы катнаша, шуларның 34 е сугыш кырында ятып кала [18: 6]. Тарихчы А. Кәбирова язганча, сугышның беренче елында Язучылар берлегендә торган 53 язучыдан 25 кеше фронтка китә [9: 396]. Алар арасында М. Җәлил, А. Алиш, Г. Кутуй һәм башкалар кебек шактый танылган язучылар да була. Шунысы аяныч: сугышның беренче елларында сугышка киткән язучылар фронтка язучы статусында китми, гади солдат булып алына. Тарихчы-галимә язганча, моның сәбәбе – илдә милли интеллигенция вәкилләрен саклап калу механизмы булмау. Бу факт М. Җәлилнең Г. Кашшафка язган хатында теркәлеп калган: «...Ты пиши мне такие теплые, дружеские “рекомендательные” письма. Я хочу приносить пользу и своим поэтическим пером. Ты, может быть, кроме писем, пришлешь мне и справку о том, что я писатель, член ССП (а то у меня нет никаких таких документов)» [15: 19]. Бары тик 1942 елда «Мат-

бугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары турында» карар кабул ителгәннән соң гына, фронтларда милли телләрдә хәрби газеталар чыгарыла башлый, татар язучыларының күбесе әлеге басмаларга корреспондент булып китә [5: 14].

Бөек Ватан сугышы чорында Казандагы әдәби тормыш Бауман урамында урнашкан Матбугат йорты белән тыгыз бәйләнгән. Сугыш елларында биредә Татгосиздат, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы, республикадагы иң зур китап кибете, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе, «Совет әдәбияты» журналы редакциясе урнаша. Сугыш башланган елны Тукай клубында Мәскәүдән эвакуацияләнгән язучылар туктала. Биредә 1941 елның көзендә А. Толстой, 1942 елда А. Фадеев чыгыш ясый. Татар язучыларының күбесен фронтка нәкъ менә Тукай клубыннан озаталар. М. Җәлилнең фронтка китүенә бәйле кичәне композитор Җәүдәт Фәйзи болай дип искә төшерә: «Кичә күңелле үтте. Күп речьлар сөйләнде. Рус шагыйре Алексей Сурков белән тәрҗемәче Семён Липкин Мусага батырлыклар теләделәр... Шунысы истә: үзенең чыгышында ул үзен иң элек гражданин-коммунист, аннан соң гына шагыйрь диде, өлкән политрук буларак, Ватанына тугры хезмәт итәчәген белдерде һәм җиңү безнең якта булачагына шикләнүсез ышануын әйтте. Вакыт бик соң иде. Күп иптәшләр Муса белән саубуллашып, аңар исәнлек теләп таралыштылар. Муса мине үз яныннан җибәрми. Берничә генә кеше калдык. Эстрадада рояль янында утырабыз. Ул минем уйнавымны сорады. Һаман шул “Ташкыннар” драмасына язылган Гайнавал җырын уйната. Үзе җыр башлый, башкалар кушыла:

Телеграм баганасын
Олы юлга кем куйган?
Китәсем килеп китмәдем,
Туган илдән кем туйган?

Без иртән сәгать дүртләрдә генә таралыштык» [19: 79].

Тукай клубында фронттан кайткан язучылар белән очрашулар да оештырыла. 1943 елның март-апрель айларында фронттан Ф. Кәрим, М. Максуд һәм Х. Госман кайтып китәләр. Әлеге очрашуда Ф. Кәрим «Разведчик язмалары» әсәрен, Х. Госман үз повестеннән өзекләр, М. Максуд шигырьләрен укый. Бу хакта мәгълүмат «Кызыл Татарстан» газетасының 4 апрель санында җиткерелә [21].

Тукай клубында шулай ук юбилей кичәләре һәм язучыларның гомуми җыелышлары үткәрелә. Биредә М. Лермонтов, М. Горький һ. б. танылган язучыларның (1942 елда – Г. Тукай, 1943 елда – Г. Камал) кичәләре оештырыла.

Җыелышларның берсендә, 1944 елның февраль аенда, өлкә комитеты сәркатибе сугыш чорында язучыларның бурычлары һәм Г. Кашшаф «Сугыш чорында татар әдәбияты» дигән темаларга чыгыш ясыйлар. Г. Кашшаф истәлегеннән: «Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты

“Совет әдәбияты” журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби хезмәткәр штаты кыскартылды. Ул чакта журнални Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы аны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде. Бөтен эш Абдулла Гомәр җилкәсенә авып калды. 1942 елда Гомәр Бәшировны мин алыштырдым. Гомәр Бәширов Татарстан радиосының баш мөхәррире итеп билгеләнде. Журналда хәл авырлыгына котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле Матбугат йорты ягылмый иде. Менә без Абдулла Гомәр белән икәү “Совет әдәбияты” журналының нәүбәттәге санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын үзәккә үтә. Һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда урамда җылырак шикелле тоела безгә...» [12: 154–155].

Сугыш сузылган саен, кыенлыклар арта гына бара. Типографиядәге авырлыклар, кәгазь кытлыгы, бастырасы материалларның азлыгы, хезмәткәрләр саны кыскару... Шулар өстенә «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире Г. Кашшаф 1943 елның октябрендә Язучылар оешмасының җитәкчесе итеп сайлана. 1943 елның җәендә журналның типографиядә җыелмыйча яткан саннары җидегә җитә. Фронттан исә журналны сорап хатлар килеп кенә тора. Фронтовик язучылар Казанның бик әкрен кыймылдавы, журнал саннарының килеп җитмәве турында хатлар юллыйлар. Ниһаять, 1943 елда бер төркем язучылар Мәскәүдә А. Фадеев белән очрашканнан соң гына, хәлләр уңай якка үзгәрә. Шуннан соң журналның тиражы 3 мәртәбә арттырыла [12: 155].

Сугыш еллары татар вакытлы матбугатына да сизелерлек йогынты ясый, күп кенә басмалар чыгудан туктый. Мисал өчен, «Совет мәктәбе» журналы (бүгенге көндә «Мәгариф») 1941–1948 елларда басылмый. Шагыйрь М. Җәлил оештырып җибәргән «Кечкенә иптәшләр» (1924–1928 елларда «Кечкенә иптәшләр», 1928–1932 елларда «Октябрь баласы», 1933–1941 елларда «Пионер каләме», бүгенге көндә «Ялкын» журналы) 1941–1950 елларда чыкмый. Бүген «Татарстан яшьләре» буларак билгеле «Яшь сталинчы» газетасы 1942 елның мартында чыгудан туктап, 1949 елның август аенда гына кабат тергезелә. «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы 1941–1957 елларда басылмый. «Ватаным Татарстан» (совет чорында «Кызыл Татарстан, «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» исеме белән басылып килгән) газетасы хезмәткәре Мәрьям Дибаева болай дип искә төшерә: «...һич уйламаганда, көтмәгәндә илебезгә сугыш арбасы дөбердәп килеп керде. Матбугат йорты үзендә эшләүче ир-егетләрне күпләп-күпләп фронтка озата башлады. Балалар һәм яшьләр газеталары, “Совет әдәбияты”ннан башка барлык журналлар чыгудан туктады. Матбугат йорты бөтенләй бушап калгандай булды. Ябылган редакцияләрдән күчкән башка иптәшләр белән бергә мин дә “Кызыл Татарстан”да эшли башладым» [6: 93]. М. Дибаева эшләгән «Яшь ленинчы» газетасы (хәзерге «Сабантуй» журналы) 1941 елдан

алып 1960 елга кадәр «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә «Пионер бите» дип исемләнгән сәхифә буларак тәкъдим ителә.

«Совет әдәбияты» журналы – авыр сугыш елларында да чыгудан туктамаган басмаларның берсе. Бу, күпмедер дәрәҗәдә, редакция, Г. Кашшаф эшчәнлекләре белән дә бәйле. Р. Фәйзуллин юкка гына аны сугыш чорында иң төп фигураларның берсе дип атамый [20: 35]. Күп кенә фронтовик язучылар нәкъ менә аның белән хат алыша. М. Җәлил исә аңа васыятен җибәрә. Язучы А. Шамовның кызы Әлфия Шамова тарафыннан сугышта катнашкан язучыларның фронт хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре тупланган җыентыкта 500 дән артык хатның 100 дән артыгы Гази Кашшафка адресланган [15]. Бу хатларда, беренче чиратта, фронтовик язучылар, үз гаиләләрен, иҗатларын кайгыртып, берлек җитәкчесенә, «Совет әдәбияты» журналы мөхәрриренә мөрәҗәгать итәләр. Шул ук вакытта алар фронтта чыга торган газеталарга бастыру өчен материал сорап та хатлар юллыйлар. Билгеле булганча, фронтларда 16 исемдә татарча газета бастырыла («Ватан өчен», «Алга, дошман өстенә», «Сталин байрагы», «Кызыл сугышчы» һ. б.) [23: 137–150]. Аларны чыгаруда даими хәрби хезмәттәге яисә командировкага килгән язучылар, журналистлар катнаша: Г. Бәширов, М. Әмир, Ш. Маннур, А. Шамов, Р. Ишморат һ. б.

Сугыш елларында әдәбият фәне, милли мәгариф үсешендә дә уңай күренешләр күзәтелә. 1943 елда Казан дәүләт университетында Маһинур Гайнулла кызы Фәйзуллина татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып «Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның буржуаз-демократик революция елларында иҗат эшчәнлеге» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый [10: 93]. Ул сугышка кадәр үк М. Җәлил белән таныш була, шагыйрь иҗатына багышлап, «Совет әдәбияты» журналында мәкалә бастыра.

«1944 елның 1 июненнән В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачылу турындагы приказ чыга һәм аңа 4 штат бирелә» [8: 52]. Биредәге беренче мөгаллимнәр арасында Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре дә бар. Әлеге бүлекнең мөдире итеп филология фәннәре кандидаты, доцент Рабига Афзал кызы Хәкимова билгеләнә. «Кафедрада Рабига Афзаловна оештыру һәм методик эшләрне, уку планнарын һәм программалар төзүне, фәнни хезмәткәрләр туплауны, студентлар кабул итүне, тәрбия эшләрен алып бара. Үзе немец, рус, башкорт һәм татар телләрен яхшы белә. Шулай ук казах, кыргыз телләрендә дә аралаша ала. Конференцияләрдә югары дәрәҗәдә фәнни чыгышлар ясый» [2: 135].

Татар әдәбиятын фәнни нигездә өйрәнү юнәлешендә Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән галимнәрне дә санап узарга мөмкин. Билгеле булганча, сугыш елларында «Идегәй» дастанын, татар халкының Урта гасырлар тарихын, әдәбиятын өйрәнү активлаша. Бу уңайдан Х. Ярми эшчәнлеге аерылып тора. Кызганычка

каршы, 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты чыгарган «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карар нигезендә бу өлкәдәге эзләнүләр туктатыла.

Сугыш чорында Институтның әдәбият белеме бүлегендә берничә генә галим була [14: 65]. 1942 елда Я. Агишев «Габдулла Тукай – патриот» дигән хезмәтен бастыра. Институт галимнәре сугыш чоры әдәбияты буенча гомуми хезмәтләр, шул чорда бастырылган китапларга, әсәрләргә рецензияләр язу эшенә дә тартыла. Г. Тукай иҗатын өйрәнү юлында да сугыш елларында мөһим адымнар ясала. 1943 елда Я. Агишев белән Х. Хисмәтуллин тарафыннан шагыйрь әсәрләренең 1 нче томы бастырыла. 1943 елның башында Х. Ярми, Г. Кашшаф һәм К. Нәҗми фронтовик татарларга Сәлам хаты язалар.

Сугыш елларында Х. Ярми урынына Институт директоры итеп М. Гайнуллин билгеләнә. Әлеге галимнең хезмәтләре бүгенгәчә актуаль булып кала. Ул сугыш елларында басылып чыккан «Максим Горький и татарская литература» дигән кечкенә генә брошюрасында, язучының исемен атамый гына, Г. Исхакый хатын урнаштыра. Аның шулай ук К. Насыйрига багышланган хезмәтләре дә дөнья күрә.

М. Гайнуллин 1942–1944 елларда Татгосиздатны (Татарстан китап нәшриятын) җитәкли. 1944 елдан башлап әлеге вазифа З. Тинчурингa йөкләнә. Нәшрият ветераны Л. Хәмидуллин язганча: «Сугыш башланганда, биредә 100 ләп кеше эшләгән. Редактор, корректор һәм исәп-хисап хезмәткәрләренең күпчелеген, әлбәттә, хатын-кызлар тәшкил иткән. Ватан сугышы башлангач, китап нәшриятыннан фронтка 30 лап ир-ат һәм берничә хатын-кыз алына. 16 кеше, шул исәптән 1940–1942 еллар аралыгында нәшрият җитәкчесе булган Шакир Арсланов яу кырында ятып кала» [22: 49]. Шул чорда нәшриятта билгеле булган шәхесләрдән Г. Кашшаф, А. Гомәров, Ә. Камал, С. Фәйзуллин, А. Хөсәенова – редактор, Б. Әлминев китап бизәүче рәссам булып эшли.

Шартлар авыр булуга карамастан, сугыш вакытында нәшриятта китап бастыру тукталмый. Бу елларда 220 исемдә китап дөнья күрә, аларның гомуми тиражы 1,5 млн данәгә җитә [9: 397]. Арада, агитация һәм пропаганда юнәлешендә чыгарылган китаплардан тыш, Ш. Мөдәрриснең «Фронтовик татарлар», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» «Идегәй», М. Җәлилнең «Алтынчәч», «Илдар», Н. Баянның «Карахмәт», «Туган авыл», С. Батталның «Сынау», Ф. Кәримнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт», «Язгы төндә», К. Нәҗминең «Фәридә» китаплары, Ә. Ерикәй, Н. Дәүлинең шигырь җыентыклары, Г. Камал альбомы һ. б. басмалар бар [16: 206–221].

1940 елда Казанда М. Горький музее ачыла. Һәм ул Бөек Ватан сугышы чоры әдәби тормышында әһәмиятле урын алып тора. 1943 елдан биредә Г. Тукайга багышланган күргәзмә эшли башлый. 1944 елда Казанда Әдәби музей һәм Ш. Камалның Музей-квартирасын ачу турында карар кабул ителә [4: 155].

Шул рәвешле, Бөек Ватан сугышы елларында да Казанда әдәби тормыш тукталып тормый. Язучылар арасында шактый зур югалтулар булса дә, иҗат эше дәвам итә. Сугыш чорында каһарман язучыларыбызның яу кырындагы батырлыгы, М. Җәлилнең тоткынлыкта язылган «Моабит дәфтәрләре», Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун», «Разведчик язмалары», Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары», «сугыш яки тыл вакыйгаларын түгел, бәлки аларның кеше күңелендә чагылышын сурәтләү объекты ясаган, аерым кеше өчен фаҗига булуын үзәккә алган» [7: 61]. Ә. Еникинең «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» һәм шул чорда язылган күп кенә башка әсәрләр татар әдәбияты сынауларга бирешми алга таба атларга тиеш, дигән фикерне куәтли.

**Әдәбият**

1. Әдәбият баскычлары: татар совет әдәбияты елъязмасы (1917–1973). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 476 б.

2. *Баһаветдинова Х.З.* Галимә Хәкимова Рабига Афзаловна: тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Историческая этнология. 2021. Т. 6, № 1. С. 132–140.

3. Бөек һәм изге Ватан сугышы һәм Татарстан язучылары // Совет әдәбияты. 1941. № 8. Б. 95.

4. *Гаврилова М.Ф.* Роль Казанского музея А.М. Горького в деле сохранения литературного наследия Татарстана // Вестник Кемеровского государственного университета культуры и искусств. 2019. № 46. С. 152–158.

5. *Гыйззәтуллин Н.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 5 т.: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 11–36.

6. *Дибаева М.* Үзе бер һәйкәл / Матбугат йорты – гомер китабы: истәлек-хатирәләр. Казан: Мәгариф, 2006. Б. 92–94.

7. *Заһидуллина Д.Ф.* Әмирхан Еники прозасы: поэтик ачышлар // Фәнни Татарстан. 2024. № 4. Б. 60–64.

8. *Кабирова А.Ш.* Татарская АССР – важная тыловая база СССР // История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. Казань: Институт истории АН РТ, 2013. С. 388–398.

9. *Йосыпова Н.М.* Казан университетында татар әдәбият белеме: тарихы һәм бүгенгесе // TATARICA. 2024. № 23(2). Б. 41–60.

10. *Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш.А.* Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год. Казань: Фикер, 2000. 160 с.

11. *Кашшаф Г.* Беренче тәэсирләр, беренче йомгаклар... // Совет әдәбияты. 1957. № 7. Б. 72–74.

12. *Кашшаф Г.* Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. Б. 139–158.

13. Матбугат йорты – гомер китабы: истәлек-хатирәләр. Казан: Мәгариф, 2006. 271 б.

14. 50 лет поисков и открытий. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 240 с.

15. Сугыш уты белән өтелгән язмышлар. Фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы. Казан: Ихлас, 2014. 623 б.

16. Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт.: Р.Ф. Мәрданов, И.Г. Һадиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 504 б.

17. Татарстан китап нәшрияты. 100 ел: тарих сәхифәләреннән. Шәхесләр, истәлекләр. Казан: Татар. кит., нәшр., 2019. 170 б.

18. Татарстанның фронтовик язучылары / төз.: Ш. Мостафин, Ә. Мушинский. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 367 б.

19. *Фәйзи Җ.* Онытылмас хатирәләр // Муса Җәлил турында истәлекләр / Төз. Р.Ә. Мостафин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 74–79.

20. *Фәйзуллин Р.* Татарстан Язучылар берлеге (Әдипләр берлеге): публицистик уйланулар, тарихи фактлар, хатирә-күзәтүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 223 б.

21. Фронтовик язучыларның яңа әсәрләре // Кызыл Татарстан. 1943. 4 апр.

22. *Хәмидуллин Л.* Мылтык һәм каләм берлеге // Татарстан китап нәшрияты. 100 ел: тарих сәхифәләреннән. Шәхесләр, истәлекләр. Казан: Татар. кит., нәшр., 2019. Б. 48–50.

23. *Шамова Ә.* Газета битләрендә фронт сәхифәләре // Казан утлары. 2005. № 5. Б. 137–150.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Галиева Лейсан Шаукатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*nisanbedri@mail.ru*

УДК 373.2 (075.32)

*Ә.Г. Төхфәтуллина*

# МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАЛАРЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

В статье рассматривается история развития дошкольных образовательных программ. Региональные дошкольные образовательные программы возникли не на пустом месте. Современные программы развития речи имеют свою историю становления. Истоки этих программ восходят к первым документам детских садов, разработанным в послереволюционный период. Содержание и структура программ формировались постепенно. По мере развития педагогической науки и практики в них появлялись новые задачи, уточнялись и расширялись объемы речевых умений и навыков, а также совершенствовалась общая структура.

По мере накопления научных исследований и практического опыта вносились изменения и дополнения в структуру программ. Так, увеличивался спектр упражнений и видов работ, направленных на комплексное развитие речевой активности ребенка.

Современные программы предусматривают различные формы взаимодействия взрослого и ребенка, способствующие эффективному решению задач развития речи.

В итоге сформировалась целостная система дошкольного образования, направленная на гармоничное развитие ребенка, обеспечение преемственности дошкольного и начального школьного звеньев. Таким образом, современные региональные дошкольные образовательные программы представляют собой итог длительной эволюции, включившей в себя лучшие достижения прошлого и актуальные инновации настоящего.

**Ключевые слова:** программа, развитие речи, педагоги, дошкольное образование, дошкольники, воспитатели, задачи, методы, принципы, речь.

The article considers the issue of the history of preschool educational programs. Regional preschool educational programs did not appear out of nowhere. Modern speech development programs have their own history of formation. The origins of these programs go back to the first documents of kindergartens developed in the post-revolutionary period. The content and structure of the programs were formed gradually.

As pedagogical science and practice developed, new tasks appeared in them, the scope of speech skills and abilities was clarified and expanded, and the general structure was improved. As scientific research and practical experience accumulated, changes and additions were made to the structure of the programs. Thus, the range of exercises and types of work aimed at the comprehensive development of the child's speech activity increased. Modern programs provide for various forms of interaction between an adult and a child, contributing to the effective solution of speech development problems.

As a result, an integrated system of preschool education was formed, aimed at the harmonious development of the child, ensuring the continuity of the preschool and primary school levels. Thus, modern regional preschool educational programs are

the result of a long evolution, which included the best achievements of the past and current innovations of the present.

**Keywords:** program, speech development, teachers, preschool education, preschoolers, educators, tasks, methods, principles, speech.

Сөйләм үстерү бурычлары, сөйләм күнекмәләре һәм осталыгы, төрле яшь төркемнәрендәге балалар сөйләменә таләпләрне билгеләүче программалар аша тормышка ашырыла.

Хәзергә көндә гамәлдә булган «Туган телдә сөйләм үстерү программалары»ның тарихы еракларга барып тоташа [18]. Октябрь революциясеннән соң илдәге кискен борылышлар мәгариф өлкәсенә дә зур йогынты ясый. Бердән, белем бирү тулысынча дәүләт карамагына күчерелеп, аның максаты, бурычлары һәм эчтәлеге тамырдан үзгәрсә, икенчедән, структур яктан үзгәрешләр дә кертелә, мәгариф челтәрендә мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү тармагы барлыкка килә [7].

Мәктәпкәчә тәрбия йортлары оешуның беренче елларында тәрбия буенча бердәм система, расланган бердәм юнәлеш булмый. Яңа төр тәрбия оешмалары челтәре барлыкка килгәч, педагоглар алдына әлеге оешмаларның төп максатларын билгеләү, төрләрен ачыклау, һәрбер төрнең тормышка ашыру юлларын һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча методик кулланмалар белән тәэмин итү зарурлыгы килеп баса. Октябрь революциясенең беренче елларында мәктәпкәчә яштәге балалар өчен татар педагоглары тарафыннан татар халкының гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүрешен күз алдында тотып язылган методик һәм педагогик кулланмалар төзелә. Әлеге хезмәтләр уен барышында баланың сөйләм телен үстерүгә, физик һәм хезмәт тәрбиясе бирүгә, балаларда сәламәт яшәү күнекмәләре булдыруга юнәлдерелгәннәр. Бу эш белән беренче чиратта үзләре үк мәктәпкәчә тәрбия йортлары оештырып йөргән галимнәр шөгыльләнә. Алардан К. Вәлитова, С. Миңлекәй, М. Ялымова, М. Мөштәри һ. б. ны санап китәргә була. Алар үзләренең гамәли һәм тәгълимати хезмәтләре белән мәктәпкәчә тәрбия эшенең урнашуына һәм аның таралуына зур йогынты ясыйлар [7]. Бу хезмәтләрдә сөйләм үстерү бурычлары гомум характерда булып, коллективизм һәм яңа кеше тәрбияләү принципларына корыла, сөйләм үстерү заман чынбарлыгы яки тормыш белән бәйләп карау күздә тотыла.

1962 елда РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәрбиячеләр өчен төп дәүләт документы буларак «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы» раслана һәм куллануга тәкъдим ителә. Программа педагогика тарихында балаларны сабый чактан алып мәктәпкә кадәр (2 айдан алып 7 яшькә кадәр) тәрбияләүнең төп эчтәлеген һәм формаларын билгеләгән беренче методик документ була [10]. Анда сөйләм үстерү бурычы эшчәнлекле якын килү аша хәл ителә, ягъни сөйләм күнекмәләре һәр бүлек саен чагылып, сөйләм осталыгы характеры һәр төр эшчәнлекнең эчтәлеге, оештыру үзенчәлеге белән билгеләнә. Гомумән, бу программада балалар сөй-

ләменә таләпләрне сөйләм дөреслегеннән һәм матурлыгыннан чыгып карау талпынышы ясала. Бу программа СССРның, нигездә, барлык балалар бакчаларында XX гасыр ахырында яңа норматив документлар барлыкка килгәнче кулланылган. 1978 елда аңа үзгәрешләр кертелә һәм ул үрнәк программа дип атала башлый. Татар телендә тәрбия бирә торган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре үзләренең эшчәнлеген федераль программага («Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы»на [10]) таянып алып баралар. Аның нигезендә союздаш республикалар төбәкнең үз программасын төзи. Татарстанда 1994 елда әлеге программа филология фәннәре докторы, профессор Ф.Ю. Юсупов җитәкчелегендә З.Ф. Камалова, Р.А. Борһанова, Р.Н. Ярмиева, М.А. Вәлиуллиннар тарафыннан тәрҗемә ителә һәм, шуңа нигезләнеп, «Балалар бакчасында тәрбия һәм укыту программасы» басылып чыга [4]. Акыл, хезмәт, әхлак тәрбиясе, физик һәм эстетик тәрбия бирүне, нәниләрне мәктәптә укуга әзерләүне күздә тоткан бу программа татар телендә тәрбия бирүче балалар бакчалары педагоглары өчен зур сөенеч була. Аның уңышлы ягы – тәрбия һәм белем бирү процессына милли-төбәк компонентлары кертелү. Программага, сөйләм телен үстерү максатыннан, татар язучыларының төрле жанрларда иҗат ителгән әсәрләре кертелә, музыка тәрбиясе бирү өчен классик татар композиторларының әсәрләре киң урын ала.

Тәрбия һәм белем бирү эшендә укыту-дисциплинар модель куллану – программаның [4] зур кимчелеге. Баланы мәктәптә укырга әзерләү, аңа билгеле бер күләмдә белем һәм күнекмәләр бирү төп максат булып тора. Ә баланы шәхес буларак үстерү, аңа мәктәптә уку өчен кирәкле психологик процесслар – күзәтүчәнлек, хәтер, логик фикерләү сәләте, игътибарлылык һ. б. икенче планда, читтә кала. Балаларның шәхси үзенчәлекләрен өйрәнеп, аларның сәләтләрен ачу, шул сәләтне үстерүгә юнәлеш бирүгә дә зур игътибар ителми.

1990 елның 30 августында кабул ителгән суверенлык декларациясе нигезендә татар һәм рус телләре дәүләт теле итеп игълан ителгәч, мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә рус һәм башка милләт балаларына татар теле өйрәтү бурычы куела.

1991 елдан соң базар икътисадына һәм демократик үзгәртеп коруларга күчү мәгариф өлкәсенең дә үзгәрүенә китерә. Һәр балага аерым якын килүгә һәм аның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алуга нигезләнгән яңа мәктәпкәчә тәрбия бирү концепцияләре һәм модельләре барлыкка килә. Региональ хакимият органнары җирле шартларга һәм төбәкләрнең мәдәни үзенчәлекләренә җайлаштырылган белем бирү программаларын мөстәкыйль рәвештә эшләү мөмкинлегенә ия була.

1992 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» законы [12] нигезендә балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрнең үз туган телендә сөйләшә алу сәләтен җитди үстерү, аларның танып белү процессларын камилләштерү, белем һәм тәрбия бирүдә милли мирастан, матур әдәбият әсәрләреннән сыйфатлы файдалану мөһим бурычлар рәтенә куела. Нәтиҗәдә, белем бирүнең

беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый. Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә. Тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган программалар, яңа технологияләр көннән-көн киңрәк кулланыла. Татар телен өйрәтүче тәрбиячеләргә татар телен «Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы» [2], ә ана телен «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы» [3] нигезендә алып барырга тәкъдим ителә.

2000 елларда «Балалар бакчасында тәрбия һәм укыту программасы» [3] балалар бакчаларының ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Илдә бара торган үзгәрешләрне, заман таләпләрен искә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-методик үзәге (Татарстан Республикасы Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институты белән берлектә) программаны кабат нәшер итүгә әзерли.

М.А. Васильева җитәкчелегендә эшләнгән «Программа воспитания и обучения в детском саду» [9] федераль программасына нигезләнеп, татар телендә төбәкнең «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы» [3] төзелә. Шулай ук программаның кайбер бүлекләрендә Ф.Ю. Юсупов җитәкчелегендә төзелгән «Балалар бакчасында тәрбияләү һәм укыту программасы»ның [4] тәрҗемәсе файдаланыла. Программа мәктәпкәчә тәрбия буенча дәүләт һәм республика стандартларын, педагогика һәм психология өлкәсендәге казанышларны, хәзерге көн таләпләрен искә алып үзгәртелә, тулыландырыла. Балаларда халык иҗаты, милли-гамәли сәнгать, халык һөнәрчелеге белән кызыксыну хисе уяту максатыннан, программага татар халкының тормыш-көнкүрешендәге үзенчәлекләр, милли кием, мөселман бәйрәмнәре, республикабызның иҗтимагый тормыш вакыйгалары, символикасы; сынлы сәнгать әсәрләре, декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру бурычлары кертелгән.

2000 елда К.В. Закирова һәм Р.А. Борһановалар тарафыннан балалар бакчаларының эшен камилләштерү һәм эчтәлеген яңарту буенча үзгәрешләр кертелгән «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы» төзелә [3]. Тәрбия-белем бирү процессына милли-төбәк компонентлары кертүгә нигезләнгән әлеге программа яңа социаль-икътисади шартлар балаларда милли аң һәм үзаң тәрбияләү, нәниләрне үз халкының тарихы, традицияләре, мәдәнияте белән таныштыру бурычын куя. Балалар, иң беренче чиратта, үзе яши торган төбәкнең табигате һәм аның үзенчәлекләрен, шулай ук туган халкының үзенә генә хас гореф-гадәтләрен, сәнгатен, әдәбиятын, мәдәниятен аеруча яхшы белергә тиешләр. Программада тәрбия

эше «үз туган халкыңның мәдәниятеннән – дөнья культурасына» дигән методологик принципка нигезләнеп алып барылырга тиеш, дигән таләп куела.

Балаларда халык иҗаты, милли-гамәли сәнгать, халык һөнәрчелеге белән кызыксыну хисе уяту максатыннан, программага татар халкының тормыш-көнкүрешендәге үзенчәлекләр, милли кием, мөселман бәйрәмнәре, республикабызның иҗтимагый тормыш вакыйгалары, символикасы; сынлы сәнгать әсәрләре, декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру бурычлары кертелә.

Программада балалар өчен язылган матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре һәр яшь төркеме өчен кварталларга бүленеп тәкъдим ителә. Әсәрләр уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау өчен дип күрсәтелеп бирелә. Ләкин бу шартлы бүленеш кенә. Чөнки балаларның әдәби әсәрләрне аңлау, кабул итү мөмкинлекләре төрле. Моңа аларның шәхси үзенчәлекләре дә, яшәү шартлары да, шулай ук матур әдәбият белән таныштыруның ни дәрәҗәдә эзлекле алып барылуы дә йогынты ясый. Шунлыктан тәрбияче әсәрләр белән эшләү төрен (ятлау, эчтәлеген сөйләү, уку) үзе билгели ала. Шулай ук, тәрбияче, болар белән генә чикләнмичә, өстәмә әдәбиятка да мөрәҗәгать итәргә тиеш. Анда эчтәлеге белән балалар күңеленә якын, аңлаешлы, алар яратып тыңлый торган күп кенә әсәрләр тупланган.

Программада шулай ук нәниләрдә әдәплелек, әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә дә зур игътибар бирелгән.

2014 елда «Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт стандарты» [11] гамәлгә кергәннән соң, белгечләр алдына мәктәпкәчә мәгарифнең үрнәк программаларын төзү бурычы куела. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләренә һәм үрнәк белем бирү программасына нигезләнеп [8], үзләренең белем бирү программасын төзи, раслый һәм тормышка ашыра. Бу очракта, һичшиксез, мәктәпкәчә белем бирү программасының инвариант (үзгәреш кертелми торган, гомуми күләмнең 60% ыннан ким булмаган) һәм вариатив (белем бирүдә катнашучылар төзегән – 40% тан артык булмаган) өлешләрдән торырга тиешлеген истә тоту зарур. Вариатив өлеш мәктәпкәчә белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль төзелә. Монда, әлбәттә, этник-мәдәни ихтыяҗлар, милли төбәк үзенчәлекләре, мәгариф оешмасының мәнфәгатьләре, сәламәтлеге чикләнгән балаларның шәхси теләк-мөмкинлекләре, ата-аналарның сорау-тәкъдимнәре һ. б. искә алына. Димәк, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, төп норматив документларны файдаланып, әлегә үз программаларын төзи һәм эш юнәлешләрен билгели ала. Программа эчтәлеге балаларны шәхес буларак формалаштыруны, аларның төрле юнәлештәге эшчәнлектә кызыксынуларын һәм сәләтләрен үстерүне тәэмин итәргә тиеш була.

Шушы таләпләрне тормышка ашыру өчен бала иң элек үз фикерен булдырырга һәм аны курыкмыйча дөрес, аңлаешлы сөйләм белән әйтеп бирә белергә тиеш. Балаларның акыл үсешен һәм сөйләм телен

үстерү, кечкенәдән үк үз туган телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү – бүгенге көннең иң мөһим бурычы.

2015 елда Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми үрнәк төп гомуми белем бирү программалары реестрына Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә «Туганнан алып мәктәпкәчә. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы» кертелде. 2016 елда ул Р.И. Хәлиуллина тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителде [13].

Үрнәк программаның кысалы характеры мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында белем бирү процессының гомуми моделен тәкъдим итү, үсешнең яшькә бәйле нормативларын күрсәтү, белем бирү эшчәнлегенең структурасын билгеләү һәм эчтәлеген баланың биш төрле белем бирү өлкәсендә үсеш юнәлешләренә туры килә торган итеп тулыландыру аша ачыла. Программаның төп максатлары – баланың мәктәпкәчә балачагын тулы канлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, анда культура нигезен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

Программада баланың шәхесен үстерүгә, балаларның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын таба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә.

Программага хас үзенчәлекләр:

1. Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек.
2. Патриотик юнәлгәнлек.
3. Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек.
4. Алга таба укуны дәвам итү максатын кую.
5. Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек.
6. Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек.

Программа федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә түбәндәге үсеш юнәлешләрен тормышка ашыру максатын куя:

1. Социаль-аралашу үсеше.
2. Танып-белү үсеше.
3. Сөйләм үсеше.
4. Эстетик-сәнгать үсеше.
5. Физик үсеш.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010–2015 елларда Мәгарифне үстерү стратегиясе – «Киләчәк» программасы ярдәмендә, мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы төзелеп [19], Федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләренә җавап бирә алырдай

укыту-методик комплектлар булдырылды. УМК га методик әсбаплар, программалар, хрестоматияләр, эш дәфтәрләре, тематик картинкалар, күрсәтмә һәм тарату материаллары, мультимедиа чаралары керә. Бу комплектларга балаларны татар һәм рус телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомумән, балаларның актив сөйләмен үстерү максаты куелган.

«Туган телдә сөйләшәбез» укыту-методик комплекты ярдәмендә (авторлары: З.М. Зарипова, Ф.В. Хәзрәтова, З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина) [14] тәрбиячеләр татар теленә өйрәтү һәм сөйләмне үстерү бурычларын танып белү, коммуникатив алымнар, матур әдәбият белән таныштыру аша гамәлгә ашыра. «Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга тел хәзинәсен, татар теленең матурлыгын, байлыгын аңларга, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга; кеше өчен газиз булган туган илгә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итагать тәрбияләргә; үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек сыйфатлар булдыруны күздә тота.

Хәзерге вакытта балалар бакчасында туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү «Куаныч» мәктәпкәчә белем бирү программасы»на [18] нигезләнеп алып барыла. Программа Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты, Федераль мәктәпкәчә белем бирү программасы таләпләренә туры китереп эшләнгән. Әлеге Программа максат һәм бурычларны, планлаштырылган нәтиҗәләрне, мәгариф эшчәнлеген оештыруны, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан балачак үсешенең этномәдәни һәм яңа социомәдәни вазгыятен исәпкә алып формалаштырыла торган мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген билгели. Программа белем бирүнең иң югары максатын – кеше турында әхлакый (идеаль) күзаллау буларак аңлана торган милли тәрбия идеалын гамәлгә ашыруга нигезләнә.

Программада 2–7 яшьлек балалар өчен белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан төбәкнең иҗтимагый-мәдәни һәм милли кыйммәтләрен исәпкә алып формалаштырыла торган белем бирү эчтәлеге чагылыш таба, күпмилләтле Россия Федерациясе халыкларының тел мирасын саклау һәм үстерүне тәэмин итү максатыннан әлеге программаны туган (татар) телдә тормышка ашыру каралган.

Программа оешмада һәр баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә, баланы тел, предмет, табигать, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә, шулай ук танып белү, үзгәртеп кору һәм иҗат итү ысулларына нигезләнгән гомумкешелек мәдәнияте белән таныштыру һәм аны үзләштерү өчен шартлар тудыруны күз уңында тоткан мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсеше проблемасына мәдәни-тарихи якын килүгә туры китереп эшләнгән.

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программалары буш урында гына барлыкка килмәгән. Алар, вакытлар узу белән, мәктәпкәчә белем

бирү ихтыяҗын канәгатьләндерми, мәгариф, заман таләпләренә туры килми башлый, нәтиҗәдә, алар урынына яңа программалар барлыкка килә. Бүген мәктәпкәчә учреждениеләрнең төбәк мәгариф программалары, заманча таләпләргә һәм чынбарлыкка яраклашып үсүен дәвам итә. Алар бала үсешен тәэмин итүә торган заманча алымнар һәм технологияләр кертеп, үткәннең иң яхшы традицияләренең дәвамчанлыгын саклый.

Хәзер гамәлдә булган бу документ [18] мәктәпкәчә белем бирүнең федераль мәгариф программасына, танылган педагог һәм методистларның күпьеллык эш тәҗрибәсенә һәм милли традицияләргә таяна.

**Әдәбият**

1. Балалар бакчасында татарча сөйләм үстерү дәресләре: балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / [төз.: З.М. Зарипова, А.И. Касыймова]. Казан, 2010. 117 б.

2. *Борһанова Р.А., Юсупов Ф.Ю.* Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. Казан: РИЦ «Школа», 2004.

3. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / [төз.: К.В. Закирова, Р.А. Борһанова]. Казан: Хәтер, 2000. 192 б.

4. Балалар бакчасында тәрбия һәм укыту программасы / [төз.: Ф.Ю. Юсупов, З.Ф. Камалова, Р.А. Борһанова, А.Ш. Әсәдуллин, Р.Н. Ярмиев, М.Ә. Вәлиуллин]. Чаллы, 1994. 114 б.

5. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / [төз. З.М. Зарипова]. Яр Чаллы, 2000. 70 б.

6. *Вәлитова К.* Мәктәпкә кадәр тәрбия // Мәгариф. 1921. № 1/2. Б. 36–43.

7. *Зиннәтуллина А.Ә.* Татар балалар бакчаларының барлыкка килү алшартлары һәм беренче адымнары // https://historicalethnology.org/wp-content/uploads/2018/01/ИЭ_2_2017_Зиннатуллина_338-345.pdf (мөрәҗәгать итү көне: 30.05.2025).

8. От рождения до школы. Инновационная программа дошкольного образования / [под ред. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, Э.М. Дорофеевой]. М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2015. 336 с.

9. Программа воспитания и обучения в детском саду / [под ред. М.А. Васильевой]. М.: Просвещение, 1985. 208 с.

10. Программа воспитания и обучения в детском саду / под ред. Н.А. Ветлугиной. М.: Просвещение, 1962. 288 с.

11. *Сафиуллина Г.* Мәктәпкәчә белем бирү стандарты: таләпләр һәм мөмкинлекләр // Мәгариф. 2014. № 12. Б. 11–14.

12. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы законы. Казан: РИЦ «Школа», 1998. 80 б.

13. Туганнан алып мәктәпкәчә. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы / [Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева; русчадан Р.И. Хәлиуллина тәрҗ.]. Казан: ХӘТЕР, 2016. 357 б.

14. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / [З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина, Ф.В. Хәзрәтова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 19 б.

15. Туган телдә сөйләшәбез: методик әсбап / [З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина, Ф.В. Хәзрәтова]. Казан: Инновацион технологияләр үзәге, 2019. 256 б.

16. Федеральный государственный стандарт дошкольного образования (утвержден приказом Минобрнауки России от 17.10.2013 № 1155). Официальный сайт МО и Н РТ (мөрәҗәгать итү көне: 09.12.2024).

17. *Хәмидуллин Ф.* Беренче балалар бакчасы // Мәгариф. 1967. № 11. Б. 57– 58.

18. *Шәехова Р.К.* «Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. Казан: Татар балалар нәшр., 2024. 146 б.

19. *Шаехова Р.К.* Региональная программа дошкольного образования = Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. Казан: РИЦ, 2012. 99 с.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Төхфәтуллина Әлфия Госман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Тухфатуллина Альфия Гусмановна,***
*кандидат филологических наук, преподаватель татарского языка и литературы Арского педагогического колледжа им. Г. Тукая*

*12345alfia@mail.ru*

УДК 372.881.1

***К.С. Фәтхуллова***

# ЯҢА ШАРТЛАРДА ТУГАН ТЕЛДӘН ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ОЕШТЫРУ

В данной статье рассматриваются результаты исследования по организации внеурочной работы по татарскому языку в современных условиях в общеобразовательных организациях. Цель исследования – научно обосновать и практически подтвердить важность организации учителями татарского языка внеурочной деятельности по учебному предмету. Эта работа позволяет развивать творческие и коммуникативные способности школьников; углубить знания и расширять их познавательную активность, а также повышать мотивацию к изучению родного языка. Научная новизна статьи заключается в том, что в ней содержатся методические рекомендации по проектированию и проведению внеклассной работы по татарскому языку в соответствии с требованиями обновленных ФГОС и с содержанием Федеральной примерной программы воспитания для общеобразовательных учреждений. Изучение татарского языка направлено на развитие у обучающихся речевой, языковой и этнокультурной компетенций, поэтому каждому учителю необходимо в своей педагогической деятельности придавать отдельное внимание организации внеклассных мероприятий с целью повышения результативности образовательного процесса.

**Ключевые слова:** татарский язык, внеурочная работа, методические рекомендации, результативность обучения, ключевые компетенции.

This article examines the results of a study on the organization of extracurricular activities in the Tatar language in current general education institutions. The purpose of the study is to scientifically substantiate and practically confirm the importance of Tatar language teachers organizing extracurricular activities related to the subject. This work helps develop students' creative and communicative abilities, deepen their knowledge and expand their cognitive activity, and increase their motivation to study their native language. The scientific novelty of the article lies in its provision of methodological recommendations for the design and implementation of extracurricular activities in the Tatar language in accordance with the requirements of the updated Federal State Educational Standards and the Federal Model Curriculum for General Education Institutions. The study of the Tatar language is aimed at developing students' speech, linguistic, and ethnocultural competencies. Therefore, every teacher must pay special attention to the organization of extracurricular activities in their teaching to improve the effectiveness of the educational process.

**Keywords:** Tatar language, extracurricular activities, methodological recommendations, learning outcomes, key competencies.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясенең барлык урта гомуми белем бирү оешмаларында тәрбияви эшчәнлек «Федераль үрнәк тәрбия бирү программасы» нигезендә алып барыла [7]. Норматив документта әйтелгәнчә, тәрбия бирү процессын уңышлы оештыру өчен, һәр мәктәптә укучы шәхесенең үсеше өчен кирәкле шартлар булдыру

мөһим. Татар теле укытучысы педагогик эшчәнлегендә үз предметыннан белем бирү белән генә чикләнми, ул эзлекле һәм системалы рәвештә дәрестән тыш эш алып барырга, яшь буынны тәрбияләүгә тиешле игътибар бирергә бурычлы. Нәкъ менә мәктәп елларында укучылар үзара аралашырга, башкалар белән мөнәсәбәтләр урнаштырырга, кешеләр белән уртак тел табарга, авыр ситуацияләрдә креатив карар кабул итәргә, үз көчләренә ышанырга өйрәнәләр, рухи кыйммәтләрне үзләштерәләр һәм, нәтиҗәдә, һәркем өчен мөһим булган гамәли тәҗрибәгә ия булалар. Шуңа күрә яңа шартларда укучыларга традицион һәм милли мәдәният кыйммәтләрен җиткерү, аларның асылына төшендерү зур әһәмияткә ия.

Гомуми кыйммәтләргә педагоглар кеше тормышы, гаилә, Ватан, мәдәният, хезмәт, сәламәтлек кебек төшенчәләрне кертеп карыйлар.

Фәнни-методик хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, тәрбия бирү – укучының шәхси сыйфатларын максималь рәвештә үстерүгә, аны үз тормышының субъекты буларак формалаштыруга юнәлтелгән һәм укытучы тарафыннан махсус оештырылган эшчәнлек. Димәк, тәрбия бирү – уңайлы шартлар булдыру аша бала шәхесенең үсеше процессы белән идарә итү дигән сүз [2: 12]. Әлеге билгеләмәне В.А. Караковский, Л.И. Новикова, Н.Л. Селиванова кебек танылган педагоглар тәкъдим итә. Бүгенге көн укытучысының төп тәрбияви максаты – укучы шәхесенең үсешен тәэмин итү. Төп бурычлары: балаларны кызыклы дәрестән тыш эшләр белән мавыктыру; укучылар белән ышанычлы һәм формаль булмаган элемтәләр урнаштыру; үзара аралашуга кыйммәти юнәлеш бирү.

Билгеле булганча, дәүләтебезнең киләчәге җәмгыятебездәге кешеләр белән бәйләнгән. Ә ул кешеләргә башка педагоглар белән беррәттән татар теле укытучылары да белем һәм тәрбия бирә, уртак эшкә үз өлешен кертә. Шуңа күрә татар теле укытучыларының дәрестән тыш эшчәнлеге заман таләпләренә җавап бирергә, инновацияләр кулланып, методик яктан югары дәрәҗәдә оештырылырга тиеш. Шулай эшләгәндә генә укытучы яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартында (ФДББС) билгеләнгән максатларга ирешә ала [6]. Бүгенге көндә әлеге мәсьәләнең актуальлеге беркемдә дә шик тудырмый. Дәрестән тыш чаралар аша татар теле укытучысы балаларда дәүләт алдында җаваплылык формалаштыра, аларда ватанпәрвәрлек һәм күпмилләтле Россия халыкларының гореф-гадәтләренә һәм мәдәни мирасына карата хөрмәт хисе, шул ук вакытта укучыларның туган теле булган татар теленә, татар халкының тарихы һәм мәдәниятенә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияли, аларның рухи үсешен тәэмин итә. Иҗади эшләүче алдынгы татар теле укытучыларының тәҗрибәсе күрсәткәнчә, дәрестән тыш эшләр балаларның дәресләрдә алган белемнәрен тирәнәйтергә, аларның иҗади осталыкларын камилләштерергә, үзара аралашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен ныгытырга, социальләшү ихтыяҗларын гамәлгә ашырырга ярдәм итә [4: 5].

Татар теленнән дәрестән тыш эш мәдәни-тарихи, эшчәнлекле һәм шәхескә юнәлтелгән төп методик юнәлешләргә нигезләнеп алып барыла. Дәрестән тыш чараларда катнашкан һәр укучы үзен шәхес итеп тоя, коллективта үз урынын таба һәм үзенең кирәклеген күрә, тормыш тәҗрибәсе туплый, һәр вакыйгага карата мөнәсәбәтен белдерергә, башкаларны тыңларга һәм хөрмәт итәргә, теләктәшлек күрсәтергә, җаваплылыкны үз өстенә алырга күнегә. Шундый эшчәнлек балаларны баета, үстерә, канатландыра, куандыра, аларда уңай тәэсир калдыра һәм көтелгән нәтиҗәләргә китерә. Татар теле укытучысы үткәргән һәр дәрестән тыш чара планлаштырылган метапредмет, предмет нәтиҗәләренә ирешүгә һәм тәрбияви бурычларны уңышлы хәл итүгә хезмәт итә. Бу уңайдан танылган татар галиме, педагог Ә. Хуҗиәхмәтовның укытучы хезмәте турында әйтелгән сүзләре игътибарга лаек: «Мәктәп бусагасын беренче атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаганчыга кадәр бала белән янәшә һәрчак аның Укытучысы атлый. Ул аны белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга өйрәтә, фикерләү сәләтен үстерә, дөньяга карашын формалаштыра, аңардан шәхес тәрбияләүгә бөтен көчен куя...» [8].

Татар теленнән үткәрелә торган дәрестән тыш чараларга күзәтү ясаганда, аларның шактый күптөрле булуы күзгә ташлана. Мәсәлән, һәр мәктәптә уку елы барышында татар теле атналыгы үткәрелә, укучылар күпсанлы чараларда теләп катнашалар: иҗади бәйге һәм викториналар, концерт һәм фестивальләр, лингвистик уеннар, токшоу, квиз һәм квестлар, шигъри флешмоб һәм онлайн-марафоннар, социаль проект һәм акцияләр, осталык дәресләре, тренинглар, шигърият кичәсе, татар әкиятләрен сәхнәләштерү, яңа китаплар күргәзмәсен тәкъдим итү, сыйныф газетасын чыгару, танылган татар шәхесләре белән очрашулар, татар театрларына һәм күренекле шәхесләрнең музейларына экскурсиягә бару, фәнни-гамәли конференциядә чыгыш ясау һ. б. Мисаллардан күренгәнчә, дәрестән тыш эшчәнлек укытучы белән укучыларның үзара хезмәттәшлек итүенә әверелә, укытучының методик осталыгын үстерүгә китерә, ә укучылар яңа белемнәргә, күнекмәләргә, социаль тәҗрибәгә ия булалар, аларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну тагын да арта. Шул ук вакытта әлеге чаралар дәрес программасында тәкъдим ителгән материалны ныгытырга, тулыландырырга булыша. Шуны да ассызыклап үтик: дәрестән тыш чараларны оештырганда, укучыларга индивидуаль якын килү, аларның ихтыяҗларын һәм кызыксынуларын исәпкә алып эш итү, шәхси һәм психологик үзенчәлекләренә игътибар бирү сорала.

Методистлар искәртеп үткәнчә, укытучы эш барышында түбәндәге тәкъдимнәрне дә истә тотарга тиеш: тәрбияви чаралар эмоциональ яктан үтемле һәм балаларны кызыксындыра алырлык алымнарга бай булырга тиеш; рефлексия этабында укучыларны, үз фикерләрен дәлилләп, нәтиҗә ясарга өйрәтергә кирәк.

Дәрестән тыш эшчәнлекне уңышлы оештыру өчен, укытучыга заманча педагогик технологияләр ярдәмгә килә. Алар арасында аеруча проектлар технологиясенә өстенлек бирелә. Укучылар үзләре тикшеренү объектын билгелиләр, төрле чыганаклардан файдаланалар, интернет һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урын алган материалны тәнкыйть күзлегеннән карап сайлыйлар, аны анализлыйлар, чагыштыралар, нәтиҗә ясыйлар, чыгыш ясау өчен, презентация әзерлиләр һәм проектларын яклыйлар. Шундый эшләр укучылар өчен аеруча әһәмиятле, чөнки аларны башкару барышында балаларның сөйләм, тел, этномәдәни һәм тикшеренү компетенцияләре үсеш ала, уңыш ситуациясе булдырыла.

Моннан тыш, төрле сыйныфларда уен технологиясе киң кулланыла. Уен укучыларның танып белү һәм фикер йөртү эшчәнлеген активлаштыра, укучыларга дифференциаль якын килүне тәэмин итә. Уеннарны берничә төркемчәгә бүлеп карыйлар: өйрәтү уеннары, тренинг үткәрү уеннары, тикшерү уеннары, иҗади уеннар. Куллану ысулыннан чыгып, сюжетлы, рольле, эшлекле, имитацион уеннар була.

Шулай ук татар теле укытучылары мәгълүмати-коммуникатив, тәнкыйди фикерләү, үстерелешле укыту, проблемалы укыту, берләштереп укыту, модульле укыту, кейс, кроссенс, TED, ТРИЗ технологияләрен үз эшләрендә уңышлы кулланалар, алар ярдәмендә балаларны иҗади эшчәнлеккә тарталар. Методик хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, укытучы сайлап алган заманча педагогик технологияләр шәхескә һәм укучыларның социаль үсешен тәэмин итүгә юнәлтелгән булырга тиеш. Яңа технологияләрне куллану белән бәйле берничә таләпне билгеләп үтик: укучыларның яшен, белем дәрәҗәсен исәпкә алу; традицион һәм инновацион методларның бер-берсен тулыландыруын истә тотып эш итү; тел материалын визуаь рәвештә кабул итүнең мөһимлегенә аерым игътибар бирү.

Эш барышында укучыларны цифрлы ресурслар, татар телендәге белем бирү порталлары белән таныштыру, андагы мәгълүматка аларның игътибарын җәлеп итү шулай ук зур әһәмияткә ия. Моны дәлилләү өчен, күренекле язучы һәм тел белгече Галимҗан Ибраһимовның сүзләрен искә төшереп үтү урынлы булыр: «Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр» [3].

Укучыларда мөстәкыйльлек, ягъни үзлегеннән уйлау һәм фикер йөртү, эшне башкарып чыгу сыйфаты тәрбияләү өчен, укытучы аларга дәрестән тыш эшләрнең бер төре буларак индивидуаль биремнәр тәкъдим итә ала. Мәсәлән: 1) интернеттан Татарстан халыклары ассамблеясы турында мәгълүмат табып сөйләгез. 2) «Бәйрәме бар халык – бай халык» темасына проект эше әзерләгез. 3) «Шәһәребездәге бер һәйкәл» темасына презентация әзерләгез. 4) Туган ягыгыз белән таныштырып, мәктәп музеенда виртуаль экскурсия үткәрегез.

5) «Кече Ватаным» темасына мәктәп газетасы өчен мәкалә языгыз. 6) «Татарстан – уртак йортыбыз» фестивалендә катнашу өчен чыгыш әзерләгез. 7) «Халыклар дуслыгы – Татарстанның байлыгы» темасына ток-шоу оештырыгыз. 8) РФ төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге татар милли оешмаларының эшчәнлеге турында мәгълүмат табыгыз һәм сөйләгез. 9) Милли ризыклар турында видеосюжетлар әзерләгез һәм сыйныфташларыгыз белән уртаклашагыз һ. б. Әлеге биремнәрне үтәүче һәр укучы үзе өчен кызыклы һәм файдалы мәгълүмат ала, аңа карата үз мөнәсәбәтен белдереп, фикерләрен башкаларга җиткерергә һәм үз эшенә объектив бәя бирергә күнегә. Ә бу, үз чиратында, укучыга позитив социаль тәҗрибә тупларга һәм үзен шәхес буларак бәяләргә ярдәм итә. Төрле дәрестән тыш чаралар аша укытучы балалар күңелендә туган телгә карата хөрмәт һәм аны өйрәнүгә даими кызыксыну булдыруга ирешә. Укучылар, башлангыч мәктәптән алып, халкыбызның рухи мәдәнияте белән танышсалар, туган телдә чыгыш ясарга өйрәнсәләр, мәктәптә үткәрелә торган чараларда теләп катнашсалар, алар чын мәгънәдә милли җанлы һәм мәгърифәтле булып үсәләр. Танылган татар мәгърифәтчесе, галим, дин эшлеклесе, педагог Ризаэддин Фәхреддиннең сүзләре моңа дәлил булып яңгырый: «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас». Форсаттан файдаланып, бөек шәхеснең тагын бер гыйбарәсен искә алып үтү кирәктер: «Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле балалар» [5: 134]. Әлеге сүзләр бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый.

Димәк, туган тел укытучыларыннан тәрбия бирү ысулларын һәм алымнарын тагын да камилләштерергә омтылу, төрле чаралар аша укучыларның күңелләрендә туган телгә мәхәббәт салу һәм аны көннән-көн арттыру, балаларда оптимизм, оешканлык, кыюлык, тапкырлык, тәвәккәллек кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү сорала.

Шунысы да мөһим: тәрбияви бурычларны уңышлы хәл итү өчен, укытучыга ата-аналар, җәмәгатьчелек белән тыгыз һәм дустанә мөнәсәбәттә, уртак фикердә булырга кирәк. Моның өчен аңа сабырлык, шәфкатьлелек, ихтыяр көче кебек сыйфатларга ия булу зарур.

Аңлашыла ки, бу – җаваплы һәм катлаулы эш, һәм укытучы үзе һәрьяклап үрнәк булырга тиеш. Үзе мавыккан укытучы гына балаларны да мавыктыра ала, диләр. Татар теле укытучыларының мәктәптә фәнни түгәрәкләр алып барулары, укучыларны фән дөньясы белән таныштырулары, аларны фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаштырулары уңай тәҗрибәнең тагын бер ачык мисалы булып тора. Фәнни эзләнүләр укучыларга күренекле шәхесләрнең тормыш һәм иҗат юлы, аларның хезмәтләре, халкыбызның үткәне һәм бүгенгесе, тарихи мирасы белән танышырга мөмкинлекләр бирә. Әлеге эшчәнлек балаларның иҗади сәләтләрен ачып бирүгә, танып белү эшчәнлеген активлаштыруга, фәнгә кызыксынуларын арттыруга китерә. Моның белән беррәттән сыйныфтан тыш эшләрдә актив катнашучы

укучы шәхси потенциалын һәм эчке мотивларын тормышка ашырырга өйрәнә, горурлык һәм канәгатьлек хисе кичерә. Укытучы, үз чиратында, балаларның хыялларын һәм мавыгуларын аңларга, аларга ярдәм итәргә, һәр позитив адымын хупларга бурычлы. Әлеге эш, һичшиксез, укытучылардан зур тырышлык һәм педагогик осталык таләп итә, белем һәм тәрбия бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итәргә өйрәтә.

Татар теле укытучысының балалар белән дәрестән тыш эш оештыруы һәм үзара хезмәттәшлек итүе методик казанышларга китерә, әлеге эшчәнлекнең максатларын, эчтәлеген, яратып кулланыла торган алымнарны тагын да камилләштерергә ярдәм итә, фәнни эзләнүләргә этәргеч булып тора. Тикшеренү эшләренең нәтиҗәләре, алдынгы тәҗрибә белән уртаклашып, укытучылар методик хезмәтләрдә һәм конференция җыентыкларында мәкаләләрен, дәрестән тыш чараларның эшкәртмәләрен бастыралар, шәхси сайтларында мәгълүмат урнаштыралар һәм хезмәттәшләренә ярдәм күрсәтәләр. Яңа шартларда максатчан эш алып баручы, заманча белемнәрне һәм педагогик инновацияләрне үз эшчәнлегендә даими кулланучы укытучы гына яшь буынга төпле белем һәм милли тәрбия бирә, эшенең нәтиҗәләрен күрә ала, дигән нәтиҗәгә киләбез. Бүгенге шартларны исәпкә алып, урта гомуми белем бирү оешмаларында һәр укучыны югары технологияләр заманында көндәшлеккә сәләтле һәм милләте турында кайгыртырлык, туган илен яратучы, туган телен белүче, үз халкын хөрмәт итүче, Россия халыкларының һәм кешелек дөньясының рухи кыйммәтләрен аңлаучы шәхес итеп тәрбияләү – заман таләбе. Әйтелгәннәрне гомумиләштереп, күренекле галимебез Ш. Мәрҗани сүзләре белән йомгак ясау дөрес булыр: «Үткәнен белмәгән, милли тәрбия алмаган кешенең киләчәге юк».

**Әдәбият**

1. *Бахтигулова Л.Б.* Методика воспитательной работы: учебник для вузов / Л.Б. Бахтигулова, А.В. Гаврилов. 2-е изд., испр. и доп. М.: Юрайт, 2025. 188 с.

2. Воспитательная деятельность в школе. Учебное пособие для студентов педагогических специальностей и начинающих педагогов / под ред. П.В. Степанова. М.: ФГБНУ «Институт стратегии развития образования», 2023. 204 с.

3. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: унбиш томда. 9 т.: Татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр (1910–1917) / ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 381 б.

4. Проектирование воспитательной работы в школе в современных условиях: методические рекомендации. URL: http://irort.ru/sites/default/files/31-proektirovanie-vospit-raboti.pdf (мөрәҗәгать итү көне: 01.06.2025).

5. *Фәхреддин Р.* Көзге өстендә калган исем – бетмәс гомердер. Казан: Рухият, 2014. 148 б.

6. ФГОС ООО. URL: https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/401333920/ (мөрәҗәгать итү көне: 01.06.2025).

7. Федеральная примерная программа воспитания для общеобразовательных учреждений. URL: https://fgosreestr.ru/poop/primernaia-rabochaia-programma-vospitaniia-dlia-obshcheobrazovatelnykh-organizatsii (мөрәҗәгать итү көне: 01.06.2025).

8. Хузиахметовские чтения. Основные направления совершенствования средств и методов обучения и воспитания: Сб. науч. тр. / под общ. ред. д-ра пед. наук, проф. А.Н. Хузиахметова и др. Нижняя Русь, 2024. 284 с.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Фәтхуллова Кадрия Сөнгать кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының гамәли тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

***Фатхуллова Кадрия Сунгатовна,***
*кандидат педагогических наук, доцент кафедры общего языкознания и тюркологии Казанского федерального университета*

*Kadria.kgu@mail.ru*

УДК 745/749+82-1

*А.Ю. Махинин*

# ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ӘСӘРЕН БУЛДЫРУДА ВИЗУАЛЬЛӘШТЕРҮНЕҢ РОЛЕ

В основе данной работы исследование современных методических подходов в подготовке специалистов в области декоративно- прикладного искусства. Основное внимание уделяется использованию художественных особенностей поэтического текста в процессе создания произведения декоративно-прикладного искусства. Целью работы является определение приемов создания прикладного художественного изделия по мотивам литературного произведения. Мы приходим к выводу, что более точному воплощению авторского замысла при создании произведения декоративно-прикладного искусства способствует обучение анализу специфики построения стихотворного текста.

**Ключевые слова**: декоративно-прикладное искусство, керамика, панно, формообразование, декорирование, поэзия, Бродский, художественные средства, сюжет, композиция, художественный образ.

This work studies modern methodological approaches to training specialists in the field of decorative and applied arts. The primary focus is on the use of the artistic properties of poetic text in the creation of works of decorative and applied art. The goal of the work is to identify techniques for creating an applied art piece based on a literary work. We conclude that training in analyzing the specifics of poetic text construction facilitates a more accurate embodiment of the author's intent when creating a work of decorative and applied art.

**Keywords:** decorative and applied art, ceramics, panel painting, form-making, decoration, poetry, Brodsky, artistic devices, plot, composition, artistic image.

Хәзерге заманда нәфис керамика үсешендә утилитарлыктан читләшү күзәтелә, бу өлкәдә дә авторлар индивидуальлеккә омтылалар. Әйләнә-тирә дөньяны сәнгатьчә визуаль төшенү процессында рәссам өчен буяулар нинди әһәмияткә ия булса, керамика да шундый коралга әверелә.

Әмма керамик эшләнмә ясауда шундый осталыкка ирешү өчен, сәнгати сәләтләрне үстерергә кирәк, һәр оста үзгә авторлык теленә, сәнгати почеркка ия булырга тиеш. Димәк, һөнәргә өйрәтергә мөмкин, әмма сәнгати фикер йөртүче шәхес тәрбияләү җиңел түгел.

Хәзерге заманга караган кайбер фәнни хезмәтләрдә иҗатның башка төрләре белән интеграцион бәйләнеш булдыру ярдәмендә декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре ясауны оештыру процессы тикшерелә. Мәсәлән, Е.М. Торонованың «Живопись как предмет междисциплинарного исследования» [2], Л.В. Шокорова һәм О.В. Первушинаның «Межпредметность как основа целостности процесса обучения декоративно-прикладному искусству» [3] мәкаләләрендә төрле сәнгать төрләренә караган әсәрләрне башка төрләр

белән чагыштырып анализлауның предметка тирәнрәк һәм төрле планда якын килергә, һәм ахыр чиктә, эчтәлеге һәм стиле ягыннан кызыклы эшләнмәләр ясарга мөмкинлек бирүе ассызыклана.

Рәссам әсәр иҗат иткәндә еш кына үзен шәхес буларак формалаштырган, әйләнә-тирә дөньяны аңларга ярдәм иткән интеллектуаль багажыннан чыгып эш итә. Матур әдәбият әлеге багажның бер өлешен тәшкил итә. Чөнки әдәби әсәрнең эченә кереп, укучы автордашка әйләнә: кайгы-хәсрәтне, шатлыкны бергә кичерү, тирәннән аңлау процессы башлана. Бу планда шигъри текстның эмоциональ тәэсире күбрәк булырга мөмкин. Шуңа күрә сәнгати-пластик образ тудыруда нәкъ менә шигърият еш кына илһам чыганагына әйләнә.

Хәзерге буын студентлары XX гасырның икенче яртысында яшәгән аерым шагыйрьләр иҗатына битараф түгел. Чөнки әлеге фигуралар төрле чорларны, стильләрне, идеяләрне бәйләп торалар. Шундыйларның берсе – Иосиф Бродский.

Барыннан да элек, мөгаен, бу аның шигъри иҗатының төп лейтмотивы итеп ирекне санавыннандыр. Ирек аның өчен, тел белән беррәттән (бу сүзнең иң югары мәгънәсендә!), бик мөһим кыйммәт иде. Бүген сүзнең мәгълүмат чыганагы гына түгел, ә чынбарлыкка йогынты ясау коралы булуын һәркем таный.

Моннан тыш, Бродский үз иҗатында, беренче карашка, капма-каршы ике сыйфатны берләштерә һәм аның иҗаты чәчәк аткан вакытта рус поэзиясендә бу сыйфатларның берсе дә яхшы үзләштерелгән дип булмый. Болар – аның теленә хас югары академиклык һәм шуның белән бергә гадилек. Бродскийның шигъри теле эчке катлаулылыкка ия булса да, шигырьләренә салынган мәгънәләрнең аңлаешлы булуы таң калдыра.

Безнең карашка, әлеге үзенчәлекләр чагылыш тапкан әсәрләрнең берсе – «Стихи в апреле» шигыре. Ул шагыйрьгә хакимиятнең басымы аеруча көчле булган авыр елларда языла. Эчке киеренкелек нәтиҗәсе буларак, шигырь яшерен хис-кичерешләр белән тулы. Аларны кайвакыт сүзләр белән белдерү авыр, әмма визуальләштерү чаралары ярдәмендә ачыграк итеп тапшырырга мөмкин.

Шигырь текстының мәгънәсен һәм стилистикасын нәфис керамика әсәрендә гәүдәләндерүгә алынганда, иң элек шигырьнең төп темасын, иң әһәмиятле образларны һәм гомуми интонацион рәсемне ачыкларга кирәк. Бу – шигырьгә беренчел анализ була, һәм ул эшләнмәнең композицион төзелеше характерын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, лирик герой үзенә-үзе урын тапмый йөри, үзен әйләнә-тирә дөньяның бер өлеше итеп тоя алмый интегә. Шушы кичерешләрнең шигырь темасын тәшкил итүе башлангыч этапта ачыклана. Зур боз кисәкләре арасындагы буксир образы иң мәгънәле образга әверелә. Һәм лирик герой үзен шулар белән чагыштыра.

«Дотянув до седин,
я смотрю, как буксир среди льдин
пробирается к устью» [1: 162].

Тулаем алганда, шигырьнең интонациясе меланхолик монотонлыгы белән аерылып тора, шуңа да карамастан, аның артында яшерен нерв киеренкелеге сизелә.

Шуңа тәңгәл рәвештә, эшләнмәнең гомуми композицион рәсеме өч сәнгать образын үз эченә ала: шагыйрь үзе, Нева елгасы һәм Петербург шәһәре.

Икенче этап – шигырь текстының төп мотивларын ачыклау һәм композициянең үзенчәлекләре турындагы күзаллауны киңәйтү.

Бер вакыттагы халәттән икенчесенә күчү мотивы Нева образының түгәрәк рәвешендә булуы аша тапшырыла. Элементларның вакланувы эрү процессын да, лирик геройның эчтән сынуын да чагылдыра.

«С новым временем года
поздравляю себя
и, зрачок о Фонтанку слепя,
я дроблю себя на сто» [1: 162].

Петербург образы композицион үсешнең дәвамы булып тора. Композициядә алар бер-берсен тулыландыралар.

Лирик герой образы композициянең мөһим өлешенә әйләнә. Ул бер үк вакытта балалар кебек яклауга да мохтаҗ, салкын-ironияле дә. Моңа аерым детальләр ярдәмендә ирешелә: борынга эленгән күзлек, мәгънәсез озын күлмәк, пропорциональ булмаган фигура, авыздан төшәм-төшәм дип торган тәмәке.

Композиция төзегәндә, без тыңдашлектән аңлы рәвештә читкә китәбез. Аерым фрагментларның геометрик төгәллек белән урнашуы детальләрнең тәртипсез эшләнеше белән яраша.

Буксир образы – композицияне бәйләп торучы деталь. Шунысы кызык: бу образның мәгънәсе шагыйрь тарафыннан салынган мәгънәгә туры килми. Буксирның бурычы батырларча боз вату түгел, ә сабыр гына йөк тартып бару.

Керамик паннода буксир ике тапкыр пәйда була: фрагментларның берсендә ул үзенең асыл ролен үти. Һәм лирик герой уенчыкка ябышкан бала кебек аны кулыннан ычкындырмый, әйтерсең лә әйләнә-тирә дөньяда ул үзен егылудан саклый торган нәрсәгә тотынган.

«Пятерней по лицу
провожу. И в мозгу, как в лесу –
оседание наста» [1: 162].

Эшләнмәдә соры-зәңгәр төсләр кулланыла. Алар язгы-болытлы Петербург, салкын, сөйкемсез Нева, соры бина образларын гәүдәләндерә. Әмма иң мөһиме – алар лирик геройның икеле-микеле уйларын: аның дөньядан ятсынуын һәм шул ук вакытта дөньяның да үзенә салкынлыгын тоюын чагылдыра.

«В эту зиму с ума
я опять не сошел. А зима,
глядь, и кончилась» [1: 162].

Әмма шагыйрь фигурасы да, аның кулындагы кораб та хәрәкәт итүгә һәм җиңүгә өмет белән тулы. Буксир, авырлык белән булса да, бозны ватып, көчкә-көчкә алга бара.

«Извини же
за возвышенный слог:
не кончается время тревог,
но кончаются зимы.
В этом – суть перемен,
в толчее, в перебранке Камен
на пиру Мнемозины» [1: 162].

Эшләнмә традицион агач рамга түгел, ә җитен арканга утыртылган. Бу очракта игътибарны янәдән корабка юнәлтү бар, һәм шул ук вакытта мондый рам ниндидер төгәлләнүдән кабат хәрәкәт мотивына алып кереп китә.

Эшләнмәдә, керамикадан тыш, агач, шпагат кебек башка материаллар да актив файдаланыла. Алар табигать дөньясына аерылгысыз бәйләнгән. Керамика белән аларны шул берләштерә дә. Димәк, алар бер-берсен органик рәвештә тулыландыралар.

Шулай итеп, шигырь текстының төзелү үзенчәлеген аңларга өйрәтү декоратив-гамәли сәнгать әсәренең композицион, пластик, колористик чишелешен төгәлрәк итәргә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1. *Бродский И.А.* Стихотворения. Таллин: Александра, 1991; Ээсти раамат, 1991. 256 с.

2. *Торонова Е.М.* Живопись как предмет междисциплинарного исследования // Вестник Томского государственного университета. Культурология и искусствоведение. 2013. № 2 (10). С. 130–134.

3. *Шокорова Л.В., Первушина О.В.* Межпредметность как основа целостности процесса обучения декоративно-прикладному искусству // Научно-педагогическое обозрение. 2020. № 4 (32). С. 124–128.

***Махинин Андрей Юрьевич,***
*тарих фәннәре кандидаты, доцент,*
*Казан дәүләт мәдәният институты Инжиниринг үзәгенең*
*нәфис керамика фәнни-экспериментал лабораториясе*
*әйдәп баручы белгече*

***Махинин Андрей Юрьевич,***
*кандидат исторических наук, доцент, ведущий специалист*
*научно-экспериментальной лаборатории художественной керамики*
*Инжинирингового центра Казанского государственного*
*института культуры*

*mahinin@rambler.ru*

УДК 792.071

***Ж.О. Кулмамбетов***

# КАЗАХСТАН ҺӘМ КЫРГЫЗСТАН ТЕАТРЛАРЫНЫҢ ЯШЬ РЕЖИССЁРЛАРЫ ЯҢА МӘГЪНӘ ЭЗЛИ

В последние 10–15 лет в театрах Казахстана и Кыргызстана заметно усилилось обращение режиссеров, особенно молодого поколения, к идеологически ангажированным пьесам советского периода. Представители практически самого младшего поколения театралов XXI века – недавние выпускники театральных учебных заведений, такие как Фархат Молдагали и Гульназ Бальпеисова (Казахстан), Уланмырза Карыпбаев, Арнис Кыдырмышев и Омурбек Израилов (Кыргызстан), – активно начали обращаться к драматургии тоталитарной эпохи. Почти все режиссёры – тридцатилетнего возраста. Они не обременены советской реальностью.

Поэтому при размышлении о причинах и мотивах возникновения такой парадоксальной, на первый взгляд, тенденции на ум приходит известность авторов этих произведений. То есть думаешь: может, заманчивыми являются именно их имена. И Мухтар Ауэзов, и Мустай Карим, и Токтоболот Абдумомунов, и Жалил Садыков в советское время были известны далеко за пределами своих национальных республик. А некоторые из них, как башкир Мустай Карим и казах Мухтар Ауэзов, и вовсе были в первых рядах советских писателей.

Можно ли это называть возрождением драматургии тоталитарной эпохи? Что привлекает молодых режиссеров в пьесах Мухтара Ауэзова, Мустая Карима, Токтоболота Абдумомунова и Жалиля Садыкова – идейно выдержанных советских драматургов?

На эти и другие вопросы попытались ответить в настоящей статье.

**Ключевые слова:** молодые режиссёры, советские пьесы, новый смысл, модернистское действо, рабы традиции, рабы догмы, переосмысление прошлого.

Over the past 10–15 years, theater directors in Kazakhstan and Kyrgyzstan, especially those of the younger generation, have noticeably increased their turn to ideologically charged plays from the Soviet period. Representatives of the youngest generation of 21st-century theatergoers – recent graduates of theater schools such as Farkhat Moldagali and Gulnaz Balpeisova (Kazakhstan), Ulanmyrza Karypbayev, Arnis Kydyrmyshev, and Omurbek Izrailov (Kyrgyzstan) – have begun actively turning to the dramaturgy of the totalitarian era. Almost all of these directors are in their thirties. Some are not even thirty yet. They are unburdened by Soviet reality.

Therefore, when considering the reasons and motives for this seemingly paradoxical trend, the fame of the authors of these works comes to mind. That is, you wonder: perhaps it is their names that are enticing. Mukhtar Auezov, Mustai Karim, Toktobolot Abdumomunov, and Zhalil Sadykov were known far beyond their national republics during the Soviet era. Some of them, like the Bashkir Mustai Karim and the Kazakh Mukhtar Auezov, were even among the foremost Soviet writers.

Can this be called a revival of totalitarian-era drama? What attracts young directors to the plays of Mukhtar Auezov, Mustai Karim, Toktobolot Abdumomunov, and Zhalil Sadykov – ideologically sound Soviet playwrights?

This article attempts to answer these and other questions.
**Keywords:** young directors, Soviet plays, new meaning, modernist drama, slaves of tradition, slaves of dogma, rethinking the past.

2018 елда Астана шәһәрендә уздырылган «Самгау» Халыкара театр фестивાленә театралларның күбесенә бөтенләй таныш булмаган яшь казах режиссёры Фархат Молдагали Петропавел шәһәреннән М. Ауэзов әсәре буенча куелган «Карагёз» спектаклен алып кайта [1: 205–253]. Башта, фестивальнең репертуарын һәм спектакльнең «Карагёз» дип аталуын күрүгә, күпләрдә нигезле сорау туарга мөмкин иде: совет драматургының марксистик-ленинчыл идеология таләпләренә буйсындырылган пьесасы бүгенге көн тамашачысын, бигрәк тә белгечләрне җәлеп итә алырмы, театр аңарда нәрсә тапкан? Аннары парадоксаль хәлләр килеп туа: спектакльне тамашачы (күпчелекне яшьләр тәшкил итә) дулкынланып карый: аларга конъюнктур совет спектакле түгел, ә заманча киенгән Сырым (джинсы чалбардан), Карагёз һәм Нарша катнашында модернистик күренеш тәкъдим ителә. Суперзаманча проблемага дәгъва белдергән героиня (Карагёз) сыланып торган капрон ефәк күлмәктән йөри дияргә була. Әмма эш хәтта костюмнарда гына да түгел: кара фонда (кара кабинет) горизонталь рәвештә тарттырылган ике арканда ике яшь йөрәкнең гаҗәеп, үзәкләргә үтеп керә торган романтик, шул ук вакытта фаҗига тулы мәхәббәт тарихы уйнала. Ә аннары мәсхәрәләнгән, хур ителгән, бөтен кеше җирәнеп караган, физик яктан да, рухи яктан да көчсезләнгән Карагёз яңгыр астында импульсив хәрәкәтләр эчендә ята (яшь актриса Мәдинә Осербаева бик хисле һәм драматик тәэсирле итеп уйный). Тик хыянәтче яшь хатынның (Карагёзның) ире Нарша гына, үзендә көч табып, аны җылы чапан белән капларга батырчылык итә. Бу гамәле бәхетсез ирнең нинди олы йөрәкле, чиксез кешелекле булуын һәм Карагёзны яратуын күрсәтә.

Традицияләр һәм мәхәббәтнең борынгы коллизиясе – яшь режиссёр Фархат Молдагали куйган спектакль әнә шул капма-каршы полюсларда урнаша. Ул сәхнәдән шуны җиткерергә тели: казахлар борынгы бабаларыннан килгән табуны һаман да саклыйлар – аларга җиденче буынга кадәр үз нәселе кешесенә өйләнү һәм кияүгә чыгу тыела. Шуның белән кешеләрнең мәхәббәт иреге һәм бәхеткә хокуклары чикләнә. Әмма режиссёр тарафыннан спектакльгә салынган сәнгати гомумиләштерелгән фикер гадәттән тыш киң булып, тар милли проблема кысаларыннан чыга: кешелек җәмгыяте ни рәвешле, ниндидер хәлләрдән һәм фикерләрдән чыгып, төрле яшәеш кагыйдәләре уйлап таба, соңыннан аларны тотрыклы, какшамас традицияләргә әйләндерә, аннары кешеләр шуларның гөнаһсыз корбаннарына әверелеп, үзләре дә газап чигә. Кеше яшәешенең бөтен парадоксы менә шунда. Һәм Җир тормышындагы мәңгелек конфликтның асылы (элек тә, хәзер дә) шуңа кайтып кала. Казах режиссёрының бу искиткеч спектакле әлегәчә кискенлеген югалтмаган, кешеләрнең нормаль

яшәешенә, шул исәптән яшь гашыйкларның бәхетенә комачаулаган проблеманы (тормышны тоталь догмалаштыру) артык төгәл чагылдыра һәм тамашачыларга бик нык тәэсир итә.

Казах совет драматургы язган иске пьесаның яңа мәгънәсе менә шуңа кайтып кала.

2024 елда Бишкәктә тагын бер яшь, шул ук вакытта Үзәк Азиядә һәм аннан читтә танылып өлгергән кыргыз режиссёры Уланмырза Карыпбаев совет драматургы Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» пьесасын куя. Монысы да күпгасырлык тотрыклы традицияләргә әверелгән догмалар турында. Аталар традициясенең, какшамас догмага әверелеп, хәзер дә уңышлы дәвам итүен белдерү өчен, режиссёр сәхнә метафорасына мөрәҗәгать итә – хәзерге заман яһүдләренә охшатып киенгән яшьләр халык алдында, сакаллар куеп, көлке картларга әвереләләр һәм кешеләрнең җәмгыятьтә үз-үзләрен тоту нормаларын билгели башлыйлар. Бу уңайдан түбәндәге күренешләрне атарга мөмкин: алар (яшь «картлар») мәрхүмнең гаиләсен корбанны бик аз чалуда гаеплиләр һәм «устукан»га (иткә) дип билгеләнгән пакетлар өчен сугышалар, шулай ук өер-өер булып Тәңкәбикәгә ябырылалар. Ә ул аларның басымы астында, ата-бабаларының догмаларына таянып, үз балаларына карата карарлар кабул итәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, Уланмырза Карыпбаев тамашачының игътибарын күп гасырлар элек салынган һәм кешеләрне иллюзор төшенчәләрнең ирекле колына әйләндергән ныклы традицияләргә юнәлтә. Сүз уңаеннан, кайчандыр Ибрайның данлыклы «Ай тотылган төндә» [3: 70–75] спектаклен (анда кыргыз сәхнәсенең күренекле корифейлары уйный) күргән кайбер артистлар үз героинясын гаять зур эчке драматизм белән баеткан көчле трагик актриса Гөлшәрә Дулатова (Тәңкәбикә) [3: 72, 75] һәм үзенең Дәрвишен чын Иблис иткән Сыдыкбәк Җаманов [3: 72, 75] Карыпбаев трактовкасының (төп героиняга мөнәсәбәтле) «йомшаклыгын» бик үк аңлап бетермиләр. Ә Карыпбаев интерпретациясе шуның белән аңлатыла: хәтта хакимлек итәргә яратучан шундый көчле характерлы Тәңкәбикә дә (Гөләйем Каниметова) ата-бабаларыннан килгән гореф-гадәтләргә каршы тора алмый. Алай гына да түгел, Шәфәкъ, Акъегет, Зөбәрҗәт һәм Ишморзаның киләчәктәге язмышларына карата нинди фикергә килүен белдергәндә, ул догма исеменнән сөйли.

Карыпбаевның «Ай тотылган төндә»се – догмага каршы әсәр. Димәк, режиссёрның сәхнә концепциясе буенча түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин:

– догма яшьләрнең (Зөбәрҗәт һәм Акъегетнең) бәхетен урлап, аларны мәңгелек фаҗигага дучар итә;

– кеше кайгысы бәхетенең төп җимергеч көче булган догмалар эчендә югала;

– кеше – догмалар колы һәм корбаны;

– кешеләр белән догмалар идарә итә һәм фаҗиганың асылы шунда.

Шулай итеп, Карыпбаевның «Ай тотылган төндә»се тоташ караңгылык – догмалар алдында сукырларча кол булуның һәлакәткә китерүе хакында. Бу гадәти булмаган тамашаның фаҗигалы дефинициясе шунда.

Режиссёрның оптимистик нәтиҗәсе бер генә: бу караңгылыкны бары тик мәхәббәт кенә җиңә ала. Бәхет, Карыпбаев фикеренчә, иллюзияләр һәм идеаллар дөньясында гына була ала. Мондый финалдан спектакльнең трагик мәгънәсе тагын да көчәя, азатлыкның догмалардан ирешелмәслек дәрәҗәдә ераклыгы ассызыклана. Ул гына да түгел, режиссёр үз концепциясен икенче дәрәҗәгә күчерә: Дәрвиш (мөгаен, ул – Гитлерның прообразыдыр) барысын да үтерергә, юк итәргә өнди. Шул рәвешле, режиссёрның сәнгати фикере буенча, барысы да планета, галәм масштабына күтәрелә.

Бу метафораның мәгънәсен аңлагач, куркыныч була башлый.

Төп фикердән тыш, Уланмырза Карыпбаев спектакле сәхнәдәге әлеге кызыклы һәм тирән күренешнең барлык образлы-концептуаль төзелешенә кагылышлы бик зур метафорик нәтиҗәләргә китерә. Алар фаҗигалы тамашаның сәнгати тукымасы белән органик рәвештә яраша. Бу сәхнә тарихының башында Акъегет (Өмүрбәк Израилов) һәм Зөбәрҗәт (Анара Таалайбәк кызы) мәһабәт гәүдәле искиткеч матур затлар булып күренәләр, ташып торган көчле яшьлек энергиясе аларга тирән романтизм, саф мәхәббәт бирә, спектакльнең прелюдиясенә якты оптимистик рух өрә. Шул ук вакытта бу рух, бу матурлык, ә иң мөһиме – эчтәлекле метафора, спектакль барышында аларның мәхәббәт һәм хыялларының фаҗигалы рәвештә җимерелүенә капма-каршы куела, гаепсезгә борынгы традицияләр корбаны булган геройларның күңелен яралый һәм төзә алмаслык газаплар китерә.

Бу тарихның тирән фаҗигасын турыдан-туры чагылдырган тагын бер метафорик күренеш – Шәфәкъ белән Зөбәрҗәтнең төнге очрашуы. Ул пластика ярдәмендә хәл ителгән һәм кеше табигатенең инстинктив-хайвани асылына кагыла. Көндәшләр очрашуын режиссёр ике ерткыч хайванның табыш өчен көрәше рәвешендә, искитмәле хореографик хәрәкәтләр һәм героиняларның бер-берсенә ярсулы мөнәсәбәтләре аша хәл итә. Кешеләр дә, ерткыч хайваннар кебек, үз табышларын бирергә теләмиләр – аларда да беренчел, ерткычлар инстинкты уяна.

Гаҗәеп метафора. Әмма кеше хайваннардан акылга ия булуы белән аерыла. Режиссёр аларның көрәшенә Шәфәкъның, татулашу билгесе буларак, Зөбәрҗәткә яулык бүләк итүе белән нокта куя.

Бу спектакльдә иң куркыныч метафора – Шәфәкъның чарасызлыктан, төзә алмаслык фаҗигадан гаилә учагындагы казанда батуы. Гаилә мөнәсәбәтләре тарихында мәңгелек догмалар аркасында булган шундый фаҗигалар санап бетергесез. Шәфәкъ фаҗигасы – шуларның берсе. Сүз уңаеннан, актриса Гөлнара Сатарова Шәфәкъ ролен бик яхшы башкара, героинясының күңел төпкелендәге хис-кичерешләрен ачып бирә.

«Ай тотылган төндә» спектаклендә догмаларның вакыт белән чикләнмәгәнлеге хәтта декорацияләр, костюмнар һәм җырлар аша да ассызыклана. Мәсәлән, таш сыннар (бу бик еракта калган борынгы чор) һәм хор (эшләпәле, ялган сакаллы әфәнделәр, алар соңгырак чорны билгелиләр, ягъни заманчалыкны чагылдыралар) кеше яшәешенең бөтен катлаулы тарихын бик тиз арада берләштерәләр. Шулай итеп, Уланмырза Карыпбаев догмаларның вакыт белән чикләнмәү традициясен гомумиләштерә. Хәтта спектакльдә кулланылган заманча «Былбылым» һәм «Буй-буй» җырлары да Карыпбаев спектакле контекстында күптән үткән көннәр традицияләре корбаннары кичергән күңел газапларының фаҗигалы аһәңе булып яңгырый, һәм сүз уңаеннан, бүгенге көнгәчә дәвам итә.

Төп фикерне белдерү өчен, режиссёр бик күп кызыклы нәрсәләр уйлап таба. Спектакльнең катлаулы, тәэсирле-образлы партитурасы шуннан килеп чыга.

Карыпбаев үзенең яраткан темасына – «Күн кармаган бала» («Кояш тоткан бала») спектакленнән башлангыч алган гаилә һәлакәте темасына кагылмаса, Карыпбаев булмас та иде [4: 474–477]. Бу спектакльдә барысы да гаилә фаҗигасы белән тәмамлана: Басыт, белмичә, үзенең никахсыз туган улы Жусупны (дөреслек сөюче) үтерә; ә Дабдырны Жусупның әнисе очраклы рәвештә таба. Ул аны кайчандыр, яшертен генә, үлсен дип калдырып китә, ягъни чынлыкта ул кояш тоткан малайның үз әбисе була. «Ай тотылган төндә» әсәрендә дә шундый ук хәл – Рысколбәй белән Тәңкәбикә яшерен мәхәббәтенең җимеше булып Дивана дөньяга килә. Ә Тәңкәбикәнең улы Акъегеткә Рысколбәйнең кызы гашыйк була – язмышның аларга биргән җәзасы шундый.

Бу сызык та спектакльнең фаҗигалылыгын көчәйтүдә уңышлы эшли.

Сүз уңаеннан, У. Карыпбаевның «Ай тотылган төндә»се – ул бөтен заман театрларының конгломераты. Анда антик трагедия һәм Урта гасырлар урам театры принциплары барлык символик реквизитлары белән бергә укмашкан. Биредә төрле чорлар театр сәнгате эстетикасы буталган. Антик бәйрәм принциплары – борынгы орхестраны хәзерге бию төркеме (безнең замандашлар) тутыра. Монологлар да антик театрдагы кебек – ялгыз, аерым. Шул ук вакытта сөйләшүләр көнкүреш сөйләм теленә якын, ягъни модернизм театры икәнлеге сизелә. Шуңа күрә бу антик-урта гасыр һәм ультразаманча театрда драматик, трагик һәм модернистик театрларның сәнгати-тәэсир чаралары бар.

Һәм мондый үзенчәлек шулай ук спектакльнең сәнгати гомумиләштерелгән мәгънәсен тулыландырачак – ул вакыт белән чикләнмәячәк.

Йомгаклап шуны әйтеп була: Т. Абдумомунов исемендәге Кыргыз дәүләт академия драма театрында мәгънәсе буенча бик тә эчтәлекле, сәнгати-тәэсир чаралары ягыннан гадәттән тыш мавыктыргыч, чын интеллектуаль спектакль барлыкка килә.

2024 ел ахырында кыргыз режиссёры, популяр театр һәм кино артисты Арнис Кыдырмышев тагын М. Ауэзовка – аның «Каралы сылу» дигән атаклы хикәясенә мөрәҗәгать итә [2: 121–133]. Спектакль «Тол хатын» дип атала. Арнис Кыдырмышев бу тарихны табигый дәрт һәм уйлап чыгарылган кануннар, догматик табу арасындагы кискен бәрелешкә әйләндерә. Яшь, чибәр, энергиясе ташып торган хатын-кыз, гореф-гадәт таләпләре буенча, авыр газап тулы алты ел дәвамында, кара киемен салмыйча һәм үзен ир-атлар белән аралашудан тыеп, көн саен табигый ярсулы дәртен акрынлап бастырып, тол хатын булып, матәм халәтендә яши. Спектакль шул турыда. Бу аның өчен газап һәм өметсезлек тулы коточкыч җәза була. Шул рәвешле, ул үзенең чәчәк кебек яшьлек елларын ниндидер уйлап чыгарылган традицияләрнең корбаны итә.

Арнис Кыдырмышев куйган спектакльдән аңлашылганча, ул алты ел дәвамында гомеренең һәр көнен, бикләнеп, акылдан язу чигенә җитеп үткәрә. Бу образның тирән фаҗигасын кыргыз сәхнәсенең әйдәп баручы артисткасы Альбина Имашова гаять тәэсирле итеп ача.

Спектакльдә барган вакыйгалар контекстында, совет язучысының иске хикәясен А. Кыдырмышевның сәхнәгә куюын чын мәгънәсендә догмаларга каршы фетнә күтәрү дип атарга мөмкин.

Бу контекстта (яңа мәгънә эзләп) А. Кыдырмышевның борынгы халык эпосы буенча эшләнгән «Эр Төштүк» дип аталган тагын бер гадәти булмаган постановкасын билгеләп үтәргә кирәк [5]. Спектакль Т. Абдумомунов исемендәге Кыргыз милли академия драма театры сәхнәсендә шул ук 2024 ел башында куела.

Жанр ягыннан спектакль – комедия-фэнтези. Академия театры өчен гадәти булмаган уен стиле шулай сайлана. Ул метафоралар куллану, төп образларның роль характеристикаларын арттыру белән аерылып тора. Алар хәзерге тамашачыларга инде таныш. Куючы режиссёр популяр жанрны кыргызларның шулай ук данлыклы фантастик эпосы өчен кулланып, милли сәнгать мирасын күпсанлы тамашачыларга җиткерә, шул рәвешле аңа универсаль (гомумкешелек) эчтәлек бирә. Әлеге гадәти булмаган куелышның төп мәгънәсе шунда.

Режиссёр фикеренчә, борынгы эпос бөтенләй яңа мәгънә ала. Бигрәк тә халык эпосының традицион герое яңача интерпретацияләнә. Төштүк (Бәхтияр Шаршенбаев) ныклы мораль-әхлакый, ә иң мөһиме – ир-ат позициясе булган замана егетенә әйләнә. Аның хәзерге яшьләр аудиториясенә таныш көлкеле хәрәкәтләрен һәм «блатной» йөрешен залдагы тамашачылар бик ошаталар һәм рәхәтләнеп көләләр. Шулай ук җир асты цивилизациясе хакиме – Күк дию (Зәңгәр алып) (Эржан Осмонов) образы да үзенчәлекле: ул үз-үзен тотышы белән хатын-кызларны хәтерләтеп, көлкеле халәт тудыра, ирексездән безне бүгенге кеше популяциясе эчендә барган заманча күренешләр белән параллельләр үткәрергә мәҗбүр итә. Шул ук вакытта бу – көлдерү өчен мәзәкләнү генә түгел. Аның төгәл мәгъ-

нәви нигезе бар: ул игътибарны бүгенге яшәешнең һәркемгә билгеле кайбер моментларына юнәлтергә тели.

Болар арасында Альбина Имашева иҗат иткән Мастан (сихерче карчык) образына бөтенләй яңа мәгънәви акцент ясала, ул – «Эр Төштүк»тәге аны явыз һәм кара көчләр символы буларак характерлаган традицион эпик һәм сәхнә интерпретацияләренә капма-каршы. Зифа буйлы, матур кыяфәтле Мастан, киресенчә, Гөләйем белән Тёштюкне (хатын-кыз белән ир-атны) өйләнештерү өчен бөтен көчен куючы хәзерге заман яучысы (Хануманы искә төшерик) булып күренә. Монда, минемчә, аның Мастаны, хатын-кызны хәтерләткән Күк Дию һәм комсыз, саран Элеман образларына каршы куелып, сәламәт һәм акыллы башлангычны гәүдәләндерә. Аның Төштүккә карата барлык тырышлыклары нәкъ менә ир-ат һәм хатын-кызны (Төштүк һәм Гөләйем) кавыштыру теләге белән аңлатыла.

Ә төп йөкләмәне режиссёр алтмыш яшенә кадәр ир-атның үзе янына килүен көтеп утырган Гөләйем (Күк Дию кызы; Мээрим Касаболотова) образына йөкли. Аңардан ул илле бала табарга әзер! Пробиркадан яки бер җенесле никахтан түгел (бу мөмкин түгел диярлек), ә чын ир-аттан. Мээрим Касаболотова Гөләйемне чын лирик-буффон гротеск чигендә уйный. Ул – карт карчыкка бөтенләй охшамаган, сөюен чын ир-ат белән уртаклашырга теләгән гүзәл, хыялый хатын-кыз. Шул ук вакытта режиссёр актриса Гөләйем катнашкан күренешләрдә пародияне көчәйтә, аларда театраль штамплар өстеннән сәхнә эстетикасы, шул исәптән милли эстетика тарихыннан алынган җиңелчә ирония сизелә. Бөтен куелыш пародиягә һәм уенга корыла. Һәм бу – спектакльне карнавал кебек чын театр тамашасына әверелдерә.

Спектакль ир-атка шашкын мәхәббәт турында. Шуңа күрә, ышанып әйтә алабыз: әлеге постановкада, мәгънәви яктан, заманның актуаль проблемалары күтәрелә, ә театраль-куелыш планында ул – менә дигән нәтиҗәгә китергән кызыклы иҗади эзләнү.

Дефиниция: ни өчен кешеләр гасырлар дәвамында формалашкан кануннар корбаны була? Бу мәңгелек сорау хәзерге режиссёрлар Фархат Молдагали, Уланмырза Карыпбаев һәм Арнис Кыдырмышевны бердәй борчый. Бу – аларның чын сәнгати, алай гына да түгел, гражданлык позициясе. Шуңа күрә шундый отышлы иҗади нәтиҗәләр килеп чыга. Парадокс шунда ки, бу эштә аларга бары тик совет пьесалары гына ярдәмгә килә, безнең заманда догмаларның һәлакәткә китерүен сурәтләгән драмалар язылмый.

**Әдәбият**

1. *Ауэзов М.* Карагоз. Трагедия: в 4 актах, 7 картинах // Мухтар Ауэзов. Собрание сочинений: в 5 т. Т. 4. М.: Худож. лит., 1975. 696 с.

2. *Ауэзов М.* Красавица в трауре: Рассказ // Мухтар Ауэзов. Собрание сочинений: в 5 т. Т. 1. М.: Худож. лит., 1973. 565 с.

3. *Кулмамбетов Ж.* Режиссёр Бообек Ибраев. Бишкек: Принт-экспресс, 2015. 160 с.

4. *Кулмамбетов Ж.* Кыргыз театры. Бишкек: Оптима Технолоджис, 2023. 536 с.

5. Эр Төштүк: Эпос / сост.: О. Сарыпбеков, М. Мукасов, М. Колбаева. Бишкек: Турар, 2024. 527 с.

***Кулмамбетов Жаныш Османович,***
*культурология кандидаты, Б. Бейшеналиева исемендәге Кыргыз дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының актёрлык осталыгы һәм режиссура кафедрасы профессоры, Кыргызстан Театр әһелләре берлеге президенты, Кыргызстан Республикасының халык язучысы*

***Кулмамбетов Жаныш Османович,***
*кандидат культурологии, профессор кафедры актёрского мастерства и режиссуры Кыргызского государственного университета культуры и искусств им. Б. Бейшеналиевой, президент Союза театральных деятелей Кыргызстана, народный писатель Кыргызской Республики*

*tr_ademi@mail.ru*

УДК 75.02.322

***Т.М. Бердникова,***
***Л.М. Шкляева***

# АПАС РАЙОНЫ РӘССАМНАР ИҖАТЫНДА (пленэр мисалында)

В данной статье рассматривается положительный опыт проведения пленэра, как для его участников-художников, так и для населения тех мест, где он проводится. Описываемый в публикации пленэр был организован в 2023 г. Союзом художников Татарстана в Апастовском районе республики для российских живописцев и графиков. Куратором мероприятия выступил М.М. Мингазов, советский и российский художник, народный художник и заслуженный деятель искусств Республики Татарстан.

Основной задачей данного пленэра стало раскрытие своеобразной привлекательности апастовской земли живописными средствами. Участникам были предложены темы, отражающие историю и культуру этого района. Художники стремились запечатлеть природное богатство края, виды традиционных жилых строений и мечетей, портреты местных жителей в самобытной среде и фольклорные сюжеты локального характера. Поскольку пленэр по определению предполагает творческую работу на открытом воздухе при естественном освещении, стимулирующую креативный потенциал, то каждому участнику указанного процесса удалось создать интересные произведения, которые привлекли доброжелательное внимание общественности Апастовского района. Благодаря им у жителей произошло обновление восприятия привычного окружения в позитивном направлении, что способствовало повышению чувства гордости за свою малую Родину. Приезжие участники пленэра по возвращению домой демонстрировали пленэрные работы и делились интересными впечатлениями с окружающими, чем стимулировали желание посетить Апастовский район у потенциальных туристов. В публикации описывается культурное своеобразие района, как источник вдохновения для мастеров. Акцентируется внимание на каких именно темах местной истории и культуры остановили свой выбор участники данного пленэра.

**Ключевые слова:** пленэр, Татарстан, художники, Апастовский район, арт-туризм.

This article examines the positive experience of conducting a plein air, both for the artist participants and for the local communities. The plein air described in this publication was organized in 2023 by the Union of Artists of Tatarstan in the Apastovsky District of the Republic for Russian painters and graphic artists. The event was curated by M.M. Mingazov, a Soviet and Russian artist, People's Artist, and Honored Artist of the Republic of Tatarstan.

The main goal of this plein air was to reveal the unique appeal of the Apastovsky region through painting. Participants were offered themes reflecting the history and culture of the region. The artists sought to capture the region's natural wealth, views of traditional residential buildings and mosques, portraits of local residents in their unique environment and local folklore. Since plein air painting by definition involves creative work outdoors in natural light, stimulating creativity, each participant in this process managed to create engaging works that attracted the enthusiastic attention of the Apastovsky District community. Thanks to these works, residents experienced a

positive change in their perception of their familiar surroundings, which contributed to a heightened sense of pride in their small homeland. Upon returning home, visiting plein air participants displayed their plein air works and shared their interesting impressions with others, thereby stimulating potential tourists to visit the Apastovsky District. The publication describes the district's cultural diversity as a source of inspiration for the artists. It also highlights the specific themes of local history and culture that the plein air participants chose.

**Keywords:** plein air, Tatarstan, artists, Apastovsky District, art tourism.

Рәссамнарның табигатьтәге объектларны натурадан рәсемгә төшерүен күздә тоткан пленэрга (фр. plein air «саф һава») чыгу традициясе XIX гасырның беренче яртысыннан ук килә: ул Барбизон нәкышь мәктәбе эшләгән чорда башлангыч ала һәм алга таба импрессионистлар иҗатында ныклы позицияләр яулый. Бу уңай тәҗрибәне Россия рәссамнары да кабул итә. Пленэрда К. Коровин, В. Серов, А. Саврасов, Н. Фешин һ. б. уңышлы эшли. Шул вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр пленэр рәссамнарның һөнәри үсеш процессында мөһим өлеш кенә түгел, бәлки ышанычлы материалга таянган иҗат планнарының әһәмиятле чыганагын тәшкил итә. Хәзерге заманда пленэр оештыручылар аларны үткәрү мөмкинлеген ничек тә табарга тырышалар, әйтик, җәмәгатьчелек һәм идарә аппараты вәкилләрен җәлеп итеп, аларның ярдәменнән дә файдалалар.

Шул рәвешле, җирле җитәкчелек ярдәме белән 2023 елның июнендә Татарстан Рәссамнар берлегенең 44 нче пленэры старт ала. Бу юлы ул республиканың башка районнарындагы кебек үк уникаль, рәсми рәвештә танылган мәдәни мирас объектлары урнашкан Апас районында узды. Әлеге төбәктә җирле халык өчен әһәмияте зур булган башка «һәйкәлләр» дә бар [3]: аларга Апас районының төрле үзенчәлекле һөнәрчелек эшләнмәләре, шулай ук җирле осталар образлары керә. Әлеге матди булмаган «һәйкәлләр» район үсешенә үз өлешен керткән танылган шәхесләрне: укытучыларны, табибларны, авыл хезмәтчәннәрен, хәрбиләрне һ.б.ны каһарманлаштырудан гыйбарәт.

Уникаль мирасны төрле ысуллар белән саклап калырга һәм аңа җәмәгатьчелекнең, киләчәк буыннарның игътибарын төрлечә җәлеп итәргә мөмкин. Әлеге пленэр – шуны максат иткән чараларның берсе. Анда катнашучылар үз әсәрләрен мәдәни хәтерне теркәргә ярдәм итүче сәнгати иҗат нәтиҗәсе буларак карыйлар [1]. Рәссамнар һәм графиклар пленэрда үз миссияләрен түбәндәгечә формалаштыралар: натурадан ясалган этюдларга таянып, районның мәдәни мирас объектларын гәүдәләндерү, биредә барган тарихи вакыйгаларның һәм процессларның мәгънәләрен актуальләштерү, алар белән бәйле шәхесләрнең портретларын, шулай ук корылма, урам, авыл һәм табигать күренешләрен сурәтләү [2].

Бу мәкаләнең максаты – пленэр эшчәнлеген сынлы сәнгать әсәрләре иҗат итү буларак кына түгел, ә хәзерге заман рәссамнарының пленэр уздырылган район мәдәниятенә керткән өлеше итеп тә карау. Анда Россия рәссамнары үз әсәрләрен җирле тарихка һәм мәдәниятка

(бу очракта – Татарстан Республикасының Апас районы) караган материалларга таянып иҗат итәләр. Фәнни яңалык менә шуны колачлаган пленэр тәҗрибәсен тасвирлаудан гыйбарәт. Мәкаләнең җәмәгатьчелек һәм тиешле эшчәнлек өлкәләрендәге белгечләр өчен дә гамәли әһәмияте зур.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу проектны гамәлгә ашырганда, рәссамнар район территориясенә, аның табигый үзенчәлегенә һәм анда яшәүче халыкның характерлы менталитетына зур әһәмият бирәләр. Булачак әсәрләрнең авторлары, аутентик мохиткә чумып, иҗади импульс алалар. Шулай итеп, районның мәдәнияте һәм тарихы белән бәйле темаларны чагылдырган фикер-идеяләр туа һәм алар төрле сәнгать чаралары ярдәмендә гәүдәләндерелә.

Бу мәкалә өчен материал булып пленэр процесслары, анда катнашучылар белән әңгәмәләр һәм әсәрләр белән аларны иҗат итү барышында ук танышу хезмәт итте. Кыр тикшеренүләре, сәнгать белемендәге чагыштырма анализ һәм аның нәтиҗәләрен гомумиләштерү методлары кулланылды.

Пленэрда катнашучыларның күбесе үз тәэсирләре, фикерләре белән уртаклашты, шуларның берсе – Череповецтан килгән сәнгать белгече һәм рәссам Филиппова Вера Ивановна. Ул Апас авылының мәдәни мирасында Татарстан һәм Россия тарихындагы вакыйгаларның чагылыш табуын билгеләп үтте. Биредә халыкчан традицияләрне һәм заманчалыкны органик рәвештә берләштергән иң яхшы тенденцияләр урын ала.

В.И. Филлипова бу пленэрга дәүләтебезнең төрле почмакларыннан җыелган рәссамнарның татар милли стилендә төзелгән һәм агачка кисеп-уеп бизәк төшереп эшләнгән үзенчәлекле авыл йортларын, уңайлы парк зоналарын һәм Апас районы табигатенең матурлыгын күреп гаҗәпкә калулары турында сөйләде.

Бу рәссамнарның күбесе натурадан күчереп ясау өчен традицион йортларны сайлаган. Череповецтан килгән рәссам Кондратенко Владимир Анатольевич та шулар исәбенә керә. Ул мондагы мәчетләрнең үзенчәлекле матурлыгы турында тәэсирләнеп сөйли, һәм бу аны югарыга омтылган әлеге гыйбадәтханәләренең якты образларын да колачлаган пейзаж язарга рухландыра. Рәссам аларны полотнога шундый итеп урнаштырган ки, алар җылы алтынсу төсләргә чумган башка йортлардан өскәрәк калкып, композицион үзәк тәшкил итәләр.

Кояш яктысында урамда эшләгән В.А. Кондратенко халыкның кунакчыл һәм игелекле булуына игътибар итә, аның фикерен пленэрда катнашкан Малышева Любовь Викторовна раслый. Ул Апаска Пермь краеннан килә һәм ачык һавада матур этюдлар ясый. Беркадәр вакыттан соң ул, Россиянең башка төбәкләрендәгегә караганда, Татарстан хөкүмәте рәссамнарга күбрәк игътибарлы, дигән нәтиҗәгә килә. Л.В. Малышева Апаска кергәндәге манзарага соклана. Ул үзен дулкынландырган шушы күренешне киндердә ачык контраст төсләрдә сурәтләгән.

Татарстанның Чирмешән авылыннан Вилданов Фәйзелхак Габделхак улы иҗади бурычны башкача хәл итә. Ул Апаска якын гына урнашкан Кызлар тавы турындагы риваятьләр белән кызыксына һәм аның пейзажын чынбарлыкка туры китереп, җәйге яшеллеккә хас төрле төсләрне кулланып сурәтли. Бу тауның сере Лениногорск рәссамы, педагог Крылова Нина Сергеевнаны да үзенә җәлеп итә. Ул бу теманы чынбарлыкка якын итеп, әмма тауда яшәүче стильләштерелгән серле затларга урын калдырып, күптөсле гүзәл сюжет композициясе ярдәмендә ача. Апас районына беренче мәртәбә килгәч, ул биредә яшәүче кешеләрнең ярдәмчеллегенә, авыл күренешләренең гүзәллегенә һәм һәр туар таңны сихри серлелеккә күмгән иртәнге томанга соклана, болар барысы исә аның иҗади фантазиясен активлаштыра.

Лениногорскидан рәссам Таманян Агуник Жоржиковна да бу пленэрда шундый ук хис-халәтләр кичерә. Аның сүзләренә караганда, Апас үзенең ачык йөзле кешеләре, үзенчәлекле авыл урамнары белән заманча кечкенә шәһәрчекне хәтерләтә. Апас яшьләре дә үз районнарының тарихы һәм мәдәнияте белән горурланырга һәм аны үстерүгә үз өлешләрен кертергә тиеш, дип ассызыклый рәссам А.Ж. Таманян. Ул татар актрисасы, җырчы һәм композитор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Апас районының Тутай авылын аеруча яраткан Сара Садыйкова (әнисе Бибигайшә шунда туган) образын гәүдәләндерүгә алына [4]. А.Ж. Таманян бу авыл күренешләрен сурәтләп, тынычлык һәм тынлык тойгыларын чагылдырып, уйлаганнарын этюд эше ярдәмендә чынга ашыруга ирешә.

Түбән Камадан рәссам Әфләтунов Марат Сәгадәт улы хәзерге вакытта Апаста яшәүче танылган кешеләрнең график портретлары сериясен ясарга карар кыла. Ул аларның тормышын күзәтә, сөйләшә-аралаша, һәм нәтиҗәдә эшләрендә тышкы охшашлыкны гына түгел (авыл халкы өчен бу бик кадерле), бәлки аерым кешеләргә генә хас характерлы үзенчәлекләрне дә чагылдыра.

Яшел Үзәннән Новиков Владимир Николаевич, пленэрда катнашучылар белән бергә Апастагы туган якны өйрәнү музее экспозициясендә гомерен хезмәткә багышлаган авыл хатыны – Хезмәт Герое Мәгъсүмә Садри кызы Кәлимуллинаның фотосурәтен күреп соклана. Аңарда шунда ук бу хатынның портретын ясау теләге туа. Рәссам хәтта портретны күз алдына да китерә. Ул пленэрның уңышын көтелмәгән темаларның күңелдә яңгыраш табуы белән бәйләп аңлата.

Казан рәссамнары Татьяна һәм Юрий Бердниковлар да авыл табибы образын тудыруга беренчел этәргечне биредә ала. 1960 елларда Апас районы Шонгат авылы хастаханәсендә эшләгән легендар хирург Борис Борисович Мосихинны алар яхшы беләләр. Казан медицина институтын тәмамлаганнан соң, ул бу районга эшкә җибәрелә, һәм килүенең икенче көнендә үк аңа керосин лампасы яктысында бер баланы ана карыныннан ярып алырга туры килә. Операция уңышлы уза: ана да, сабый бала да исән кала. Ул коткарган авырулар исемлегендә алар – беренчеләр. Ямь-яшел үләннәр, яңа сөрелгән басу-кырлар фонында язгы җылы төсләр белән ясалган картинада бүрәнәдән са-

лынган хастаханәнең агач капкасы янында яшь табиб басып тора. Бу уникаль йорт 1883 елда земство акчасына төзелә. Ул 2004 елда тулысынча янып беткән [4].

Апаста Татарстан Рәссамнар берлеге тарафыннан оештырылган һәм үткәрелгән пленэрның әһәмияте гаять зур. Тәҗрибәле рәссамнар иҗади импульс һәм аны гамәлгә ашыру мөмкинлеге алдылар. Дустанә, ышанычлы вазгыять барлыкка килү аеруча сокландыра: яшь рәссамнар бергә катнашкан өлкәнрәк буыннан күп нәрсәгә генә түгел, бәлки тәнкыйтьне дә дөрес һәм урынлы кабул итәргә өйрәнә. Апаста булу аларны профессиональ яктан үстерә. Килгән рәссамнарның төбәктәге пейзажлар, тарихи сюжетлар белән кызыксынуын күреп, район халкы да табигать күренешләренә, таныш авылдашлары образларына бөтенләй башкача карый башлый.

Апас районында булган рәссамнар күпсанлы пленэр этюдлары гына түгел, алар нигезендә җирле тарих һәм мәдәният белән бәйле темаларга тулы реалистик әсәрләр (пейзажлар һәм портретлар), шулай ук бу төбәкнең мифологик, дини, этномәдәни символларына бай картиналар да иҗат итәләр. Шул рәвешле, рәссамнар Татарстанның Апас районы мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертәләр.

**Әдәбият**

1. *Рабилова З.Ж., Головачева Н.П.* Специфика творческой деятельности в пленэрной живописи // Омский научный вестник. Социально-экономические и общественные науки. № 1 (135), 2015. С. 135–137.

2. *Ляхова Н.Б., Ерёмкин Д.И., Лебедева О.Е.* Прогнозирование развития туристских предприятий в современных условиях // Вестник Алтайской академии экономики и права. 2023. № 8–1. С. 88–92.

3. *Сункишев А.* Апастовская историко-краеведческая энциклопедия. Т. 1. Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Казань: Респ. центр мониторинга качества образования, 2013. 231 с.: ил.

4. *Сункишев А.* Апастовская историко-краеведческая энциклопедия. Т. 2. Населенные пункты. Казань: Школа, 2014. 228 с.

***Бердникова Татьяна Михайловна,***
*В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты профессоры*

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Бердникова Татьяна Михайловна,***
*профессор Казанского инновационного университета имени В.Г. Тимирясова (ИЭУП)*
*tberdnikova1958@mail.ru*

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*кандидат искусствоведения, старший научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*luda-next@yandex.ru*

УДК 372.881.1

***Габдрахман Сәгъди***

# ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ СОВЕТ МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ АНЫ УКЫТУ МЕТОДЛАРЫ

Литературовед, критик, педагог Габдрахман Сагди (Сагдиев Габдрахман Гайнанович (1889–1956) – многогранная личность, внесшая неоспоримый вклад и в развитие татарского языка и литературы. Научные труды ученого в области литературоведения, языкознания, педагогики не теряют актуальности и на сегодняшний день.

Вниманию читателей предлагается один из трудов ученого – «Литература и методы ее преподавания в советских школах второй ступени», где представлены тезисы докладов по наиболее продуктивным методам обучения татарской литературе в школах, педтехникумах и рабфаках. Преподавание родного языка и литературы, правильная организация учебно-методического процесса, по определению Г. Сагди, являются ключевыми факторами, влияющими на становление интеллектуально-духовного потенциала учащихся, формирование личностных качеств и традиционных ценностей.

**Ключевые слова:** Г. Сагди, татарская литература, национальное образование, методика преподавания, программы.

Literary critic, teacher Gabdrakhman Sagdi (Sagdiev Gabdrakhman Gaynanovich (1889–1956)) is a multifaceted personality who made an undeniable contribution to the development of the Tatar language and literature. The scientific works of the scientist in the field of literary studies, linguistics, and pedagogy do not lose their relevance today.

Readers are offered one of the works of the scientist – “Literature and methods of its teaching in Soviet schools of the second stage”, which presents the abstracts of reports on the most productive teaching of Tatar literature in schools, pedagogical colleges and vocational schools. Teaching of the native language and literature, the correct organization of the educational and methodological process, according to G. Sagdi, are the key factors influencing the formation of the intellectual and spiritual potential of students, the formation of personal qualities and traditional values.

**Keywords**: G. Sagdi, Tatar literature, national education, teaching methods, programs.

*Күренекле әдәбият галиме, лингивист, методист Габдрахман Гайнан улы Сәгъдиев (1889–1956) – 1908 елларда әдәбиятка килеп, татар теле һәм әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Үзеннән соң бай мирас калдырган галимнең киң колачлы эшчәнлеге, фәнни хезмәтләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый, фикер-карашлары, тегe яки бу хәлләргә бәясе заман галимнәре өчен дә әһәмиятле булып, билгеле бер нәтиҗәләр ясаганда терәк булып тора.*

*Әдип мирасы белән укучыларны таныштыру җәһәтеннән дә эш тукталмый. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әзерләгән «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 22, 23, 24 чыгарылышлары тулаем Г. Сәгъдинең фәнни эшчәнлегенә багышланды. Әлеге басмаларда галимнең 1926 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы», «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» кебек зур хезмәтләре, шулай ук 1912–1932 елларда матбугат битләрендә, аерым җыентыкларда басылган фәнни мәкаләре, язмалары («Символизм турында», «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» һ. б.) гамәлдәге язуда, аңлатмалар белән тәкъдим ителде.*

*Билгеле булганча, Г. Сәгъди хезмәт юлын укытучы булып башлый, шул ук вакытта үзенең фикер-тәкъдимнәрен матбугатта да яңгырата. Аның педагогик, гыйльми эшчәнлеге Октябрь инкыйлабыннан соң тагын да күтәрелеп китә. Мәгълүм ки, Г. Сәгъди, авыруы сәбәпле, Урта Азия якларына дәваланырга китә. Ләкин биредә дә укытучылык эшен ташламый, укыту белән беррәттән, күпсанлы дәреслекләр яза, газета-журналларда языша. 1925 елда Г. Ибраһимов чакыруы буенча кабат Казанга кайта – Татар коммунистлар университетында татар теле һәм әдәбияты укыта, аннан Казан Көнчыгыш педагогия институтына күчә, фәнни эшен дә дәвам итә, матбугатта, аерым җыентыкларда татар теле һәм әдәбиятын укыту, укыту методикасы буенча язмалары басыла, мәгариф өлкәсендәге фикерләре белән уртаклаша. 1927 елда аның, аерым җыентык булып, «Икенче баскыч совет мәктәпләрендә әдәбият һәм аны укыту методлары» исемле күләмле мәкаләсе дөнья күрә. «Тел-әдәбият дигән нәрсә – кешелек тормышында иҗтимагый хадисәләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе», «Татар укучысы үз мәктәбендә үз теле, үз әдәбияты аркылы эмоциональ тәрбия алып чыгарга тиеш булган шикелле, ул гамәли тормышында да үз теле, үз әдәбияты аркылы эш итә алырлык, шуның аркылы социализм юлында үзенең иҗтимагый фикер тәрәккыйсен мәктәптән чыккач та һаман үз башына дәвам иттереп китә белерлек бер дәрәҗәдә әдәбият белеме, әдәбият техникасы белән коралланып чыгарга тиеш» дип күрсәтеп, әлеге предметның әһәмиятен, урынын, үзенең аерым хосусиятләрен билгели. Гомумән, татар педагогикасы, татар мәгарифенең үсеш юлларын, барышын күзаллау, төрле елларда игътибар үзәгенә алынган мәсьәләләр, килеп туган кыенлык-каршылыклар һәм аларны чишү юллары, аерым алганда, әдәбият укыту методикасының торышы һ. б. ны өйрәнгәндә шундый язмалар төп чыганакларның берсе булып торалар.*

*Фәнни даирәгә мәкалә гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, сүзлек-аңлатмалар һәм кайбер кыскартулар белән тәкъдим ителә.*

## Урта тип совет мәктәпләрендә әдәбият

### *Икенче баскыч совет мәктәпләрендә әдәбият һәм аны укыту методлары*

*(Доцент Габдрахман Сәгъди докладының тезисы)*

Мәктәпләрдә әдәбиятның тоткан урыны, максаты, мөндәриҗәсе[1], программы, укыту методы.

1. Мәктәп эшләренең мөндәриҗәсе, методы гомуми икътисади, иҗтимагый төзелеш нигезендә мәктәпләр өчен куелган гомуми төп максатлар белән билгеләнә. Мөндәриҗә методлары исә, үз нәүбәтләрендә, мәктәптә тәрбия-укыту эшләренең ничек оештырылырга кирәклеген билгеләтәләр.

Мәктәп баланың, яшүсмернең бөтен шәхесен һәммә ягы белән, тулы көенчә ихата кылырга тиеш. Шуның белән бергә, моннан совет мәктәбенең белем урыны гына түгел, тәрбия урыны да булганын ачык аңлый алабыз.

Бу максат безгә совет мәктәбендә белем алу, тәрбияләнүнең төп мөндәриҗәсен һәм аның методын да ачык билгеләп бирә: ***мөндәриҗә*** – реаль вакыйгыйлык, реаль тормыш, ***метод*** – «баладан дөньяга» бару нигезендә марксизм методы.

2. Тел-әдәбият дигән нәрсә – кешелек тормышында иҗтимагый хадисәләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе. Кешенең иҗтимагый хезмәт эшчәнлеге, хезмәт процесслары, хезмәт мөнәсәбәтләре белән дә моның багланышы бик зур. Бу фәннең дә югарыдагы нигез буенча совет мәктәбендә тотарга тиеш булган үз урыны, үзенең аерым хосусиятләре, аерым әһәмияте, аерым хокукы 1929 елда Дәүләт советы тарафыннан нәшер ителгән «Программ проекты»нда ачык билгеләнеп бирелде. Ленинградтагы тел-әдәбиятчылар, әдәбият методистлары тарафыннан да бу эш әсасән дөрес дип, хаклап яхшы каршы алынды.[2]

Үзенең төп максаты буенча совет мәктәбенең ихатасы эченә әһәмиятле бер гонсыр[3] булып, баланың, яшүсмерләрнең эмоция (тойгы) даирәсе, аларның сәнгатьчә тәрбияләнү яклары да кергезелергә тиешлеге әлеге «Программ проекты»нда аеруча бер игътибар белән ачык күрсәтелде. Иң дөресе – нәфис әдәбиятның совет мәктәбендәге урыны, аерым әһәмияте иң элек яшүсмерләрнең әнә шушы эмоция даирәсен тәрбияләү ягы белән билгеләнде. Моның белән, шул ук вакытта, совет мәктәбендә әдәбият укытуда тотылган максатның мөһим бер гонсыры да билгеләнеп бирелгән булды.

Шуның өстенә әдәбиятның мәктәптә әдәбият шөгыльләренең җәмгыять белеменә иллюстрация ясап баручылык, аңа хезмәтче бу-

---

[1] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.

[2] «***Родной язык в школе*** « исемендә чыгып килгән гыйльми әһәмиятле мәҗмуганың 1927 ел чыккан беренче китабына, 134–139 битләренә, «Габо» мәкаләсенә каралсын. Монда «Программ проекты»ның кайбер нокталарына әһәмиятле тәнкыйтьләр дә бар. (*Авт. иск.)*

[3] Гонсыр – элемент, өлеш.

лып әверүчелек сызыгына төшерелүе дә методология ягыннан «ике мәртәбә яраксыз» булып чыкканлыгы ачык күрсәтелде («Программ проекты»ның 82–83 битләренә каралсын).

Ләкин моның белән әдәбиятның җәмгыятьчелеккә, җәмгыять белеменә бәйләнешы бөтенләй киселә, бу як бөтенләй инкяр ителә дип аңламаска кирәк.

Бу бәйләныш һаман барачак. Тик ул кайбер тәҗрибәләрдә күренгәнчә, соңгы бер юл белән көчләнеп түгел, бәлки әдәбиятның үз хосусиятләре, сәнгатьчелек, сәнгатьчә тәрбия бирүчелек шартлары саклану шарты белән табигый эчке мантыйкы бер бәйләныш әсасында барачак, бу бәйләныш тормышлы, нәтиҗәле бер бәйләнышка әйләндереләчәк.

3. Икенче баскыч совет мәктәпләрендә әдәбият укытуда тотылган югарыдагы төп максат өстенә бу мәктәпләрдәге гомуми белем бирү эшләренең эченә яшүсмерләрне әдәбият белеменнән яисә әдәби белемләнүдән, әдәбият техникасыннан өлешле итеп чыгару мәсьәләсен дә кушарга кирәк. Безнең шикелле милли мәдәнияте, теле-әдәбияты үз хокукын яңа алып, яңа зәминдә[1] киңәеп үсә башлаган бер халык мәктәбендә моның әһәмияте тагын да зур икәне аерым исбат ителүгә мохтаҗ түгел. Татар укучысы үз мәктәбендә үз теле, үз әдәбияты аркылы эмоциональ тәрбия алып чыгарга тиеш булган шикелле, ул гамәли тормышында да үз теле, үз әдәбияты аркылы эш итә алырлык, шуның аркылы социализм юлында үзенең иҗтимагый фикер тәрәккыйсен мәктәптән чыккач та һаман үз башына дәвам иттереп китә белерлек бер дәрәҗәдә әдәбият белеме, әдәбият техникасы белән коралланып чыгарга тиеш.

4. Дәүләт «Программ проекты» буенча икенче баскыч мәктәпләрнең әүвәлге ике елында әдәбият белән шөгыльләнү эшләренең төп бурычлары түбәндәгечә билгеләнә: әдәби укуны тәрәккый иттерү – мәдәниятләштерү. Сәнгатьле рәвешләрне (сурәт) эләктереп ала алу, аңлау, шуларны баштан кичерә белү һәм һәртөрле сәнгатьле гыйбарәләр – текстлар белән эш итә алу.

Монда, әлбәттә, материалның ничек сайлану, ничек салыну мәсьәләсе җиңелдән авырга яисә катлаусыздан катлаулыракка таба бару кагыйдәсе белән билгеләнә. Сурәт, өслүб, тел, композиция, әсәрнең күләме кебекләр бары да шул яктан нык игътибарга алына.

Шуның өчен укытучы 2 нче баскычның әүвәлге ике елында кирәк хронологик, кирәк формаль, кирәк мәүзуг берлек (тематик) таләпләре белән бәйләнып калмаска тиеш. Бу ике елда әдәбият бигрәк тә үзенең эмоцияле һәм рәвешле-сурәтле стихиясендә аңланып алынырга тиеш. Әсәрне тикшерү, аңа анализ ясау эшләре бу ике елда сүз сәнгатьчесенең (әдип-шагыйрьләрнең) әйтергә теләгәннәренә тирәнрәк төшенү характерын ала. Шуны ачу, шуңа дикъкатьле рәвештә һәр як белән ирешү, шуны яхшы аңлап алу өчен эшләнә.

[1] Зәминдә – җирлектә, нигездә.

Әдәби материалларга социологик анализ ясау бу ике елда төп бурыч түгел. Мәсьәләнең бу ягына тик уңае чыкканда һәм бик кирәк булганда гына туктальна. Монда әсәрне аңлау өчен чарасыз кирәк булган тарихи һәм башка төрле изахлар[1] белән генә чикләнелә. Дөрес, тикшерүнең бу ягы баскычлы рәвештә һаман киңәя, тирәнәя барырга тиеш. Шулай да социологик анализ һәрхәлдә 7 еллыкның соңгы елында гына эшнең мөһим бер элементы булып китә ала. Бу елда сәнгатьче, әдип үзе дә, аның әдәби иҗаты да иҗтимагый, тарихи фактлар белән нык багланып, шулар белән чагыштырылып тикшерелә башлый, ләкин монда да тикшерелүнең төп үзәге турыдан-туры әсәрнең үзе, мөндәриҗәсе, өслүбе булырга тиеш. Мөхәррирнең тәрҗемәи хәле кебек материаллардан тик иң соңгы нәүбәттә генә файдаланырга мөмкин.

2 нче баскычның бу беренче бүлеме (әүвәлге өч ел) өчен югарыдагы төп бурычларга өстәп, тагын түбәндәге хосусый бурычлар куела:

1. Укучыларда нәфис әдәбиятны (тезмә һәм чәчмәләрне) укырга кызыксындыру, шуны киряксендерү.

2. Яшүсмерләрнең өйдәге укуларында укыган әсәрләренең эченә кермичә, бик ашыгып, өстән-өстән генә һәм тик күңел ачу өчен генә, шулай ук әсәрне бөтен көенчә түгел, тик аның аерым урыннарын гына өзеп алып уку кебек аяньчлы җитешсезлекләр, игътибарсызлыклар бар. Мәктәп менә моңа каршы нык көрәш ачарга кирәк. Шундый җиңелчә уку гадәтен бетерү чарасын нык күрергә кирәк.

Бу көрәштә аларда башка бер уку техникасы тудырып, шуны тәрәккый иттерү, мәдәниләштерү юлы белән булачак. Мәктәп яшүсмерләргә, һәрхәлдә, игътибарлы, текстның авырлыгын җиңүче, җитди һәм актив рәвештә уку техникасын казандырырга, аларга шундый яңа бер гадәтне бирергә тиеш.

Мондый бер җитешсезлекнең хәзерге татар яшүсмерләре арасында тагын да аянычлырак бер хәлдә булуын уйласак, безнең мәктәпләребез өчен бу юлдагы көрәшнең әһәмияте тагын да зураячак.

3. Мәктәп яшүсмерләрне укыганнарын мөмкин кадәр тулы аңлап алырга өйрәтсен. Бу тулылыкта: әсәрнең төп әйтергә теләгәне, композициясе, идеясе белән бөтен, төгәл хәлендә ихата кылынуыннан һәм шул ук вакытта аны баштан кичерү, аның аерым тәфсилләренәчә бәя бирә белүдән гыйбарәт. Моның өчен дә:

а) әдәби материалларның сәнгать таләбенә җавап бирә алулары өстенә, яшүсмерләр өчен җиңел аңлаешлы һәм аларны үз-үзләреннән кызыксындырырлык булсыннар;

ә) укучыны әдәби материал белән таныштыруның һәртөрле рәвешләре татбикъ ителергә[2] тиеш: укучының өйдә үз башына укуы, сыйныфта кычкырып укуы, укытучының үзенең укып күрсәтүе, шу-

[1] Изахлар – аңлатулар.

[2] Татбикъ ителергә – яраклаштырылырга.

лай ук күмәк (коллектив) укуларның һәртөрле рәвешләре – шулар җөмләсеннән;

б) укучыга әдәби организмны сәнгатьчә бербөтен рәвешендә аңлап алуның юлын ача торган һәммә чараларны укытучы бу турыда күрергә тиеш. Мәсәлән, әдәбиятка якын сәнгатьләрдән рәсем, музыка шикелле сәнгатьләргә экскурсия ясау, тормышлы күзәтүләр ясау, укучыларның үз иҗатлары – менә болар барысы да шундый чаралардан;

в) шул ук максат өчен әдәби әсәрләрне укыганда алар турындагы шәрех һәм аңлатуларны укый бару да файдалы булачак;

г) әсәрне аңлау өчен очрый торган манигълар[1] башта ук һәм уңае чыккан саен кирәкле мәгълүматлар, изахлар бирә тору юлы белән бетерелә барырга тиеш. Мондый изахлар тарихи яки җәгърафия яки әдәби техника ягыннан яки тәрҗемәи хәл мәгълүматлары аркылы булырга мөмкин.

5. Шушы югарыда күрсәтелгән төп нигездән чыгып, 2 нче баскычның беренче бүлегенең беренче елы (5 нче уку елы) өчен куелган таләпләр түбәндәгеләр:

1. Сәнгать әсәрләрен мөстәкыйль укый алырга өйрәтү.

2. Сәвадле[2], аңлаулы һәм тасвирлы укый алу күнегүләрен бирү.

3. Нәфис әдәбият белән кызыксындыру.

4. Нәгыз[3] нәфис әдәбияттан җиңел һәм үзләренә ирешү асат булган әсәрләр белән кайбер таныштырулар ясау.

5. Чәчмә, тезмә, хикәя, мәсәл, поэмалардан һәм дә драма күренешләреннән алып, әдәби иҗатларның һәр турыннан үрнәкләр бирү.

Бу елда бу максатларга ирешү өчен шартлар:

а) материал сайлаганда иң элек әсәрнең сәнгатьле эшләнгән булу ягына игътибар итеп, шундый әсәрләрдән күләмдә зур булмаган, шуның белән бергә шул яшьтәгеләр (12–14 яшьтәгеләр) өчен кызыклы һәм форма ягыннан да төрлелеге булган әсәрләр сайланыр. Шуның өстенә балаларны материал белән күмеп, шуның күплеге астында аларны каңгыртып калудан бик сакланырга кирәк. Безнең мәктәпләребездә бу хәл нык сизелә. Хикмәт материалның күплегендә түгел, аз булып та, нәтиҗәле, яхшы, кызыклы булуында. Һәрхәлдә, монда сан түгел, сыйфат ягын карарга кирәк;

ә) укыла торган әсәр фабулалы, сюжетлы һәм укучыны шөгыльләндерерлек, аны үзенә тәмам кызыктырырлык булырга тиеш. Ул аңа якын, аның өчен аңлаешлы булсын, бу якынлыкта дәүләт «Программ проекты»ндагы аңлату язуы буенча, бик хаклы һәм педагогия таләбенә дә бик муафикъ рәвештә һәр нәрсәдән элек укучының турыдан туры үз тәэсирләре, үзенең башыннан кичергәннәре, үз тәҗрибәсе белән билгеләнә, шуңа таяндырыла. Бу хәл, әлбәттә, укучының нәфис әсәрләрне үзе күргән, үзе белгән, үзе ишеткән һәм

[1] Манигълар – киртәләр.
[2] Сәвадле – укый-яза белгән.
[3] Нәгыз – яхшы.

турыдан-туры үзе күзәткән вакыйгыйлык белән чагыштырып, шулар белән тиңләштереп каравына мөмкинлек бирә. Мондый әсәрләр бигрәк тә хәзерге тормыш турында һәм шуннан алынып язылган әсәрләр, хәзерге мөхәррирләрнең хикәячекләре булачаклар. Кыскасы: мәүзуг, күзәтү даирәсе һәм әсәрнең теле укучыга мәгълүм булу, укучыларга бирелгән әсәрнең җитәрлек дәрәҗәдә сәнгатьчә эшләнгән булуы монда иң нык игътибарга алынырга тиеш.

Материал сайлаганда да материалның бербөтен бирерлек булуына, өзек-төтек булып кисәкләнеп алынмавына нык дикъкать итәргә тиешбез. Шуның өчен зур әсәрләрне кисәкләп алудан да, кечкенә, ләкин бөтен булган әсәрләрне сайлау алда тотыла. Андый муафикъ материаллар табылмый икән, ул чагында зур әсәрләрнең дә бербөтен бирерлек бүлекләре алынырга тиеш.

6. Алтынчы ел өчен дә шул ук бишенче ел өчен куелган максатлар күзәтелә. Тик монда шуларны тирәнәйтү бара. Монда мөстәкыйль һәм кычкырып укуда тагын да авыррак текстлар белән эш итә алу күнегүләрен бирергә кирәк. Нәфис әсәрне сизеп алу, аңлауның, аңа анализ ясауның тагын да нечкәләндерелүе – бу елның бурычы. Тел һәм мөндәриҗә ягыннан тагын да катлаулырак, авыррак әсәрләр сайлана. Бу елда укучы сәнгать иҗатларының стихиясен сизеп алу гына түгел, бәлки шуны аера, аралый белә башларга тиеш. Тел белән шөгыльләнү эшләре дә әдәби материллар белән баглана башлый. Бишенче елдагы кебек үк, монда да чәчмә һәм тезмәләрне укый белү ягына нык игътибар ителә. Бу елда (алтынчы елда) тезмәләр ятлана башлау да файдалы табыла.

7. Җиденче елда инде әдәбияттан белем алу тагын да тирәнәергә һәм беркадәр түгәрәкләнеп, бөтенәйтелергә тиеш.

Руслар өчен бу елда укучыларга рус әдәбиятының йөзьеллык тәрәккыйсендәге кайбер маякларны бирүне алга куялар һәм бу тәрәккыйне дә рус иҗтимагый хәрәкәт агымнарының характеристикасы белән баглап баруны шарт итәләр. Шуның белән бергә шул уңайдан мөхәррирләр турындагы тәнкыйтьләрдән һәм җәмәгатьчелек әдәбиятыннан да үрнәкләр бирә баруны матлуб[1] саныйлар.

Безнең өчен үз әдәбиятыбыздан XIX йөзнең соңгы ярымыннан хәзергәчә булган 70–80 еллык бер әдәби хәятыбыз алынырга тиеш. Шул заман эчендә татар әдәбиятының тәрәккыйсендә иң әһәмиятле моментлар сайланып, иң кирәкле кайбер маякларны бирү бу елның бурычы булыр. Билгеле, бу да татар иҗтимагый хәрәкәт агымнарының характеристикасы белән багланып барылыр. Октябрьгәчә булган классик әдипләргә әһәмият бирелеп, шулар сайланган шикелле, октябрьдән соңгы әдәбиятка, яңа әдәби кыйммәтләргә дә тиешенчә әһәмият бирелер.

8. Үз әдәбиятыбыз белән генә бикләнеп калмау һәм яшүсмерләребезнең әдәби карашларын, әдәби зәвыкларын киңәйтү, үстерү өчен Яурупа һәм рус классикларыннан, шулай ук хәзерге яңа рус пролета-

[1] Матлуб – тиешле.

риат әдәбиятыннан да кайбер җиңелчә үрнәкләр кертүне искә алырга тиешбез. Әлбәттә, болар татарча тәрҗемәләр аркылы булачаклар.

Шулар белән бергә шул ук татарча тәрҗемәләре аркылы кардәш телләрнең (башкорт, кырым, үзбәк, казакъ һәм башкаларның) әдәбиятларыннан сәнгатьчә эшләнү һәм мөндәриҗәсе ягыннан файдалы, кирәкле булган кайбер әдәби үрнәкләр алу да онытылмаска тиеш. Беренче тюркология корылтаеның карарында бу нәрсә бар.

9. Икенче баскычның беренче бүлеме өчен программда әдәбият нәзариясе (әдәбият кануннары) аерым бер курс булып кергезелми һәм кергезелә дә алмый. Шулай булса да, нәфис әдәбиятны, әдәби иҗатларны аңлап алып үзләштерү өчен, әдәби техника һәм әдәби атамалар турында кирәкле аң бирелмичә дә булмый. Болар әдәби әсәрләрне уку, тикшерү эшләре барган вакытта гамәли юл белән казаныла барырга тиешләр. Мәсәлән, әдәбият нәзариясенең өслүб бүлеме (тезмә, чәчмә, вәзен, бетем (кафия), аһәң, ошату, истигарә[1], киная, мөбаләга[2], тәкрар кебекләр), мәүзуг, мөндәриҗә, тасвир, хикәя, лирика, һөҗү, мәсәл, драма, поэма, комедия, композиция, фабула, тип һәм башкалар кебек әдәби атамалар белән таныштырулар шундый гамәли юл белән генә барачаклар. Бигрәк тә өслүб бүлеме «әдәби телне күзәтү» характерында гамәли юл белән бик кызыклы, бик җиңел рәвештә яхшы үтелә ала. Монда тезмә өслүбкә, аның хосусиятләренә аеруча тукталына. Дәүләт программ проектында да бу якка аерым әһәмият бирелә.

10. Мәктәптә әдәбият белән шөгыльләнү эшләре укучыларның үз иҗатлары белән бәйләнеп барырга тиешлек мәсьәләсен бу урында аеруча искә алып үтүгә хаҗәт бар. Укучылар әйтергә, аңлатырга теләгәннәрен, фикер, тойгыларын, сүз ифадәсе аркылы аңлату юлында чиккән үз мәшәкатьләре, үз хезмәтләре аркасында сүз сәнгатьчеләренең осталыкларын тагын да тирән аңлау һәм аңа кирәкле бәяне бирә белү юлына төшәләр, шулай ук моның аркасында аларның өслүб хосусиятләренә тагын да аңлы һәм уяурак бер мөнәсәбәттә булыну эшен җиңеләйткән булалар. Укылган, тикшерелгән әдәби әсәрләрдә, үз нәүбәтләрендә, укучыларның иҗатларына тиешле тәэсирне күрсәтә баралар.

11. Икенче баскычның беренче бүлемендә әдәбият тарихына бер әдәбият тарихы рәвешендә, әлбәттә, урын юк. Монда әдәби әсәрләрне укыту, тикшерү эшләрендә, материаллар сайлануда тарихи юл (историзм) да тотыла алмый. Әдәби материаллар кирәгенә карап сайланган шикелле, әдәби-тарихи мәгълүматлар да гамәли тикшерүләргә бәйләнып бирелә баралар. Монда катгый бер тарихи систем таләп ителмәскә һәм систем тотылмаска тиеш.

12. Укыла, тикшерелә торган әдәби әсәрләрне аңлый алу өчен аның план, тезисын һәм конспект төзү күнегүләре ясалу – иң файдалы чараларның берсе. План, тезис, конспект төздерү, укучыларны шуңа күнектерү мәсьәләсе безнең мәктәпләрдә гомумән зәгыйфь ку-

[1] Истигарә – метафора.

[2] Мөбаләга – гипербола.

елган. Безнең укучылар бу яктан йомшак булып чыгалар. Тел-әдәбият дәресләрендә бу җитешсезлекләр тутырылырга тиеш. Укучылар өчен бу юлдагы күнегүләрнең гамәли тормышта тагын да әһәмиятләре зур.

13. Инде метод мәсьәләсенә тукталыйк. Совет мәктәбендә белем алуда гомумән төп метод – марксизм методы булганлыгы һәм совет мәктәпләрендә комплекс системы да шуның нәтиҗәсе булып торганлыгы югарыда әйтелеп үтелде. Бу төп нигез буенча, башка дәресләр шикелле үк, әдәбият дәресләренең дә лаборатория, ягъни «тикшерүчелек методы» (исследовательский метод) белән барырга тиешлек мәсьәләсе алга баса.

Ләкин мәктәптә бу методны фән галимнәре тарафыннан эшләнә торган гыйльми-объектив мәгънәсендәге тикшерү эшләреннән аерып таныйлар. Мәктәптә бу метод алынырга тиешле белемнәрне укучыларның үзләреннән мөстәкыйль рәвештә эзләтеп, тикшертеп таптырудан гыйбарәт. Бу метод – искечә «әзер белем бирү методы»на бөтенләй каршы булган бер метод. Укучыларның хадисәләрне мөстәкыйль рәвештә үзләре күзәтүләре, материал җыйнауда, җыйналган материалны эшләп чыгаруда, шулай ук эшләгән эшләрдән билгеле бер нәтиҗәгә килүдә аларның мөстәкыйль рәвештә эш күрүләре – болар мәктәптә бу методның төп характерын билгелиләр.

Бу метод үзенең беренче адымында, алдан ук мәгълүм булган нәтиҗәләргә карап, укытучы тарафыннан күрсәтелгән билгеле материалның укучы тарафыннан эшләнеп чыгуы дип аңлана. Җөмләдән, лаборатория методын мәгълүм методистлардан Попова[1] шулай дип аңлый.

Ул лаборатория эшләренең шул ук вакытта тикшерүчелек эшләре дә булырга мөмкинлеген әйтсә дә, бу якның I баскычларда бик сирәк хәлләрдә генә булып, аның бигрәк II баскычлардан көтелгәнен дә аңлата. Укучының мөстәкыйль тикшерүчелек хәзерлеге, аның шул даирәсе әкренләп киңәя баруы мәгънәсе белән бу, әлбәттә, шулай.

Бу метод укучыларга мөстәкыйль башкару өчен «эш бирү» юлы белән барып, ниһаять тәдриҗән[2] дальтон-планга, ягъни совет дальтон-планына әйләнергә тиеш. Чын дальтон-планга күчү мәсьәләсе безнең мәктәпләрнең шартлары эчендә тагын да күп мәртәбәләр кыен булганлыгын игътибарга алып, шулай барырга тиеш дибез.

Бу метод (тикшерүчелек методы) буенча «эш бирү» юлы белән барганда өч төрле момент бар:

1) Эшкә кереш моменты, 2) эшне эшләү моменты, 3) эшләгән эштән хисап бирү, эшләгән эшләрнең нәтиҗәсен карау-тикшерү моменты. Кереш моментында эшләп чыгару өчен укучылар белән бергә мәүзуглар билгеләнә, максат, мәнбәгъ[3] һәм материаллар, эшләүнең методы шулай ук бирелгән мәүзугны эшләп чыгару өчен билгеле бер вакыт – сәгать күрсәтелә. Эшне бер атналык, ике атналык, өч ат-

---

[1] Наталья Сергеевна Попова (1885–1975) – педагог, методист, доцент, арифметика буенча дәреслекләр авторы.

[2] Тәдриҗән – акрынлап.

[3] Мәнбәгъ – чыганаклар.

налык һәм бер айлык итеп бирү тәҗрибәләре бар. Ләкин эшнең ике атнадан да ким бер вакыт белән бирелмәве гамәлдә файдалы һәм тәҗрибәлерәк табыла.

Эшләү моментында укучылар күрсәтелгән мәнбәгъ һәм материаллардан файдаланып, шуларны үзләре турыдан-туры мөстәкыйль рәвештә тикшереп, бирелгән мәгълүм мәүзугны эшләп чыгаралар. Эшләп чыгару эше вакыты белән индивидуаль рәвештә, вакыты белән күмәкләп (коллективларга аерылып) эшләнергә мөмкин.

Эшнең нәтиҗәсендә шул ук мәүзуг турында тезислар язылa.

Эштән хисап бирү моменты – бөтен сыйныф белән шул тезисларны карау, шулар буенча соңгы аңлашулар ясау, эшләгән эшләрне тәнкыйтьтән үткәреп, шуларга гомуми бер нәтиҗә яисә бер бәя бирүдән гыйбарәт.

Бирелгән эшләрне эшләп чыгару процессы башта байтак вакытларгача аудиториядә укытучының үз карамагы һәм аның турыдан-туры ярдәме астында барып, соңыннан укучылар үзләре тәмам мөстәкыйль эшләү юлына төшереләә һәм шуңа күнектереләләр. Ваграк, җиңелрәк мәүзуглар өйгә дә бирелә.

Һәрбер яңа бирелгән эш әүвәлге эшләр белән эчке – мантыйкый бер юл белән бәйләнеп барырга тиеш.

Тикшерелә торган әдәби әсәрләр әүвәл сыйныфта бөтен укучылар белән бергә укылып чыгыла һәм шуның өчен күләм ягыннан сыйныфта бергә укып чыга алу мөмкин булганнары сайлану яхшырак нәтиҗәләр бирә. Шуннан соң алдан әзерләнгән план буенча әсәрнең кай ягын тикшерү кирәк булса, укучылар аның шул ягын тикшерергә тотыналар.

Ләкин әсәрне бер вакытта һәммә ягыннан (тел, өслүб, мөндәриҗә, типлары һ.б. якларыннан) тикшерүне бергә алып бару мәҗбүрлеге астында калмаска кирәк. Бер вакытта әсәрнең тел-өслүбе генә аерылып тикшерелсә, икенче вакытта аның мөндәриҗәсе, типлары тикшерелергә мөмкин. Яисә бер күмәк әсәрнең тел-өслүбен тикшерүне алса, икенче күмәк яки икенче бер укучы аның гомумән мөндәриҗәсен, өченчеләре дә типларын алырга мөмкин.

Г. Сәгъди
1927 ел.

*Басмага әзерләде:*
***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*
***Гарипова Лейля Шамиловна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*leilyashamilevna@mail.ru*

УДК 929.7(470.41)

*Т.Н. Галиуллин*

# ТАРИХТА ҺӘМ ФӘНДӘ ҮЗ УРЫНЫ БАР
## (Галим, җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсәнов истәлегенә)

Статья посвящена анализу научного и общественного наследия академика, первого Президента Академии наук Республики Татарстан Мансура Хасанова (1930–2010). Автор рассматривает основные этапы его биографии, вклад в развитие татарской филологии, исследование творчества Галимджана Ибрагимова и организацию академической науки в Татарстане. Особое внимание уделяется роли М. Хасанова как наставника целого поколения исследователей, его педагогическим и общественным инициативам, а также формированию национальной научной школы. Новизна статьи заключается в осмыслении фигуры ученого не только через его труды, но и через личные воспоминания современников, что позволяет показать целостный образ ученого и общественного деятеля в контексте истории татарской культуры второй половины XX – начала XXI в. В результате выявляется значимость деятельности М. Хасанова для сохранения и развития национального наследия, формирования институциональных основ науки и утверждения авторитета татарской филологии на общероссийском и международном уровнях.

**Ключевые слова:** Мансур Хасанов, Академия наук Республики Татарстан, татарская филология, Галимджан Ибрагимов, научное наследие, культурная память, общественная деятельность.

This article analyzes the scientific and social legacy of Academician Mansur Khasanov (1930–2010), the first President of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The author examines the main stages of his biography, his contribution to the development of Tatar philology, his research into the work of Galimdzhan Ibragimov, and the organization of academic science in Tatarstan. Particular attention is paid to Khasanov's role as a mentor to an entire generation of researchers, his pedagogical and social initiatives and the formation of a national scientific school. The article's novelty lies in its understanding of the scholar's figure not only through his works but also through the personal memoirs of his contemporaries, allowing for a holistic portrayal of the scholar and public figure within the context of the history of Tatar culture from the second half of the 20th to the early 21st centuries. This study reveals the significance of Khasanov's work for the preservation and development of national heritage, the formation of the institutional foundations of science and the assertion of the authority of Tatar philology at the national and international levels.

**Keywords:** Mansur Khasanov, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Tatar philology, Galimdzhan Ibragimov, scientific heritage, cultural memory, social activities.

Яшьлек, бигрәк тә студент елларын кире кайтарып булмаган шикелле, аларны зиһенеңнән сызып ташлавы да мөмкин түгел. Мәктәп укытучылары, уку йортлары мөгаллимнәренең ата-ана кебек үк

кадерле һәм газиз шәхесләр булуы «кызыл сүз» өчен генә әйтелмиләр икән.

Үзе исән-имин чагында да, рухи дөньяга – ахирәткә күчкәннән соң да, күренекле галим, Татарстан Фәннәр академиясен гамәлгә куючылардан һәм аның беренче президенты булган Мансур Хәсән углы Хәсәнов (1930–2010) студент елларымнан алып бүгенге көнгәчә минем остазым, киңәшчем булып кала. Әлбәттә, бу фикеремне мин күпсанлы фәнни китаплар, җыентыклар авторы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесенең укучылары, дәвамчылары бихисап икәнлеген белеп әйтәм.

Мисалларны читтән эзләп тормастан, 1956–1961 елларда бер төркемдә укып, М. Хәсәновтан дәресләр алган гамәлдәге фән докторлары, күренекле галимнәр И. Бәширова, Ф. Юсупов һәм «минем Аязым» дип «зәңгәр экраннан төшмәгән» Нәкыя Гыйләҗевалар белән очрашкан саен, ул чордагы «студент – укытучы» форматындагы тәүге очрашуыбызны һәм аның дәресләрен сагынып искә алуыбызны гына язып үтим.

Көннәребезнең берсендә старостабыз Илдар Әүхәдиев аудиториягә: «Игътибар белән тыңлавыгызны сорыйм, – дип килеп керде. – Бүген икенче парга әдәбият дәресенә яшь галим Мансур Хәсәнов керәчәк, ул безгә Галимҗан Ибраһимов иҗаты буенча махсус курс укыячак. Кафедра мөдире: «Игътибар белән тыңлагыз, язып барыгыз, яшь булса да, әзерлекле галим», – диде.

Укытучыларның төрлесен күргән дүртенче курс студентларын инде берни белән дә гаҗәпләндереп булмый кебек иде. Старостабызга ачыкламыш сораулар биреп тә өлгермәдек, кинәт ишек ачылды һәм аудиториягә уртачадан озынчарак буйлы, җиңел хәрәкәтле, безнең фаразыбызча, 28–30 яшьләрдәге ир-ат килеп керде һәм, җиңелчә генә башын иеп исәнләшкәннән чоң, алдына салган кәгазенә караштырып, укыячак лекциясенең темасын әйткәннән соң, үзе белән таныштырып алды.

Ул тумышы белән Зәй районының Бигеш авылыннан икән. Әтиәнисе һаман шунда яшиләр, ди. Җидееллык авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, укуын дәвам итү, белгечлек алу өчен еракка китеп тормыйча, үсмер күрше Алабуганың китапханә техникумына юл тота. Аны уңышлы тәмамлагач, шунда ук ике ел клуб мөдире булып эшләп алганнан соң, белем алуын дәвам итү нияте аны Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Ул шунда киләчәген дә, бәхетен дә таба [2: 587–589].

Белемгә омтылучан, максатчан үсмер студент елларында ук, бигрәк тә Казан дәүләт университеты дипломы алган көннән алып, Галимҗан Ибраһимов иҗаты, шәхесе, язмышы белән кызыксына башлый һәм соңгы сулышына кадәр аның иң турылыклы һәм фидакяр өйрәнүчеләренең берсе дәрәҗәсенә күтәрелә [7]. Алдагы берничә елда ул «Татарстан яшьләре» газетасының мөхәррире булып эшләп ала. Басманың эчтәлегенә яшьлек рухы иңдереп, аның

тиражын шактый арттыруга ирешә. Аңа журналистика белән озаклап шөгыльләнергә насыйп булмый – Мансурны аспирантурага чакырып алалар. Нәкъ шул чорда Г. Ибраһимов исеменнән һәртөрле ярлыклар алып ташлана һәм аның иҗатын, әдәби, гыйльми, эстетик мирасын халыкка кайтару, гомумән исемен аклау, фәнни өйрәнү чоры башлана. Нәкъ менә шул изге бурычларны үтәү өчен, үзен намуслы каләм иясе итеп таныта башлаган яшь галим Мансур Хәсәнов лаеклы дип табыла, аспирантураны тәмамлагач, шунда ук эшкә калдырыла һәм университетның тарих-филология факультетының өлкән укытучысы, бераздан декан урынбасары итеп билгеләнә.

Тарих өчен генә булса да, шул чордагы мөхтәрәм өлкәннәребезне искә алып, атап үтәсем килә. Аерым алганда, 1950–1980 елларда укыганнарга Л. Җәләй, Х. Госман, Д. Тумашева, И. Нуруллин, Х. Ярми, Я. Агишев кебек бөтен татар дөньясының горурлыгы булган галимнәр гыйлем бирәләр һәм аларга татар титаны Г. Ибраһимовның иҗатын, әдәби, гыйльми, фәлсәфи мирасын саклап буыннарга тапшырачак яңа буын галиме Мансур Хәсәнов килеп кушыла. Яшь укытучыбыз тәүге лекцияләрендә Г. Ибраһимовның тормыш юлы, иҗат баскычлары белән таныштырганнан соң, аның сәяси, иҗтимагый карашларын ачыклауга килеп җиткәч, түбәндәге юлларны язып баруыбызны «тикшереп» торды: «Февраль, аннан соң Октябрь социалистик революциясе аның дөньяга карашларын чарладылар һәм Г. Ибраһимовны большевиклар партиясе һәм марксистик идеяләр белән бәйләделәр һәм ул бөтен иҗатын гомере буенча шул концепциядән чыгып бәяләде» [7].

Яшь галим Г. Ибраһимов иҗатына нисбәтән гомуми методологик керештән соң, аның башлангыч чор иҗатына тукталып, «Яз башы», «Диңгездә», «Карак мулла», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»,»Татар хатыныниләр күрми», «Яшь йөрәкләр» әсәрләренең эчтәлек һәм мәгънәви юнәлешләренә басым ясап, аларның сүз-сурәт байлыкларына, психологик алымнарының төрлелегенә иркенләп тукталды [7].

Без, университетта укуны тәмамлап, диплом алып чыккан 1961 елда М. Хәсәнов, нигездә, Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләренә таянып, кандидатлык диссертациясен яклый, ә 1971 елда бу юнәлештәге фәнни тикшеренүләрен дәвам итеп, Г. Ибраһимов мирасын киңрәк колачлап һәм шул чорда яшәп иҗат иткән Г. Исхакый, Гали Рәхим, Г. Сәгъди, Г. Толымбайский һәм башка әдипләр иҗаты белән чагыштырып язылган докторлык диссертациясен Казан университетында яклагач, берничә елдан соң Министрлар советы рәисенең урынбасары итеп тәгаенләнә.

Гомере дәвамында Мансур Хәсәнов нинди генә җаваплы вазифаларда эшләмәсен, ул бер мизгелгә дә Г. Ибраһимов иҗатын, әдәби һәм фәнни мирасын өйрәнүдән туктамый. «Галимҗан Ибраһимов. Тормышы һәм иҗат юлы» исемле китабын 1964 елда бастырып чыгарса [8], 1969 елда аның тулыландырылган нөсхәсен рус телендә тәкъдим

итә: «Галимджан Ибрагимов (о жизни и творчестве писателя)» [6]. М. Хәсәновның әлеге хезмәтләре М. Гайнуллин, И. Нуруллин, Г. Халит, Р. Рамазанов, В. Разумович һ. б. галимнәрнең, тәнкыйтьчеләрнең уңай бәясенә лаек булалар.

Галим, үткән гасырның соңгы чирегендә җаваплы рәсми урыннар биләгәндә дә, нәзари эзләнүләрдән читләшми, реализм, натурализм һәм романтизм кебек иҗат методларының әдәби үсештә уйнаган рольләре турындагы фикерләре белән фәнни басмаларда уртаклашып тора. Ул романтизмны, объектив һәм субъектив агымнарның синтезы буларак, Г. Ибраһимов иҗатында үсештәге күренеш дип бәяли [6].

1980 елда М. Хәсәновның «Инттернационализмның җанлы традицияләре» дигән мәкаләләр җыентыгы басылып чыга. Шул чорның кырыс сәяси таләпләрен исәпкә алу мәҗбүрияте сизелсә дә, Г. Тукай («Тукай хакында сүз»), Г. Ибраһимов («Әдипнең бөеклеге»), Г. Камал («Татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы») мәкаләләрендә күренекле татар әдипләренең иҗади портретларын тудыру аша әлеге шәхесләребез яшәп иҗат иткән чорның әйдәп баручы тенденцияләрен ачып бирүгә ирешә [9].

«Писатель, ученый, революционер: страницы жизни и творчества Галимджана Ибрагимова» (1987) монографиясе – әдипнең сюжет кору үзенчәлекләрен, сүз-сурәт муллыгын, кеше кичерешләрен ачуы белән бүгенге көндә дә төрле милләт һәм катлам укучыларга тәкъдим итәрлек хезмәтләренең берсе [7].

Үткән гасырның соңгы чирегендә Татарстанның төрле, бигрәк тә фән-техника, әдәбият һәм мәдәният өлкәләрендә ирешкән уңышларын һәм һәр юнәлештә югары квалификацияле галимнәренең җитәрлек булуын исәпкә алып, Казанда Татарстан Фәннәр академиясен оештыруга рөхсәт бирелә. Аның беренче президентын сайлау киң җәмәгатьчелек катнашында алып барыла. 1991 елда берничә кандидатура арасыннан яңа оешкан Фәннәр академиясенең беренче президенты итеп Мансур Хәсәнов сайлана.

Җыеп кына әйткәндә, Академиягә нигез салуда М. Хәсәнов зур оештыру эшләре алып бара һәм яңа фәнни оешманың абруен күтәрү, үстерү юнәлешендә күп мәсьәләләрне чишүне үз өстенә ала. Аерым алганда, ул уку йортлары ректорларын, төрле фәнни-гамәли юнәлешләрне иңләгән институт, фирма җитәкчеләрен фәнни-гамәли оешмага таяныч итеп туплап, күбесен Академия мәнфәгатьләрен үтәүгә «буйсындыра» алды.

Агымдагы елның 25 июнендә олы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, милли җанлы Мансур Хәсәновның тууына 95 ел тулды. Әле үзе исән-имин чакта ук аның иҗатына һәм шәхесенә лаеклы бәя бирелә торды: Г. Халит [5], Г. Ахунов [1], А. Әхмәдуллин [3], С. Ибраһимова [4 ] һ.б.ның мәкаләләре матбугатта дөнья күрде.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты төзегән «Рухи мирас, эзләнүләр һәм табышлар» дип аталган коллектив хезмәтнең өченче чыгарылышында гомерен Галимҗан Ибраһимов

шәхесен һәм иҗатын өйрәнүгә багышлаган Мансур Хәсәнов үзе һәм аның хезмәтләре читтәрәк калган дигән тәэсир туды. Шул ук җыентыкта урын алган «Ак тапларны киметәсе иде» дигән мәкаләсендә М. Хәсәнов белән аралашып калган, хәзергәчә иҗаттан читләшмәгән өлкән язучыбыз Лирон Хәмидуллин аны «Г. Ибраһимов иҗатын барлау өлкәсендә зур эшләр башкарган олуг галим», – дип атый [10: 203]. Л. Хәмидуллинның мәкаләсенең исемендә яңгыраган фикерне Мансур Хәсәновның юбилей елы уңаеннан әйтелергә һәм үтәлергә тиешле иң изге теләкләрнең берсе дип кабул итәргә тиешбез дип фаразлыйм.

**Әдәбият**

1. *Ахунов Г.* Без – Тукайлы дөнья кешесе // Идел. 2000. № 6.
2. Әдипләребез. 2 т. (Л–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.
3. *Әхмәдуллин А.* Олы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе // Казан утлары. 2000. № 6. Б. 161–167.
4. *Ибраһимова С.* Туган, эти, дәү эти // Сөембикә. 2000. № 6.
5. *Халит Г.* Көрәшче әдип портреты // Казан утлары. 1970. № 11. Б. 109–115.
6. *Хасанов М.Х.* Галимджан Ибрагимов (1887–1938): краткий очерк жизни и творчества. Казань: Татар. кн. изд-во, 1960. 432 с.
7. *Хасанов М.Х.* Писатель, ученый, революционер: страницы жизни и творчества Г. Ибрагимова. М.: Наука, 1987. 316 с.
8. *Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов: тормышы һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 332 б.
9. *Хәсәнов М.Х.* Интернационализмның җанлы традицияләре: әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 262 б.
10. *Хәмидуллин Л.* Ак тапларны киметәсе иде // Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г. Гумерова. Казань: ИЯЛИ, 2017. Вып. 3. 336 с.

***Галиуллин Тәлгать Нәби улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (Казан)*

***Галиуллин Талгат Набиевич,***
*доктор филологических наук, профессор, член-корреспондент Академии наук Республики Татарстан (Казань)*

*galiullinafavziya@mail.ru*

УДК 811.512.145

***Х.Ч. Алишина***

# ФУАТ ӘШРАФ УЛЫ ГАНИЕВ – ТӨРКИ ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ФӘННИ МӘКТӘПКӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Статья посвящена жизни и научной работе Фуата Ашрафовича Ганиева, выдающегося тюрколога, чьи заслуги отмечены многочисленными званиями и должностями: в свое время он был членом Российского комитета тюркологов, академиком Академии гуманитарных наук, членом-корреспондентом Академии наук Республики Татарстан, Заслуженным деятелем науки Российской Федерации и Республики Татарстан, доктором филологических наук и профессором. Ф.А. Ганиев внес существенный вклад в исследование татарского языка, занимаясь вопросами его сохранения и развития, а также изучением татарской орфографии и совершенствованием письменности. Его научное наследие впечатляет: более 300 публикаций, из которых 16 – монографии. В статье подробно рассматривается его вклад в такие области, как татарская морфология и лексикография. Результатом его научных изысканий стало появление в татарском языкознании новой дисциплины – «Словообразование», которая заняла свое место рядом с «Морфологией» и «Синтаксисом». Статья о незаурядном ученом написана в знак глубокого уважения и благодарности.

**Ключевые слова**: татарский язык, видовая характеристика глаголов татарского языка, суффиксальное словообразование в татарском литературном языке.

This article is dedicated to the life and scientific work of Fuat Ashrafovich Ganiev, a distinguished Turkologist whose achievements are recognized by numerous titles and positions: he was a member of the Russian Committee of Turkologists, an academician of the Academy of Humanities, a corresponding member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, an Honored Scientist of the Russian Federation and the Republic of Tatarstan, a Doctor of Philology, and a professor. F.A. Ganiev made a significant contribution to the study of the Tatar language, focusing on its preservation and development, as well as the study of Tatar orthography and the improvement of the written language. His scholarly legacy is impressive: over 300 publications, 16 of which are monographs. The article examines in detail his contributions to such fields as Tatar morphology and lexicography. His research resulted in the emergence of a new discipline in Tatar linguistics – «Word Formation,» which took its place alongside «Morphology» and «Syntax.» This article about this extraordinary scholar is written as a sign of deep respect and gratitude.

**Keywords:** Tatar language, aspectual characteristics of Tatar verbs, suffixal word formation in the Tatar literary language.

Танылган тюрколог, Россия тюркологлар комитеты әгъзасы, Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, РФ һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Фуат Әшраф улы Ганиевка 2025 елның 1 августында 95 яшь тулган булыр иде.

Ф.Ә. Ганиев 1959 елда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага укырга керә, күренекле профессор Латыйф Җәләй җитәкчелегендә диссертация яза.

1963 елда ул «Татар телендә фигыльләрнең вид характеристикасы» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Анда ул тюркологиядә беренче тапкыр төрки телләрдә чикләнгән һәм чикләнмәгән фигыльләр булуын ача. Алга таба төрки телләрдә совершенный һәм несовершенный вид категориясе булмавын фәнни яктан исбатлый. Аңа кадәр күп кенә тикшеренүчеләр әлеге категориянең төрки телләрдә дә булу мөмкинлеген фаразлаган. Галим рус телендәге совершенный һәм несовершенный вид категориясе мәгънәләренең төрки телләрдә фигыльләрнең чикләнгән һәм чикләнмәгән булуына бәйле рәвештә заман формалары белән имплицит рәвештә бирелүен билгеләп, бу исә төрки телләрдә бөтенләй яңа нигезләмә булып тора. Ул беренче мәртәбә төрки телләрдә ярдәмче фигыльләрнең совершенный һәм несовершенный вид категориясен белдерүгә бернинди катнашы булмавын аңлатып бирә ала. Фуат Ганиев тюркологиядә беренче тапкыр эш-хәрәкәтнең башкарылу ысуллары категориясен («Aktionsart») аерып чыгара һәм системалы рәвештә тикшерә. Галим фикеренчә, мәсәлән, татар телендә ул лексик-грамматик категория булып тора, чөнки аны белдерүдә лексик һәм грамматик чаралар катнаша: ярдәмче фигыльләр, фигыль формаларын редупликацияләү һәм кушымчалар.

1970–1985 елларда Фуат Ганиев берничә монография бастыра: «Фонетическое словообразование в татарском языке» (1973), «Суффиксальное словообразование в татарском литературном языке» (1974), «Вопросы морфологии татарского языка» (1980), «Образование сложных слов в татарском языке» (1982), «Конверсия в татарском языке» (1985).

1977 елда галим «Суффиксальное словообразование в татарском литературном языке» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Монографияләрендә һәм докторлык диссертациясендә ул татар телендә сүз ясалышының 8 ысулын билгеләп: 1) фонетик, 2) кушымчалау, 3) нигезләр кушылу, 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе, 5) сүзтезмәнең, бер үк вакытта кушымча алып, кушма сүзгә күчүе, 6) конверсия (бер сүз төркеменә караган сүзнең һәм сүз формасының икенче сүз төркеменә күчүе), 7) лексик-семантик, 8) аббревиация.

Шунысын да әйтергә кирәк: тюркологиядә Фуат Ганиев тикшеренүләренә кадәр грамматикаларда, кагыйдә буларак, сүз ясалышының 3–4 ысулы гына карала. Өстәвенә сүз ясалышының өч ысулы – нигезләр кушылу, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе, сүзтезмәнең, бер үк вакытта кушымча алып, кушма сүзгә күчүе бер ысул – сүзләр кушу ысулы буларак өйрәнелә, бу исә татар телендәге кушма сүзләр ясалу системасын тамырдан бозып күрсәтә.

Тюркологиядә сүзьясалыш ысулы буларак конверсиягә игътибар бирмиләр диярлек, ә ул тулы бер системаны тәшкил итә һәм күпмедер дәрәҗәдә инглиз телендәге конверсияне хәтерләтә. Ф.Ә. Ганиев бер

хезмәтен тулысынча шушы проблемага багышлый. Һәм бу эш яшь диссертантлар тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә.

Татар телендә реликт күренеш буларак сүзьясалышының фонетик ысулы да сакланган, күренекле галимнең аның буенча язылган хезмәте дә дөнья күрә.

Галим кушымчалау ысулы белән сүзьясалышын структурфункциональ ысул белән, ягъни һәр кушымчалы сүзнең мәгънәсен ясаучы нигез мәгънәсе белән бәйләп тикшерә, бу исә сүзьясалыш мәгънәләрен объектив дөрес ачарга мөмкинлек бирә.

Бөтен тел белемендә сүз төзелеше, билгеле булганча, морфологик структура буларак карала. Фуат Ганиев сүздә ике структура таба: 1) сүзьясагыч структура; 2) морфологик структура. Галим фикеренчә, аларның үзара бернинди уртаклыгы юк: сүзьясалыш структурасы сүздә – лексик, морфологик структура грамматик мәгънәгә ия бар нәрсәне белдерә, ә бу исә лингвистикада бөтенләй яңа нигезләмә булып тора.

Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк: галим «суффикс» термины урынына «аффикс» терминын куллануга катгый каршы була. Билгеле булганча, аффикс термины префикс, конфикс, инфикс, суффикс, интерфикс һ.б. кебек күп кенә төшенчәләр өчен гомумиләштерүче термин булып тора.

Ф.Ә. Ганиев шулай ук омоним кушымчаларны аеру критерийларын билгели. Ул татар телендәге сүзьясагыч кушымчаларның барысын да исәпкә ала һәм анализлый, һәм аларның саны 2 тапкырдан күбрәккә арта.

Аерым яңа фәнни нигезләмәләр галимнең «Татарский язык: проблемы и исследования» (2005) хезмәтендә дә чагылдырылган. Ф.Ә. Ганиев татар тел белемендә сүзьясалышы дип аталган мөстәкыйль лингвистик дисциплина булдыра.

Билгеле булганча, төрки телләрне өйрәнүчеләр барысы да аларны агглютинатив телләр дип кенә карыйлар, ягъни аларда грамматик һәм лексик мәгънәләр агглютинация, ягъни кушымчалау (суффиксация) аша белдерелә дип аңлаталар. Мондый караш төрки телләрнең асылын һәм характерын тулаем боза, чөнки аларда лексик мәгънәләрнең яртысыннан артыгы, ә грамматик мәгънәләрнең яртысына якыны аналитик рәвештә, ягъни өстәмә сүзләр белән белдерелә. Күргәнебезчә, төрки телләрне агглютинатив телләргә генә кертү бик үк дөрес түгел. Төрки телләр – галим фикеренчә, агглютинатив-аналитик телләр. Моннан төрки телләр морфологиясенең яртылаш аналитик булуы аңлашыла. Төрки телләр лексикасында аналитик, ягъни катлаулы сүзләр бөтен лексиканың яртысыннан артыгын тәшкил итә. Бу нигезләмә, һичшиксез, галимнең зур ачышы булып тора.

Фуат Ганиев тюркологиядә беренче мәртәбә француз һәм инглиз телләрендәге кебек аналитик килешләрнең булуын билгели. Мәсәлән, татар телендә нуль кушымчалы исем + бәйлек конструкциясе киң кулланыла. Бу нигезләмә – татар тел белеме өчен дә, тюркология өчен

дә яңалык. Ф.Ә. Ганиев тәкъдим иткән әлеге яңа концепция буенча кандидатлык диссертациясе дә якланды.

Төрки телләрдә интерфикслар булуын билгеләү дә – тюркологиядә зур яңалык, ул әлегә кадәр дөрес аңлатылмаган күп кенә ясалма сүзләрнең һәм аларның формаларының төзелешен төгәл һәм дөрес ачарга мөмкинлек бирә *(алты+ш+ар)*.

Телебездә катлаулы лексик берәмлекләрнең бик күп булуын билгеләү дә татар лексикасын өйрәнүдә зур алга китеш булып санала. Чөнки сүзлекләр төзегәндә телнең мондый байлыгына игътибар бирелми, хәтта исәпкә дә алынмый. Галим сүзлекләр төзегәндә катлаулы сүзләрнең исәпкә алынмавын исбатлый. Шул сәбәпле төрки сүзлекләр бик ярлы күренә, ди ул. Хәзерге вакытта бу сүзләр сүзлекләргә кертелә.

Ф.Ә. Ганиевның фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсендә татар тел белемендә «морфология» һәм «синтаксис» белән беррәттән «сүзьясалышы» дигән яңа дисциплина барлыкка килә. Шул ук тикшеренүләргә нигезләнеп, галим татар тел белемендә беренче мәртәбә югары уку йортлары өчен «Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы» дигән уку әсбабы төзи (1988, 2003, 2005, 2009).

2009 елда Ф.Ә. Ганиевның «Функциональное словообразование в татарском литературном языке» дигән монографиясе нәшер ителә, тюркологиядә бу хезмәтнең аналогы юк. Хезмәттә сүзьясалышы мәгънәдән формага таба өйрәнелә. Ул татар телен чагыштырма-типологик планда өйрәнүдә зур әһәмияткә ия.

Ф.Ә. Ганиев чакыру буенча Төркиядә ике томлы «Төрки телләрнең гомуми грамматикасы»н төзүдә катнаша.

Ф.Ә. Ганиев – 300 дән артык фәнни хезмәт, шул исәптән 16 монография авторы. «Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы» дигән китабында галим татар сүзьясалышы өлкәсендәге барлык эзләнүләрен гомумиләштерә. Татар теленең өч томлы академик грамматикасының төзүчесе һәм фәнни мөхәррире Ф.Ә. Ганиев, башка авторлар белән бергә, әлеге хезмәт өчен Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек була.

Шуның белән бергә галим татар лексикографиясенә дә зур өлеш кертә. Ул – бер томлы «Русско-татарский словарь» (Казан, 1971), «Татарско-русский словарь» (Мәскәү, 1966) хезмәтләрен, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (Казан, 1977–1981) өчтомлыгын төзүдә катнаша. Аның фәнни җитәкчелегендә, редакциясендә һәм турыдан-туры катнашында «Татарско-русский словарь» (Казан, биш басма), «Русско-татарский словарь» (Мәскәү, дүрт басма), «Татарско-русский учебный словарь» (Мәскәү, Казан, өч басма) кебек саллы сүзлекләр басылып чыга, «Tatarca-türkçe sözluk» (Мәскәү) һәм «Türkçe-tatarca sözluk» (Мәскәү) һ. б. дөнья күрә.

2005 елда бер томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (басма табагы 143) дөнья күрә. Ул киң җәмәгатьчелек һәм белгечләр тарафыннан югары бәяләнә. Сүзлеккә тюркологиядә беренче мәртәбә

тезмә фигыльләр кертелә. С.И. Ожеговның бер томлы сүзлеге рус теле өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булса, бу сүзлек тә татар лексикографиясендә шундый ук роль уйный.

Аның фәнни җитәкчелегендә, редакциясендә һәм турыдан-туры катнашында «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге = Татарско-русский словарь личных имен и фамилий» (2006) хезмәте басыла. Анда татар исемнәре рус телендә транслитерациядә бирелгән. Әлеге сүзлектә төрле тармаклар һәм структуралар өчен кирәкле 7 000 мең кеше исеменең дөрес язылышы теркәлгән.

Ф.Ә. Ганиев татар теле орфографиясе проблемалары, аның фәнни нигезләрен тикшерү белән дә шөгыльләнә. Аңлатмалы сүзлекләрнең орфографиясен исәпкә алып, аның белән берлектә «Татар теленең орфографик сүзлеге»нең яңасы төзелә һәм басылып чыга. Бу аңлатмалы сүзлекләр орфографиясенең язу өчен норма булып торуы белән аңлатыла.

Галим тарафыннан 2009 елда, татар һәм рус телләрен өйрәнү өчен, оператив рәвештә «Русско-татарский словарь» (62,5 басма табак) эшләнә һәм нәшер ителә. «Тезмә фигыльләрнең аңлатмалы сүзлеге»нең беренче кисәге (А–К хәрефләре) басылып чыга. Бу сүзлек татар телендә фигыль системасының гаҗәеп бай булуын ачык күрсәтә, тюркологиядә аның аналоглары юк. Халык хуҗалыгының һәм мәдәниятнең төрле тармакларында эшләүчеләргә адресланып, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен курсларда һәм түгәрәкләрдә өйрәнү өчен, галим җитәкчелегендә 24 русча-татарча сүзлекчә эшләнә һәм дөнья күрә.

Алга таба «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» (автор табагы 70), «Русско-татарский словарь новых слов и новых значений» (автор табагы 40) «Татар-рус сүзлеге» (автор табагы 150) төзелә, 4 томнан торачак «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (автор табагы 450) төзү эше башлана. Бу сүзлекләр галим эшләп калдырган «инструкция» буенча төзелгән һәм төзелә.

Болар барысы да галимнең татар лексикографиясен үстерүгә зур өлеш кертүе турында сөйли.

Ф.Ә. Ганиев тарафыннан 117 доклад укыла, шуларның 24 е – Халыкара (Берлин, Бухарест, Прага, Мәскәү, Казан, Симферополь, Әнкара, Измир, Елази һ.б. шәһәрләрдә), 25 е – Бөтенсоюз һәм бөтенроссия конференцияләрендә. Галим 110 фәнни басманың фәнни мөхәррире була.

Ф.Ә. Ганиев үзенең фәнни мәктәбен булдыра. Аның җитәкчелегендә 31 кандидатлык диссертациясе яклана. Галим тәкъдим иткән яңа фәнни концепцияләр һәм нигезләмәләр буенча 14 докторлык һәм 25 кандидатлык диссертациясе языла һәм яклана. Фәнни консультация алу өчен, Казанга аның янына төрле төбәкләрдән һәм республикалардан да галимнәр еш килә.

Ф.Ә. Ганиев – Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан расланган «ТР халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү

буенча дәүләт программасы» һәм «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы законы проектларын әзерләүдә башлап йөрүчеләрдән. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую буенча галим төрле комиссияләрдә эшли, күпсанлы мәкаләләр бастырып чыгара, һәм аларда татар телен сүзләр түгел, ә гамәлләр генә дәүләт теленә әйләндерәчәген ассызыклап әйтә.

Зур фәнни эш алып бару белән бергә, Ф.Ә. Ганиев 30 елга якын Казан дәүләт университетында, Казан һәм Яр Чаллы педагогика институтларында махсус курслар алып бара, Башкортстан, Кабарда-Балкар университетларында, Алабуга дәүләт педагогика институтында лекцияләр укый. Докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклаганда, еш кына рәсми оппонент буларак чыгыш ясый.

Берничә ел дәвамында (өзеклекләр белән) галим Казан дәүләт университетында, Алабуга дәүләт педагогика институтында Дәүләт имтихан комиссиясе һәм Баш аттестация комиссиясе рәисе була.

Ф.Ә. Ганиев республиканың һәм үзе эшләгән Институтның иҗтимагый тормышында да актив катнаша: озак еллар Институтта профком рәисе урынбасары, аннан рәисе булып эшли. Лингвистика буенча Республика координацион советын җитәкли, СССР Фәннәр Академиясенең «Тел һәм җәмгыять» фәнни советы әгъзасы, татар телен гамәлгә ашыру буенча рәис урынбасары, Совет тюркологлары комитеты әгъзасы, ТР ФА ТӘһТИ Гыйльми советы әгъзасы, ТӘһТИ һәм КДУның диссертация советлары әгъзасы, Казан шәһәр думасының топонимика комиссиясе әгъзасы, Бөтенроссия шәркыятчылар җәмгыяте әгъзасы була.

Ф.Ә. Ганиев берничә дәүләт медале белән бүләкләнә.

Кембридж биографик үзәге (Англия) тарафыннан филологиягә зур өлеш керткәне өчен аның исеме «Знаменитые люди XX века» (1998), «Международные интеллектуалы: кто есть кто» (1999), «Современная наука» (2003) энциклопедияләренә кертелә, ул Төркия лингвистика җәмгыятенең чит ил мөхбир әгъзасы (2000) һәм Америка биографик институтының киңәшчесе (2000) итеп сайлана. Рус фәннәр һәм сәнгать академиясе тарафыннан аның исеме «Известные русские: кто есть кто на рубеже тысячелетия» (3 нче басма, 2000) биографик белешмәлегендә дә теркәлә.

Филология фәннәре докторы, профессор Ф.Ә. Ганиев татар тел белемен һәм тюркологияне үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертте.

***Алишина Хәнисә Чайдат кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Төмән дәүләт университеты профессоры*

***Алишина Ханиса Чайдатовна,***
*доктор филологических наук,*
*профессор Тюменского государственного университета*

*kaf_tatarlit@utmn.ru*

# КИТАП КҮЗӘТҮ: КОГНИТИВ ЛИНГВИСТИКАНЫҢ ПРОБЛЕМАЛЫ КЫРЛАРЫ

Сагдеева Ф.К. Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка): монография / Ф.К. Сагдеева. – Казань: редакционно-издательский центр «Школа», 2024. 206 с.

Хезмәтнең авторы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гомуми тел белеме бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Фәүзия Кәбир кызы Сәгъдиева. Монографиянең темасыннан аңлашылганча, сүз когнитив лингвистика турында баргач, тел төзелешенең кешеләрнең үзара аралашуын барлыкка китерү вазифасына караган хосусый үзенчәлекләреннән тыш, тел чараларында рухани/дини, сәнгати/мәдәни һәм иҗтимагый/матди дөньяви шартлар белән бәйләнештәге катлаулы мәсьәләләр дә игътибар үзәгендә булыр дип көтелә. Бу – хезмәтнең керешендә үк аңлатыла: «Актуальность иследования определяется его обращением к проблематике взаимоотношений объективной действительности, языка и мышления. На сегодняшнем этапе развития гуманитарных наук в языкознании на первый план выдвигается антропоцентрический подход, предполагающий исследование языковых феноменов в тесной связи с человеком, его мышлением и различными видами его духовно-практической деятельности» [6: 3]. Димәк, тел берәмлекләренең ни рәвешле файдаланылу мөмкинлеген, бу очракта адәм баласының аңында объектив чынбарлыкны кабул итеп, үзенчә мөнәсәбәт белдерелү юнәлешендә, ягъни бу дөньядагы яшәештә көндәлек аралашу чарасы булган телнең, тагын да катлаулырак вазифалар үтәгәндә, ничек кулланылуын тикшерү максаты куела.

Сүз уңаеннан, бу монографиясенә кадәр дә Ф.К. Сәгъдиеваның татар тел белеменең төрле катлаулы проблемаларын күзаллау һәм җентекләп тикшерү юнәлешендәге хезмәтләре булды. «Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия» китабында авторның 80–90 нчы еллардагы татар-рус һәм рус-татар икетеллелеге шартларындагы чынбарлыкның асылы, татар һәм рус телләре мөнәсәбәтендә икетеллелек күренешенең табигате, типлары, тел сәясәте һәм милли мөнәсәбәтләр яктылыгында татар сөйләмә һәм әдәби теленең норма һәм интерференция кебек катлаулы мәсьәләләре турындагы күпсанлы мәкаләләрендә әйтә башлаган фикерләре берләштерелеп тәкъдим ителә [2]. Авторның: «На сегодняшний день от признания права татарского языка быть одним из государственных языков до практической его реализации очень далеко» дигән фикеренең сәбәпләре санала һәм бу мәсьәлә хәзер дә актуальлеген югалтмый [2: 84–94].

Ф.К. Сәгъдиеваның аспиранты Д.Р. Гайнанова белән берлектә язылган «Татарский концепт как объект лингвокультурологического

анализа» дигән басманың [3] исеменнән аңлашылганча, китап тел белеменең актуаль юнәлешләреннән саналган, әмма татар филологиясендә аз өйрәнелгән лингвокультурология фәне проблемаларына һәм концепт категориясенең табигатен һәм вазифасын билгеләүгә багышлана. Тел өйрәнүдә фәнни ысулларның күптөрле булуын истә тотып, бу хезмәттә тема итеп күтәрелгән мәсьәләне өйрәнү һәм хәл итүнең хәзерге лингвистикада шартлы рәвештә алынган өч фәнни парадигмага нигезләнүе ассызыклана: 1) XIX гасырның беренче чирегендә формалашкан генетик/тарихи; 2) XX гасыр уртасында барлыкка килгән таксономик/системалы/структур (тел берәмлекләренең төзелеше катлаулы булуын, аларның төрле группаларга бүленешен аңлау); 3) антропоцентристик: коммуникатив, функциональ, прагматик.

Аңлавыбызча, әлеге парадигмаларның үз табигатьләрен һәм вазифаларын төгәлрәк күзалларга мөмкинлек биргән категорияләр белән яңача, катлаулырак өйрәнү юнәлеше сайлана. XX гасырның 60 нчы елларыннан төрле телләрдә тел һәм сөйләм системасына караган мәсьәләләрне традицион рәвештә, ягъни телнең үз чаралары белән генә түгел, когнитив лингвистика, лингвокультурология дигән яңа юнәлештәге фән категорияләрен аңлы рәвештә файдаланып өйрәнү проблемасы көн тәртибенә куела. Алга таба төрле телләрдә, төрле авторлар тарафыннан лингвокультурология фәненең төп категориясе булган *концепт* төшенчәсенең проблемалары, аларның ничек аңлатылуы күпсанлы мисаллар ярдәмендә күрсәтелә һәм нәтиҗә ясала: «Из вышеизложенного видно, что изучение концептов является одним из актуальных научных направлений не только в отечественном, но и в тюркском языкознании. Однако, несмотря на большое количество работ, посвященых данной теме, вопрос об изученности концептов остается нерешенным, что в свою очередь обуславливает актуальность данного направления в лингвистике» [3: 3–13].

Лингвокультурологик анализ хезмәтнең өч бүлегендә яктыртыла. Беренче бүлек теманың теоретик яктан нигезләнүе мәсьәләренә багышлана, лингвокультурология дигән фән тармагының фәнни аппараты формалаштырыла, «...предмет лингвокультурологии – национальные формы бытия общества, воспроизводимые в системе языковой коммуникации и основанные на его культурных ценностях, все, что составляет “языковую картину мира”», дип, үзенә хас предметы билгеләнә. Әлеге фәннең төп төшенчәләре булып саналган «языковая личность», «концепт», «культурная картина мира», «культурный концепт», «прецедентные феномены» һ. б. терминнар ачыклана, кешеләрнең әйләнә-тирә чынбарлыкны танып белү тәҗрибәсенең төрле авторлар тарафыннан ничек анализлануы билгеләнә. Мәсәлән, Ю.Н. Караулов фикеренчә, «...языковая личность – это любой носитель того или иного языка, охарактеризованный на основе анализа произведенных им текстов с точки зрения использования в этих текстах системных средств данного языка для отражения видения им окружающей действительности (картины мира) для достижения определенных

целей в этом мире» [3: 15]. Әлеге фикерләргә Ф.К. Сәгъдиева да үз мөнәсәбәтен белдерә, алар, нигездә, татар теленнән алынган мисаллар белән ныгытыла. Әлеге проблеманың автор тарафыннан берничә мәкаләдә яктыртылуы да игътибарны җәлеп итә. «Анализируемый материал показывает, у Ибрагимова портрет женщины не отождествляется с простым описанием внешности, ее лица, фигуры, одежды. В портрет включается описание внешнего и внутренного состояния героини, ее действий и взаимоотношений с другими персонажами, манеры говорить и образ мышления, а также описание характера» [4: 249]. Шушы ук юнәлештә Г. Исхакый иҗаты мисалында авторның дөньяви чынбарлыкны кабул итүендә мораль-этик категорияләрнең ассоциатив-мәгънәви эчтәлеге анализлана [5]. Димәк, лингвокультурологик юнәлештәге өйрәнүдә милли һәм мәдәни яссылыктагы факторларның әһәмиятен ассызыклау сорала. Әлеге нигездә төшенчә/терминнарның чынбарлыкка, гыйлемгә мөнәсәбәттә концептлашуында концептлар ике төргә – универсаль (фәлсәфи) һәм милли мәдәният категорияләренә яисә милли концептларга бүлеп карала. Галимнәр белдергәнчә, милли концептлар халыкның аңында урын алган күзаллаулар һәм стереотипларга нигезләнеп, телдә сүзләр, фразеологик берәмлекләр һәм паремияләр буларак чагылыш табалар. Биредә алар тел белән мәдәниятне үзара бәйләп торучы ачкыч сүз төшенчәсе буларак кулланыла. Культурологик концептлар әйләнә-тирә дөнья күренешләрен концептлаштыру нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм ул тел берәмлекләренең мәгънә компонентларында гәүдәләнә. Нәкъ менә шул нигездә фикер һәм тел күренешләре, телне өйрәнә торган фәнни тармаклар үзара берләшә һәм керешеп китә. Аерым алганда, лингвокультурология фәне күзлегеннән өйрәнгәндә тел һәм мәдәният мәсьәләләренең берләшүе күз уңына куела. Шулай итеп, әлеге фән тармагына караган тикшеренүләрдә чынбарлыкны кабул итүдә тел һәм фикерләүнең милли төшенчәләргә, тел, әдәбият һәм мәдәнияткә, аларны куллану һәм өйрәнү системалары берлегенә таянып гамәлгә ашырылуы ассызыклана. «Владение языком, предполагает владение концепттуализацией мира, отраженным данным языком; ...Язык выступает как способ создания и преобразования мысли» дигәндә, кеше өчен үз ана телен белүнең әһәмияте ассызыклана – адәм баласы үзе яшәгән дөньяви чынбарлыкны туган теле ярдәмендә кабул итә, хәтердә калдыра һәм мөнәсәбәт белдерә ала. Димәк, бу фәнни юнәлеш антропоцентристик парадигмага, ягъни кеше феноменына, аның аң-фикерләвенә, чынбарлыкны ничек күрүенә, инану-ышануларын ни рәвешле әйтеп бирә белү үзенчәлегенә нигезләнә. Бу юнәлештә тел гомумкогнитив механизм буларак карала. Әйтеп бирә белү дигәндә, гомумсөйләмә тел һәм язма текстлардагы аерым автор иҗатының үзенчәлекле мөмкинлеге истә тотыла [6: 14–70].

Шулай итеп, төрле телләргә караган күпсанлы фәнни хезмәтләр анализланып, лингвокультурологиянең фәнни аппараты, методологиясе нигезләнә. «К базовым понятиям лингвокультурологии относится

и понятие «концепт», – дип яза автор, һәм татар теле материалын киң кулланып, әлеге мәсьәләне җентекләп аңлата. «Настоящее исследование посвящено рассмотрению одного из значимых концептов татарской культуры *акча* (деньги). Деньги представляют собой особый товар и занимают значительное место в жизни человека, а стало быть, и в его языковом сознании. Следовательно, важен и концепт, который стоит за этим именем». Шул рәвешле, лингвокультурологиянең фәнни аппараты, эчтәлеге ачыклана, методологиясе билгеләнә, татар теле мисалында *акча* төшенчәсенең әлеге фән тармагының культуралы модель концепты буларак ничек кулланылуы тикшерелә, ягьни катлаулы теоретик нигездә гамәли эшчәнлек башлана һәм ике бүлек дәвамында тикшерү дәвам иттерелә. Бу бүлекләр белән танышу һәм зиһенгә алу барышында татар теленең сүз/сөйләм байлыгының дәрәҗәсе күптөрле чаралар белән халыкның фикерләү үзенчәлеге, иҗтимагый яшәешкә мөнәсәбәт белдерелү кебек мәсьәләләргә нигезләнеп күрсәтелә һәм укучыга беренче мәртәбә тәкъдим ителә [3: 71–157].

Алга таба шундый ук катлаулы эшчәнлек, Ф.К. Сәгъдиеваның икенче аспиранты Ч.З. Абдуллина белән бергә язылган «Татарстан Республикасында тел вазгыяте: татар теленең кулланылыш даирәсе» дигән хезмәттә дәвам иттерелә [1]. Китапның керешендә «...173 милләт вәкиленең туган йорты булган Татарстан Республикасында барган җәмгыяви үзгәрешләрне өйрәнү, аларга тел сәясәтенә мөнәсәбәтле рәвештә бәя бирүнең аеруча әһәмиятле» булуы ассызыклана. Шунда ук тел үсеше өчен уңай дип саналган тышкы факторлар турында мәгълүмат бирелә. Авторның «Без хәзер дәүләт теле статусындагы тел турында түгел, ә туган тел / ана теле турында сүз алып барабыз», дигән фикере актуаль һәм мөһим. Сәясәтчеләрнең күбесе әлеге мәсьәләне күтәрми, сөйләмә тел белән язма телнең вазифаларын аермыйча, нечкәлекләрен белмичә, гомумиләштереп сөйләүне дәвам итәләр.

Димәк, бу очракта тел кулланылышы мәсьәләләренең социолингвистика фәненең методы/ысулы таләпләре нигезендә аның категория/төшенчәләрен файдаланып анализлануы аңлашыла. Әлеге проблема «Тикшеренүнең теоретик һәм практик аспекты» дигән беренче бүлектә 1) тел вазгыятен социолингвистик яссылыкта өйрәнү; 2) Татарстан Республикасында тел сәясәте һәм милләтара мөнәсәбәтләр; 3) татар һәм рус телләренең кулланылышы (сорашу нәтиҗәләре буенча) дип аерып тикшерү барышында, «тел ситуациясе/вазгыяте» төшенчәсе, телнең үз системасына, җәмгыять системасына, кешеләрнең яшәеш системасына караган катлаулы бәйләнеш-мөнәсәбәтләре һәм аларның күптөрле фәнни хезмәтләрдә ничек өйрәнелүе/анализлануына таянып күзаллана, күптөрле фикерләр игътибарга алына, аларның һәркайсына авторның мөнәсәбәте белдерелә [1: 8–62].

Хезмәтнең «Татарстан Республикасында татар теленең кулланылыш мохите» дигән икенче бүлегендә гаилә мохитендә, мәгариф системасында, массакүләм мәгълүмат чараларында, тел һәм дин мөнәсәбәтендә татар теленнән файдалану мәсьәләләре анализлана.

Алдагы бүлектәге кебек үк, аерым проблемалар өйрәнелә башлаганчы, төп төшенчә/терминнарга аңлатма бирелә: бу очракта телнең функциясе, факторлары дигән төшенчәләр күз уңында тотыла, аларның фәнни хезмәтләрдә өйрәнелүенә күзәтү ясала; «70 елдан артык вакыт дәвамында яшәгән СССРда дәүләт составында булган халыкларның телен һәм мәдәниятен саклау буенча эш алып барылмый, булган очракта да ул бары сүздә генә кала дип уйларга була» кебек объектив фикерләр куәтләнә; беренче бүлектән аермалы буларак, 5 параграфка бүлеп анализлана [1: 63–121]. Хезмәтнең «Аерым бер җирлектә тел ситуациясен өйрәнү берничә юнәлешне күздә тотып эш итүне таләп итә. Бу аның социологик, этник, сәяси, лингвистик фактор белән аерылгысыз бәйләнештә булуы белән аңлатыла», дип башланган йомгак өлештә әлеге мәсьәләләр тагын бер тапкыр искәртеп үтелә [1: 122–125].

Кушымтада «Урта буыннар өчен сораулыклар» [1: 126–129]; «Мәктәп яшендәгеләр өчен сораулыклар» [1: 130–133] үрнәге бирелә. Анда түбәндәге юлларны укыйбыз: «Күпмилләтле Татарстан республикасында, тугандаш халыклар гаиләсендә яшибез. Иҗтимагый тормыш таләбеннән чыгып та, гаиләбездәге шартларга карап та, төрле телдә аралашабыз. Әмма һәр кешенең, нинди дәүләттә яшәвенә, нинди телдә аралашуына карамастан, үз туган теле бар. Тормыш шартлары таләбенә буйсынып, без аны бераз читкәрәк куйган булсак та, ул күңел түрендәге урынын саклый. ...Анкета сорауларына бирелгән җаваплар гомумиләштерелеп, бары тик фәнни максатларда гына файдаланыла».

Шулай итеп, саналган хезмәтләргә мөнәсәбәттә, Ф.К. Сәгъдиеваның иҗади эшчәнлеген кыскача гына күзаллап, нинди темаларның күтәрелүе, аларга хас мәсьәләләрнең ничек тикшерелүен зиһенгә алып барудан аңлашылганча, авторның «Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка)» дигән монографиясенә кадәр дә, соңгы елларда тел белемендәге өч төрле парадигмага бүлеп каралган когнитив лингвистика, антропоцентристика, лингвокультурология һ. б. яңа фәнни юнәлешләр гамәлгә куелу, һәр фән тармагының фәнни аппараты формалаштырылып, хосусый термин/категорияләрнең табигате һәм вазифасы билгеләнү барышында күпсанлы фәнни хезмәтләр анализлана, аларга авторның үз мөнәсәбәте белдерелеп, фәнни югарылыкта һәм эзлекле системада аңлатыла. Бу китапта, когнитив лингвистика фәнни юнәлеше тема итеп алына, башка фәнни тармакларга мөнәсәбәттә бирелгән аерым фикерләр конкретлаштырылып, бер ноктага тупланып, аңлау/аңлату объекты итеп куела. «В языкознании под когнитивистикой принято понимать область взаимоотношения языка, мышления и сознания, истоки которого находятся в глубоких пластах лингвистической мысли» [6: 3]. Хезмәтнең керешендә тема итеп күтәрелгән проблеманың, классик тел белеменә нигезләнеп, Европа һәм рус телчеләре тарафыннан күптәннән тикшерелеп килүе нәтиҗәсендә яшәве, хәзерге вакытта

(2003 елдан) Россия Федерациясендә 50 субъектны берләштергән «Российская ассоциация лингвистов-когнитологов» дигән берләшмәнең юридик статус алуы һәм аның максаты турында әйтелә. Когнитивистика дигән фән тармагы категорияләре белән тикшерү барышында, сөйләүченең чынбарлыкны ничек кабул итүен, аң/акыл/фикерләү үзенчәлегенең аның сөйләмендә ничек чагылуын, башта чит ил галимнәре, аннан рус галимнәре тарафыннан бу фән тармагында нигезләнгән метод/методиканың ничек гамәлгә куелуын автор җентекләп аңлата һәм болай ди: «В русистике имеется множество работ, посвященных осмыслению задач когнитивной лингвистики. Однако в татарском языкознании указанная тема почти не освещается, что создает трудности, связанные с пониманием новых задач современной татарской лингвистики» [6: 3–8]. Димәк, автор бу хезмәтендә, хәзерге татар тел белемендә когнитив лингвистиканың яңа мәсьәләләре җитәрлек дәрәҗәдә яктыртылмау сәбәпле, әлеге фәннең аерым бер проблемалы кыры булуын күтәрә, «на материале татарского языка» дип, яңа фән таләпләренә туры килү юнәлешендә тикшерелү мәсьәләләрен билгеләүне максат итә. Шуның белән бергә, авторның «...лингвокультурологический анализ...» дип тикшерелә торган хезмәтендә дә, теоретик нигезләүләрнең татар теле мисалында да аңлатылуы мәгълүм [6: 28–29; 68–70; 125–128]. Бу монографиядә, җиде бүлекчәдән торган беренче һәм икенче бүлекләрдә, когнитив лингвистиканың хәзерге вакытта проблемалы саналган кырларының ничек тикшерелүен аңлатканда, чит ил һәм рус галимнәренең фикерләре белән бергә, татар филологларының хезмәтләренә дә мөрәҗәгать итеп, асылда, милли үзенчәлекне ассызыклау максатыннан, тарихи юнәлеш сакланган хәлдә, мисаллар анализлана [6: 32; 43–51; 54–88; 98 һ. б.] Нәтиҗәдә, когнитив лингвистиканың, хәзерге вакытта яңалык дип саналган 1) концептлашу һәм категорияләшү мәсьәләләренең дөньяви чынбарлыкка нигезләнеп аңлатылуы, 2) гыйлем/белемгә нигезләнеп баруы кебек актуаль мәсьәләләр тикшерелгәндә, башка телләр белән беррәттән, татар теленә караган мәсьәләләрдә дә «...системы понятий в сознании человека, особенности процессов восприятия и мышления определяются этноспецифическими особенностями структуры языка» икәнлеге аңлашыла [6: 9–21]. Алга таба Ф.К. Сәгъдиева күп кенә татар телчеләренең хезмәтләренә тукталып, алар файдаланган төрле типтагы метафораларда [6: 29–102] һәм абстракт мәгънәле исемнәрнең кулланылышында милли тел һәм милли күзаллау, милли аң һәм мәдәниятнең ничек чагылуын анализлый [6: 103–169]. Шулай итеп, бу тармакларда татар теле беренче мәртәбә когнитив лингвистика таләпләренә туры китереп өйрәнелә һәм алдагы тикшеренүләргә үрнәк була. Тикшерү барышында телдәге метафораларның объектив – коллектив коммуникатив функция башкаруын, эстетик сәнгатьчә метафоралар авторының мәгълүм субъектив-уникаль эстетик функциягә ия булуын аерып күрсәтү, әмма әлеге мәсьәләнең татар телендә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәвенә игътибар бирү мөһим

[6: 40–52]. Метафораларның типларын тикшергәндә дә, әлеге бүленеш саклана, әмма игътибар җитәрлек түгел, анализ, асылда, чыганак буларак алынган сүзлек материалына нигезләнә [6: 85 һ. б.]. Шуның белән бергә, автор вакыт категориясенә бәйле метафорик күзаллауларның татар телендә ислам дине кыйммәтләре йогынтысында формалашуын белдерә: «...В исламе время понимается как величайший дар Всевышного, в рамках которой вся жизнь человека, каждый день его бытия представляется как благой дар Аллаха, данный для подготовки к вечности». Мөселманның әлеге вакыт аралыгында ничек яшәвен тәфсилләп аңлатканда, вакыт төшенчәсенең ни рәвешле концептлашуы күзаллана [6: 95–99]. Әлеге катлаулы мәсьәләләрне зиһенгә алганда, милләтебезнең ислам дине кануннары буенча тормыш кичерүенә тел күзлегеннән карап, өч фәнни юнәлештә – аның көндәлек сөйләмдә ничек файлаланылуын, сәнгатьчә әдәби әсәрләрдә ничек тасвирлануын һәм когнитив лингвистикада ничек аңлатылуын тикшерү мөмкинлеге ачыклана. Әлеге тармакларны берләштереп өйрәнү яңача тикшерүгә юл ачу, когнитив лингвистиканың колачын киңәйтү булачак.

Бу юнәлештә эшләргә ниятләгәндә, фикерләү процессы дип белдерелә торган абстракт мәгънәле исемнәрнең дә текст дип алынган катлаулы параметрда ничек кулланылуын, ягъни конкрет мәгънәле сүзләр белән үзара мөнәсәбәтен, гомумтел берәмлегенә нигезләнеп, коммуникатив сөйләм тексты һәм сәнгатьчә әдәбиләшкән (культуралашкан) сөйләм текстының когнитив лингвистика фәне тармагында үзләренә хас категорияләр белән ничек концептлашуын күзаллап, тел һәм сөйләм системасын яңа яктан ачу максаты көн тәртибенә куела дип аңларга мөмкин.

Шул рәвешле, Ф.К. Сәгъдиеваның «Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка)» монографиясендә, авторның башка хезмәтләрендәге кебек үк, бүгенге татар тел белемендә махсус тикшерелмәгән күптөрле фикерләр күтәрелә, яңа юнәлештәге фән тармагы буларак, аның үзенә хас фәнни теориясе формалаштырыла, төшенчә/терминнарның мәгънәсен аңлату нигезендә гамәли юнәлештәге эшчәнлек дәвам итә. Чит ил һәм рус галимнәренең хезмәтләре белән беррәттән, татар телчеләренең фикерләренә дә мөнәсәбәт белдерелә. Хәзерге вакытта тел өйрәнүдә яңа юнәлеш саналган когнитив лингвистика фәненең чишелеп бетмәгән проблемалы кырлары ачыклана. Иң мөһиме шул: әлеге хезмәттә игътибар үзәгенә куелган фикерләргә нигезләнеп, татар филологиясендә яңа фәнни юнәлешне тәшкил итәчәк тикшеренү күзаллана. Бу типтагы фәнни хезмәтләр, асылда, докторлык диссертациясе дәрәҗәсендә бәяләнә ала.

**Әдәбият**

1. *Абдуллина Ч.З., Сәгъдиева Ф.К.* Татарстан Республикасында тел вәзгыяте: татар теленең кулланылыш даирәсе. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 136 б.

2. *Сагдеева Ф.К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. Казань: Фикер, 2002. 160 с.

3. *Сагдеева Ф.К., Гайнанова Д.Р.* Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа. Казань: ИЯЛИ, 2017. 248 с.

4. *Сагдеева Ф.К.* Концепт хатын-кыз (женщина) как фрагмент индивидуально-авторской картины мира Г. Ибрагимова // Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы. Халыкара конференция материаллары. Казань, 2017. Б. 246–250.

5. *Сагдеева Ф.К.* Ассоциативно-смысловое содержание морально-этических категорий в индивидуально-авторской картине мира Г. Исхаки (на примере прозаического произведения «Теләнче кызы») // Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы. Халыкара конференция материаллары. Казан, 2018. Б. 316–319.

6. *Сагдеева Ф.К.* Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка): монография. Казань: Редакционно-издательский центр «Школа», 2024. 206 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (Казан)*

***Баширова Илида Басыровна,***
*доктор филологических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан (Казань)*

*lilvil25@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Ә.Х. Алиева***

# ФАТИХ ӘМИРХАН – СҮЗ СӘНГАТЕ ОСТАСЫ (алты томлы академик басманың 2 нче[1] һәм 3 нче[2] томнары дөнья күрү уңае белән)

В статье представлена рецензия на второй и третий тома академического издания сочинений классика татарской литературы Фатиха Амирхана (1886–1926) в 6-ти томах, подготовленного научными сотрудниками отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ. Определяются новации нового издания. Во второй том вошли произведения, написанные автором в период 1912–1924 годов. Третий том включает в себе роман и драматические произведения автора, написанные в 1910–1922 годы. Дается краткий анализ материалов второго и третьего томов, что позволяет определить научную новизну данного академического издания. Делается вывод о том, что новое академическое издание восполняет существующие в текстологии Ф. Амирхана лакуны и открывает новые возможности для исследователей его творчества.

**Ключевые слова:** татарская литература, роман, рассказ, драма, Фатих Амирхан, академическое издание, текстология произведений Ф. Амирхана.

The article provides a review of the second and third volumes of the academic edition of the works of the classic of Tatar literature, Fatikh Amirkhan (1886–1926), in 6 volumes, prepared by senior researchers of the Department of Textology at the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art of the Tatar Academy of Sciences. The innovations of the new edition are determined. The second volume includes works written by the author between 1912 and 1924. The third volume includes a novel and dramatic works written by the author between 1910 and 1922. A brief analysis of the materials in the second and third volumes is provided, which helps to determine the scientific novelty of this academic publication. It is concluded that the new academic edition fills in the lacunae in F. Amirkhan's textology and opens up new opportunities for researchers of his work.

**Keywords:** Tatar literature, novel, short story, drama, Fatikh Amirkhan, academic edition, textology of F. Amirkhan's works.

Күренекле татар язучысы, драматург, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан (1886–1926) – XX йөз башы татар әдәбияты тарихында, аның җәмәгатьчелек фикере тарихында зур хезмәт күрсәткән классик язучыларның берсе. Ул үзенең реалистик карашы,

[1] *Әмирханов М.-Ф. М.-З.* Әсәрләр: 6 томда / Фатих Әмирхан. Академик басма. 2 т.: хикәяләр (1912–1924) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.Н. Зәйниева, Г.А. Хөснетдинова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 415 б.

[2] *Әмирханов М.-Ф. М.-З.* Әсәрләр: 6 томда / Фатих Әмирхан. Академик басма. 3 т.: роман, драма әсәрләре (1910–1922) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Ә.Х. Алиева, Г.М. Ханнанова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 366 б.

язу осталыгы ягыннан үз чорының характерлы якларын сәнгати чаралар аша оста гәүдәләндерүе белән таныла.

«ХХ йөз башы татар әдәбияты тарихында Ф. Әмирхан иҗаты әдәбиятны идея-эстетик яктан үзгәртүләрне башлап җибәрүе, милли мәдәниятне күптөрле тәҗрибәләр аша үстерүе һәм бу вакытта шәркый традицияләрне урынлы куллануы белән үзенчәлекле», – дип яза филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина әлеге алты томлы академик басмага язган кереш сүзендә. «Егерменче еллар әдәбияты өчен бу иҗат – 1917 елга кадәр формалашкан юнәлешне саклаучы, татар әдәбиятының фикри һәм форма ягыннан казанышларын югалтмыйча, алдагы буыннарга тапшырырга ярдәм иткән нигез баганаларыннан. Язучы шәхесе исә – гражданлык фидакярлеге үрнәге буларак аерым хөрмәткә лаек» булуын ассызыклый.

Язучы Фатих Әмирханның шәхесе, иҗаты һәрвакыт әдәбиятчыларның күз уңында тора. Бу табигый, чөнки Ф. Әмирхан – иҗаты татар әдәбиятында, тарихында мөһим роль уйнаган шәхесләрнең берсе. Аның иҗаты һәр чорда инде үзенчә бәяләнгән, фәнни нигездә тикшерелгән дияргә мөмкин. 1941 елда беренче тапкыр «Сайланма әсәрләр»е дөнья күргән, 1957–1958 елларда ике томлы «Сайланма әсәрләр»е һәм 1984–1989 елларда дүрт томлы «Әсәрләр» җыелмалары нәшер ителгән. Шуңа карамастан язучының үз чорында басылып та, төрле иҗтимагый-сәяси сәбәпләр белән томлыкларына керми калган әсәрләре, публицистик мәкаләләре, архив документлары, яңа истәлекләрнең табылып торуы Ф. Әмирханның яңа томлыкларын эшләү кирәклеген заман таләбе итеп куя.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге галимнәре Фатих Әмирхан әсәрләренең алты томлы академик басмасын әзерләү белән шөгыльләнәләр. Академик басманың фәнни төзелеше, беренче чиратта, Ф. Әмирханның татар әдәбияты классигы булуын истә тотып билгеләнгән. Әдәби әсәрләре 1–3 нче томнарга, ХХ гасыр башының актуаль мәсьәләләрен, заман вакыйгаларын яктырткан публицистик мәкаләләре 4–5 нче томнарга, тормыш юлы һәм иҗатына бәйле хатларны һәм архив чыганакларын исә 6 нчы томга урнаштыру планлаштырылган. Аның инде беренче өч томы Татарстан китап нәшриятында басылып та чыкты. Анда әдипнең барлык табылган әдәби әсәрләре туплап бирелгән. Китаплар белән танышкач, академик басмага хас шартларның үтәлгәнлеге, ягъни әсәрләрнең вариантлары керергә, текст тарихлары җентекләп тикшерелергә, аңлатмалар һәм искәрмәләр тулы, объектив булырга тиеш дигән максат куеп эшләнгәне күренә.

Күптән түгел басылган 2 нче томда язучының 1912–1924 елларда иҗат ителгән хикәяләре урын алган. Әлеге әсәрләр «Аң», «Ак юл», «Шәрык кызы» журналларында, «Кояш» газетасында һәм аерым китап буларак «Фатих Әмирхан», «Ташмөхәммәд», «Ф. Әмирхан», «Ф.Ә.», «Т-д» имзалары белән нәшер ителгән.

Структур төзелешенә килгәндә, том төп өлеш, искәрмә һәм аңлатмалар, кушымта бүлекләреннән тора. 28 хикәяне туплаган 2 нче томда Ф. Әмирхан иҗатының беренче чорында чәчәк аткан көлү талантының традицияләрен дәвам иттергән «Хәзрәт үгетләргә килде...», «Габделбасыйр гыйшкы» кебек сатирик хикәяләре дә, «Кадерле минутлар», «Сүнгәч» һ. б. кебек мәхәббәт, гаилә һәм хатын-кыз хәленә кагылышлы әсәрләре дә урын алган. Шулар белән бергә бу томда әдипнең балалар өчен тәрбияви әһәмияткә ия булган «Ул үксез бала шул!», «Корбан», «Нәҗип», «Балалар атавы» һ. б. хикәяләре дә тәкъдим ителгән. Язучы бу әсәрләрендә балалар дөньясын төрле яктан ача, төрле яссылыкта тасвирлый. «Ул үксез бала шул» хикәясендә балаларда тәкәбберлек, мактанчыклык, ятимнәрне рәнҗетү кебек сыйфатларны күрсәтсә, «Корбан» хикәясендә бала күңелендә төзәлмәслек яра калдырган корбан чалу вакыйгасын сурәтли. Ф. Әмирхан балаларның самимилегенә, эчкерсезлегенә сокланып иҗат иткән.

Әмирханның барлык әсәрләре дә инде табылып, ачыкланып беткән дип уйланылса да, автор-төзүчеләр эзләнү процессында язучының киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган яңа әсәрен табуга да ирешкәннәр. Ул 1914 елгы «Кояш» газетасының 23 февраль санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән Сөембикә манарасы хакында басылган «Искергән баһадир» әсәре.

Әдәбиятчы Ф. Ибраһимова тарафыннан текстологик яктан эшкәртелеп, «Әдәби мирас» (Казан, 1991) җыентыгында басылган, кулъязмасы Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә сакланган «Шәфигулла агай», «Халык кызлары» («Халык кызлары», 1995) циклыннан үзенең табигате белән гүзәллек, акыллылык символы булган һәм шул ук вакытта татар тарихының иң драматик мизгелләрен чагылдырган Сөембикә образын сурәтләгән «Сөембикә», халыкта яшәгән Зөлхәбирә хакындагы легендага нигезләнеп язылган «Картада оттырылган Зөлхәбирә» хикәяләре Ф. Әмирхан әсәрләренең академик басмасына беренче тапкыр кертелә.

Ф. Әмирхан бу хикәяләрендә татар тарихы белән бәйле булган вакыйгаларга мөрәҗәгать итә һәм аларны әсәрләрендә оста итеп сурәтләп бирә. Әсәрләрдә тасвирланган татар халкының үткәне, аеруча хатын-кыз язмышы белән бәйле фаҗигалы күренешләр, күз алдында җанланып, укучыда тирән фикер уята, уйланырга мәҗбүр итә. Хикәяләрнең фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелүе аерым игътибарга лаек.

Алдагы елларда нәшер ителгән «Әсәрләр»енең «Публицистика» (1989, 3 т.) томында басылган «Шәрык йоклый...» (1912), «Фәрештәләр юатсыннар сине!» (1914), «Мирзалар авыруы» (1919) язмаларының әдәби әсәрләр буларак 2 нче томда лаеклы урыннарын алулары томның фәнни яктан да камилләшкән булуын күрсәтүче фактларның берсе.

Хезмәтнең тагын бер әһәмиятле ягы – язучының иҗат лабораториясен тулы итеп күзаллау өчен, томда авторлар тарафыннан «Ике

вариантлы әсәрләрнең беренче варианты» дигән аерым бүлекнең урнаштырылуы. Әсәрнең берничә вариантын томлыкларга урнаштыру – академик басма төзү принципларының бер үзенчәлеге. Берничә басма вариантлары булган «Хәзрәт үгетләргә килде», «Куркыныч дошманнар», «Танс кичәсе», «Балалар атавы» әсәрләрнең беренче вариантлары тәүге тапкыр укучылар игътибарына тәкъдим ителгән. Ф. Әмирхан аларның күләмен генә түгел, сюжет элементларын, кайбер геройларның исемнәрен дә үзгәрткән, әдәби алымнар белән баеткан. Алга таба бу әсәрләр фәнни әйләнешкә кертелеп, Ф. Әмирхан иҗатын тирәнтен өйрәнергә, илдә хөкем сөргән яңа идеологиянең авторга тәэсирен ачыграк күзалларга ярдәм итәр.

Томда «Язылу еллары билгесез аерым кисәкләр» бүлеге дә аерым игътибарга лаек. Монда исемнәре, башы-ахырлары булмаган, шартлы рәвештә исемнәр куелган әсәрләрнең өзекләре урнаштырылган. Әлеге кулъязмалар (монда аларның гарәп шрифтында язылган булуын әйтеп китү урынсыз булмас) Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә Ф. Әмирханның шәхси фондында (16 нчы фонд) саклана.

3 нче томга язучының 1909 – 1922 еллар аралыгында язылган «Урталыкта» (1912) романы һәм «Яшьләр» (1909), «Тигезсезләр» (1915), «Фәтхулла хәзрәт» (1922) исемле драма әсәрләре, «Тәмамланмаган пьесалар» дигән баш астында исеме билгесез пьесаларыннан сакланып калган зур булмаган өзекләр урнаштырылган. Китап әдипнең 1912 елда ике том булып басылып чыккан «Урталыкта» романы белән ачыла. Тормышчан реализм белән сугарылган бу романда автор җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп кору өчен искелек тарафдарлары белән араны өзгән, әмма яңалык өчен көрәшүчеләр сафына баса алмаган, урталыкта чайкала торган психологик тип буларак та кызыклы Хәсән Арсланов мисалында тормышта үз юлын эзләгән татар интеллегенциясенең типик вәкиле образын тудырган.

Алга таба томда драма әсәрләренә урын бирелә. Хронологик тәртиптә урнаштырылган бу пьесалардан әдипнең фикер үсешен, драматург буларак формалашуын эзлекле рәвештә күзәтергә мөмкин. «Яшьләр» (1909) һәм «Тигезсезләр» (1915) исемле пьесалары Ф. Әмирханны талантлы драматург итеп таныта.

Татар тормышындагы үзгәреш чорын чагылдырган «Яшьләр»дә автор үзе: «Бу кычкырышлар, бу тавышлар безнең белән этиләр арасында... түгел. Бу тавышлар – иске тормыш белән яңа тормыш арасында» дип, әсәрнең төп герое Газиз авызыннан әйттерә.

Пьесаның чын мәгънәсендә реализм әсәре икәнлеген күрсәтә торган төп момент, төп проблема буларак – милләтне мәгърифәт юлы белән генә алга җибәрү мөмкин түгел. Татарны алга җибәрү өчен милләтнең фәкыйрь катлауларына, халыкка милли хис кертергә, үзаңын үстерергә кирәклек ассызыклана.

«Фәтхулла хәзрәт» (1922) комедиясе авторның шул исемдәге повесте нигезендә язылган. Пьесада татар тормышының 50 елга

якын аралыктагы үзгәрешен шулкадәр кызыклы да, көлкеле дә, бер үк вакытта мәдәниятнең, фән-техниканың алга китешен (фантастик планда) тасвирлаган бу пьеса укучыны мавыктырып үз эченә алып керә. Әсәрне тоташтан укып бетермичә, аерылып булмый. Ф. Әмирхан үзе күргән, тәрбияләнгән рухани гаиләдәге тормышны эчтән белеп, аңлап сурәтләгән Фәтхулла хәзрәт образы авторның юморга бай теле, күптөрле сурәтләү чаралары кулланып язган стиле теләсә нинди яшьтәге укучыны җәлеп итә, битараф калдырмый.

«Фәтхулла хәзрәт» пьесасы Ф. Әмирхан үзе исән чакта басылып өлгерми. Пьеса, сәхнәгә куяр өчен, ТАССР ның халык артисты Касыйм Шамил үтенече белән Ф. Әмирхан тарафыннан «Фәтхулла хәзрәт» повесте нигезендә эшләнә. Пьесаның кулъязмасын Язма мирас үзәгенә 1940 елның 27 гыйнварында Касыйм Шамил тапшырган була. Кулъязма белән бергә пьесаның язылу тарихына бәйле аңлатма язуы да теркәлгән. Бу хакта томның «Искәрмәләр һәм аңлатмалар» бүлегендә укучылар өчен кызыклы мәгълүмат бирелгән.

«Тәмамланмаган пьесалар» дигән бүлектә язылу даталары билгесез өч әсәрнең өзекләре Язма мирас үзәгендә саклана торган кулъязма вариантлардан алып урнаштырылган.

Әйтергә кирәк, Ф. Әмирханның 6 томлы академик басмасының 2–3 нче томнары текстология фәненең бүгенге таләпләренә җавап бирә торган фәнни дәрәҗәдә эшләнгән. Укучы текстларны җиңел кабул итсен өчен, XX йөз башы татар телендә еш очрый торган гарәп-фарсы, төрек яки башка телләрдән кергән аңлашылмаган сүзләргә астөшермәдә, контекстка туры китереп, тәрҗемәләр бирелгән, аларның хәзерге телдәге эквивалентлары китерелгән.

2–3 нче томнарның һәрберсендә «Искәрмәләр һәм аңлатмалар» бүлеге аерым әһәмияткә ия. Биредә һәрбер әсәрнең төрле басмалары, кулъязмалары хакында мәгълүмат бар. Язылу һәм басылу тарихлары ачыкланган. Укучыга текстны үзләштерүне җиңеләйтү максатыннан текстларда очраган тарихи вакыйгалар, шәхесләр, географик атамалар турында бөртекләп җыелган төгәл, бай, тәфсилле мәгълүмат бирелгән. Бу бәһасез зур хезмәт текстологларның фәнни әзерлекле, киң эрудицияле галимнәр булуын күрсәтә.

Әдипнең иҗаты җәмәгатьчелектә һәрвакыт кызыксыну уяткан. Ф. Әмирханның яңа әсәре басылып чыккач яки драма әсәрләре сәхнәдә уйналгач, шул чор матбугатында аларга карата мәкалә-бәяләмәләр пәйда булган. Тәнкыйть мәкаләләре, бәяләмәләр арасында Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Кәрам, И. Бикколов, Г. Толымбайский, Г. Камал, Х. Искәндәров һ. б. кебек билгеле әдәбиятчы галимнәрнең язмалары да, имзасыз, төрле тәхәллүс астында язылганнары да бар. «Йолдыз», «Сибирия», «Кояш», «Аң», «Тормыш», «Безнең юл» кебек газета-журнал битләрендә дөнья күргән әлеге мәкаләләр томнарны төзүчеләр тарафыннан 2–3 нче томнарның «Кушымта» бүлегендә бергә тупланып биргәннәр. Фатих Әмирхан әсәрләренә карата замандашлары тарафыннан язылган, әмма бүгенге

көн укучысына таныш булмаган рецензия-бәяләмәләрнең урын алуы да – академик хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен дәлилләүче фактор. Шул заман матбугатында басылган әлеге бәяләмәләр язучының үз чоры әдәби барышындагы урынын билгеләргә, иҗатының укучылар тарафыннан ничек кабул ителүен, бәяләнүен күзалларга ярдәм итәләр, бер үк вакытта томның фәнни яктан да әһәмиятен арттыралар. Төзүчеләрнең моңа кадәр киң катлау укучыларга билгеле булмаган байтак материалларны киң даирәгә тәкъдим итүе, аларны фәнни әйләнешкә кертүе дә мактауга лаек.

Бу язмалар хәзерге укучы өчен дә кызыклы булыр, XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтен күзалларга ярдәм итәр дип ышанабыз. XX йөз башы вакытлы матбугатында гына сакланган, гарәп хәрефләре белән язылган рецензияләр укучылар игътибарына беренче тапкыр тәкъдим ителгән. Элекке басмаларыннан аермалы буларак, бу томнарда совет чоры идеологиясеннән арындырып язылган шәрехләрдә шактый бай фактик материал тупланган. Мондый тәҗрибә хезмәтнең әһәмиятен һәм фәнни кыйммәтен тагын да арттыра.

Күпкырлы әдәби талантлы, киң эрудицияле булуы, сүз сәнгатендәге осталыгы белән Ф.Әмирхан замандашлары Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Камал кебек талант ияләре белән бер сафта торып, XX гасыр башы яңа татар әдәбиятының нигез ташларын салучыларның берсе буларак әдәбият тарихына керде. Язучының үз чоры татар дөньясындагы көнүзәк проблемаларны җанлы кеше образлары, реалистик вакыйга, конфликтлы ситуацияләр аша тасвирлаган драма әсәрләрен туплаган 3 нче томы бүген дә укучыны битараф калдырмый. Аларны тоташтан, эстетик ләззәт алып, тормыштагы күптөрле ситуацияләрне илебез тарихындагы, шул исәптән татар җәмгыятенең үзгәреш чорындагы коллизияләр турында кайсы юмор белән, кайсы татар әдәбиятын рус һәм дөнья әдәбиятына якынайтып язылган юлларны укып, әдәбиятыбызның үсеш баскычларын күзалларга мөмкин.

***Алиева Әнисә Хәниф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Алеева Аниса Ханифовна,***
*кандидаты филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*2450774@mail.ru*

**2025 елның 25–27 июнендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә ТР ФАнең беренче президенты М.Х. Хәсәновның тууына 95 ел тулуга багышланган «Мансур Хәсән улы Хәсәнов: дәүләт эшлеклесе, галим һәм оештыручы» Халыкара фәнни конференциясе узды. 25 июньдә Казанның Арча зиратында чара кысаларында татар энциклопедистикасына нигез салучы Мансур Хәсән улы Хәсәнов каберенә чәчәкләр салу тантанасы оештырылды.

Фәнни конференция галимне искә алудан башланып китте. Чара барышында галимгә багышланган күргәзмә дә эшләде.

**2025 елның 1–5 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – директор урынбасары Олег Хисамов, ареаль лингвистика бүлеге белгечләре Алинә Хөсәинова һәм Алсу Бәдертдинова Бурятия Республикасының Улан-Удэ шәһәрендә һәм Максимиха бистәсендә узган I Халыкара җәйге лингвистик мәктәп эшендә катнаштылар. Олег Хисамов катнашучыларны институтның инновацион проектлары белән таныштырды, Алинә Хөсәинова һәм Алсу Бәдертдинова фонетика секциясе эшендә чыгыш ясадылар.

**2025 елның 1–11 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Пермь крае Кунгур, Орда, Пермь муниципаль округларының татар торак пунктларында комплекслы экспедициядә булдылар. Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр татар халкының милли-мәдәни мирасын өйрәнделәр, тел, фольклор, сәнгать, археография, һәм эпиграфика буенча бай материал җыйдылар.

**2025 елның 7–8 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, академиянең вице-президенты Ләйсән Абҗәлилова, Татарстан Республикасы Фән һәм технологияләр фонды директоры Тимур Халитов һ. б. катнашындагы делегация Иркустк өлкәсенең фән һәм мәгариф өлкәсендәге тәҗрибәсен өйрәнде. Экспертлар Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге бүлекчәләрендә – Кояш-Җир физикасы институтының Байкал астрофизика обсерваториясендә һәм Җир кабыгы институтында, шулай ук Иркутск милли тикшеренү техник университетында булдылар, Иркутск химия институты белән хезмәттәшлек турында фикер алыштылар.

**2025 елның 11 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов Үзбәкстанның химия сәнәгате министрлыгы делегациясе белән очрашты. Очрашуда химия сәнәгате өлкәсендә хезмәттәшлек, шулай ук Үзбәкстан белән Татарстан арасында эшлекле элемтәләрне ныгыту мәсьәләләре турында фикер алышынды.

**2025 елның 17 июлендә** Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Альберт Гыйльметдинов һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов Мәскәүдә «Росатом»

корпорациясенең аддитив технологияләр үзәгендә булды, урта габаритлы һәм эре габаритлы 3D-принтерлар, турыдан-туры лазерлы үстерү җайланмалары һәм тимер чыбыкны электрон-нурлы эретү җайланмаларының эш принциплары белән танышты, үзәкнең сынау лабораториясен карады. Соңрак республикада аддитив технологияләрне гамәлгә кертү планнары турында фикер алышынды.

**2025 елның 23 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов һәм Россия мәгариф академиясе президенты Ольга Васильева оешмаларның үзара хезмәттәшлеге турында килешүгә кул куйдылар.

**2025 елның 13–24 августында** Болгарда «Ватан тарихы» фонды ярдәмендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы һәм Халыкара Үзәк Азия тикшеренүләре институты тарафыннан гамәлгә ашырылган XII Халыкара археология мәктәбе эшләде. Аның программасы археологик артефактларны реставрацияләү һәм консервацияләүнең заманча технологияләренә багышланган иде. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән, шулай ук Белоруссия, Казахстан, Кытай, Үзбәкстан һәм Таҗикстаннан килгән 80 гә якын бакалавриат, магистратура студентлары, аспирантлар, яшь галимнәр һәм белгечләр катнашты.

**2025 елның 15–25 августында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Красноярск краеның Красноярск, Енисейск шәһәрләре, Абанский, Енисейский, Казачинский, Большемуртинский, Большеулуйский, Бирилюсский районнарында комплекслы экспедициядә булып, җирле диалект үзенчәлекләрен һәм фольклор үрнәкләрен өйрәнделәр.

**2025 елның 18 августында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вәкилләре «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» III Халыкара форумы эшчәнлегендә катнашты. Бу форум кысаларында Татарстан Республикасы Татарстан һәм Кытайның гуманитар фәннәр өлкәсендә хезмәттәшлеге турында фикер алышу булды, ике ил галимнәре тарихи чыганакларны һәм Кытайдагы Россия диаспорасы тарихын өйрәнү өлкәсендә үзара хезмәттәшлекнең төп юнәлешләре турында сөйләште. Шулай ук ясалма фәһем үсеше кысаларында гражданлык авиациясе һәм пилотсыз очу аппаратларының киләчәге турында фикер алышуга багышланган махсус сессия дә үтте, белгечләр логистика, авыл хуҗалыгы һәм мониторинг өлкәләрендәге перспектив проектлар, карарларны бергәләп гамәлгә кертү, локальләштерү һәм масштаблаштыру механизмнарын тәкъдим итте.

**2025 елның 20 августында** Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсенең Цифрлы үсеш, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры урынбасары Булат Габдрахманов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президен-

ты Рифкать Миңнеханов һәм академиянең вице-президенты Марат Сафиуллин, Татарстан Республикасы Фән һәм технологияләр фонды директоры Тимур Халитов Татарстан Республикасы Фәнни-техник мәгълүмат үзәге директоры Арсен Савва катнашындагы делегация Мәскәүдә «Технологик суверенитетка ирешү өчен Россия Федерациясе субъектларында фәнни-технологик үсеш идарәсе модельләрен формалаштыру» дигән темага үткәрелгән стратегик сессия эшендә катнашты.

**2025 елның 26–28 августында** Казанда «Милләт җыены» узды, әлеге масштаблы чара кысаларында VII Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы, Бөтендөнья татар яшьләре форумы һәм Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыелышы оештырылды.

**2025 елның 17–19 сентябрендә** Казанда алтынчы тапкыр Kazan Digital Week – 2025 халыкара форумы узды. Форум һәм махсуслаштырылган күргәзмә «Казан Экспо» ХКҮ мәйданчыгында эшләде. Ачылу тантанасында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Форумда Россиядән катнашучылар да, чит ил кунаклары да тәкъдим ителде. Дөньяның 76 иленнән якынча 20 мең кеше катнашты, 10 төп тема яңгырады, барлык тармакларны үстерү драйверы буларак ясалма акыл булдыру һәм кертү мәсьәләсе көн тәртибенең үзәгенә чыгарылды.

140 тан артык чара узды, алар арасында – Россия Цифрлы үсеш министрлыгының стратегик сессияләре, төрле өлкәләрдә (дәүләт идарәсе, медицина, транспорт, мәгариф, төзелеш) ясалма интеллект кертүнең реаль кейсларын тәкъдим итү, блокчейн-технологияләр һәм криптоиндустрия форумы, конференцияләр, секцияләр, хакатоннар, вебинарлар, шулай ук минироботлар сугышы, МХО ветераннары катнашында мәгълүматны саклау турниры һ. б.

Kazan Digital Week – 2025 форумы цифрлы трансформация өлкәсендә перспектив тенденцияләр һәм алдынгы тәҗрибәләр турында фикер алышу, казанышларны һәм технологик карарларны күрсәтү, тармак лидерлары һәм бөтен дөнья инноваторлары арасында тәҗрибә уртаклашу өчен нәтиҗәле мәйданчык булды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2025. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 19.09.2025. Басылды: 30.09.2025.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 100 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск,
Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла

А.Ю. Махининның «Декоратив-гамәли сәнгать әсәрен булдыруда визуальләштерүнең роле» мәкаләсенә



А. Маренич. «Прогулки по городу»



...«Изгиб гитары желтой»

Ж.О. Кулмамбетовның «Казахстан һәм Кыргызстан театрларының яшь режиссёрлары яңа мәгънә эзли» мәкаләсенә



Арнис Кыдырмышев.
Кыргызстан



Фархат Молдагали.
Казахстан



Уланмырза Карыпбаев.
Кыргызстан

Т.М. Бердникова, Л.М. Шкляеваның «Апас районы рәссамнар иҗатында (пленэр мисалында)» мәкаләсенә



Т.М. Бердникова пленэрда катнашучы рәссамнар арасында

Г.М. Дәүләтшинның «Фронт һәм фән юлын узган галимнәр» мәкаләсенә



М.К. Мөхәррәмов



Я.Г. Абдуллин



Ә.Г. Кәримуллин



Ф.Н. Гыйззәтуллин



К.С. Сабиров



Җ.И. Гыйльманов



Һ.В. Йосыпов



Ф.С. Фәсиев

Т.Н. Галиуллинның «Тарихта һәм фәндә үз урыны бар (галим, җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсәнов истәлегенә)» мәкаләсенә



М.Х. Хәсәнов Т.Н. Галиуллинга ТР ФАнең мөхбир әгъзасы таныклыгын тапшыра. 1998 ел

Х.Ч. Алишинаның «Фуат Әшраф улы Ганиев – төрки тел белемендә фәнни мәктәпкә нигез салучы» мәкаләсенә



И.Г. Галәветдинов, Ф.Ә. Ганиев, Х.Ч. Алишина. Мәскәү, 2010 ел

З.З. Рәмиевнең «Тукай фатихасын алган шагыйрь» мәкаләсенә



Сәгыйть Сүнчәләй

Яңа китаплар






ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗГА ФОТОКҮЗӘТҮ




Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов
һәм Россия мәгариф академиясе президенты Ольга Васильева. 2025 ел, 23 июль



Казанның Арча зиратында Мансур Хәсән улы Хәсәнов каберенә чәчәк салу. 1925 ел, 25 июнь



XII Халыкара археология мәктәбе эшендә катнашучылар Болгарда. 1925 ел, август



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Улан-Удэ шәһәрендә I Халыкара җәйге лингвистик мәктәп эшендә катнашучылар арасында. 2025 ел, 1 июль



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Пермь краенда (Көнгер районы, Яңавыл) фәнни экспедициядә. 2025 ел, 4 июль



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Красноярск крае Большемуртынский районы Казанка авылы халкы белән. 2025 ел, 21 август